Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# Доган кабул булсын дисәң!

Түбән Кама 2010

بسم الله الرحمن الرحيم

# Кереш сүз

إِنَّ الْحَمْدَ للهِ نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ نَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلا مُضِلَّ لَهُ وَ مَنْ يُضْلِلِ فَلا هَادِيَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنْ لا إِلَهَ إِلاَّ اللهُ وَحْدَهُ لا شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً عَبْدُهُ وَ رَسُولُه، أَمَّا بَعْد...

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз — Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребезнең ﷺ юлы. Барча яңалык — бидгать, вә барча бидгать — адашу һәм барча адашу утка илтә.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلا تَمُوتُنَّ إِلا وَأَنْتُمْ مُسْلِمُونَ) آل عمران ١٠٢

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка хак тәкъвалык белән тәкъваланыгыз. Аңа итагать итегез, каршылык вә гөнаһ кылмагыз. Аны зикер кылыгыз, вә онытмагыз. Аңа шөкер итегез һәм көферлек кылмагыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман хәлегездә генә үлегез!».**

(يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالا كَثِيرًا وَنِسَاءً وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالأَرْحَامَ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا) النساء: ١

Мәгънәсе: **«Әй кешеләр! Сезне бер нәфестән (Адәмнән) халикъ кылучы Аллаһка тәкъва булыгыз! Ул (Аллаһ), Адәмнең عليه السلام үзеннән хатын (Хәваны) яратты, вә икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаһка тәкъвалык кылыгыз, Ул — Аллаһ исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаһ ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, һәм Аллаһ ризалыгы өчен**

**сорагач кешенең кире какмаганлыгын беләсез. Шулай булгач, Аллаһны зурлагыз вә якын туганлык җепләрен өзүдән сакланыгыз! Аллаһ бит сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче».**

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَقُولُوا قَوْلا سَدِيدًا ۞ يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَمَنْ يُطِعِ اللهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ فَازَ فَوْزًا عَظِيمًا) الأحزاب ٧٠-٧١

Мәгънәсе: **«Әй мөэминнәр! Аллаһка тәкъва булыгыз, вә хак булган файдалы, дөрес сүзләрне генә сөйләгез! Аллаһ әйткәнчә эш кылсагыз, Аллаһ эшләрегезне вә гамәлләрегезне төзәтер, вә гөнаһларыгызны ярлыкар. Берәү чын күңелдән Аллаһка, вә Аның расүленә итагать итсә, ул кеше һичшиксез өстенлеккә вә изге теләгенә иреште».**

Бу китапта булган аз гына тырышлык, хәерлесе вә дөресе Аллаһ тәгаләдән:

(وَعَلَّمَكَ مَا لَمْ تَكُنْ تَعْلَمُ) النساء: ١١٣

Мәгънәсе: **«Аллаһ сиңа белмәгәнеңне өйрәтте».**

(وَلا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إلا بِمَا شَاءَ) البقرة: ٢٥٥

Мәгънәсе: **«Аллаһ гыйлеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ теләгәнне генә белерләр».**

Ә инде китапта хата вә кимчелек булса — минем үземнән вә шәйтаннан:

(قُلْ هُوَ مِنْ عِنْدِ أَنْفُسِكُمْ) آل عمران: ١٦٥

Мәгънәсе: **«Әйт: «Бу үзегезнең нәфсегездән», — диген».**

(وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِلإِنْسَانِ خَذُولا) الفرقان: ٢٩

Мәгънәсе: **«Шәйтан кешегә батылны матурлап вә хакны кабахәт кылып, алдап ташлап китәр булды».**

**Нәрсә ул дога?**

Дога, мөселман кешесенең тормышында зур әһәмияткә ия. Ул Аллаһ тәгаләгә тәүхид белән бәйле.

Дога — ул, Аллаһ тәгаләгә үзеңнең мескенлегеңне, мохтаҗлыгыңны күрсәтеп, Аннан башка көч-куәт иясе юклыгын белдереп, үзеңә файдалы нәрсәләрне сорау һәм зарарлы нәрсәләрдән саклауны таләп итү. Шуңа да, дога губудиянең — Аллаһка коллыкны күрсәтүнең, иң югары дәрәҗәләреннәндер. Дога белән кеше үзенең түбән, зәгыйфь вә мескен зат икәнлеген тоя һәм Раббысыннан ярдәм өмет итә.

**Доганың фазыйләтләре, җимешләре һәм серләре:**

**1)** Дога — ул, Аллаһка итагатьлелек һәм Аның кушканнарын үтәү. Чөнки Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде:

(وَقَالَ رَبُّكُمُ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ) غافر ٦٠

Мәгънәсе: **«Раббыгыз әйтте: «Миңа ялварыгыз! Мин сезгә җавап бирермен».**

**2)** Дога — ул, гыйбадәт. Бу хакта пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдис-шәрифендә болай диде:

قال النبي صلى الله عليه وسلم: «الدُّعَاءُ هُوَ الْعِبَادَةُ»

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дога — ул, гыйбадәт»[1].***

**3)** Дога тәкәбберлектән пакьлый:

(وَقَالَ رَبُّكُمُ ادْعُونِي أَسْتَجِبْ لَكُمْ إِنَّ الَّذِينَ يَسْتَكْبِرُونَ عَنْ عِبَادَتِي سَيَدْخُلُونَ جَهَنَّمَ دَاخِرِينَ) غافر: ٦٠

---

1 Тирмизий 2969

Мәгънәсе: **«Раббыгыз әйтте: «Миңа ялварыгыз! Мин сезгә җавап бирермен». Әмма, Миңа гыйбадәт итүдән тәкәбберләнеп баш тарткан кешеләр түбәнсетелгән вә хур булган хәлдә җәһәннәм утына керерләр».**

**4)** Дога, Аллаһ тәгалә каршында иң хөрмәтле нәрсә, чөнки дога гыйбадәтнең иң югары өлеше, ә Аллаһ кешеләрне вә җеннәрне бер Үзенә генә гыйбадәт кылыр өчен яратты:

قال النبي ﷺ: «لَيْسَ شَيْءٌ أَكْرَمَ عَلَى اللهِ تَعَالَى مِنَ الدُّعَاءِ»

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә каршында догадан да хөрмәтлерәк нәрсә юк»[2].***

**5)** Дога, Аллаһ тәгаләнең ачуыннан саклануга сәбәп:

قال النبي ﷺ: «مَنْ لَمْ يَدْعُ اللهَ سُبْحَانَهُ غَضِبَ عَلَيْهِ»

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем Аллаһ тәгаләгә дога кылмый икән, Ул аңа ачулана»[3].***

**6)** Дога, Аллаһ каршында күкрәкне киң ача, һәм тәвәкәллеккә вә йөрәкнең бер Аңа гына бәйләнүенә, башка затлардан, кешеләрдән азат булуына сәбәп була.

Ибен Тәймия рахимәһуллаһ болай диде: ***«Адәм баласы үзенең хаҗәтләрен үтәүдә һәм зарарлардан саклануда Аллаһның рәхмәтенә теләге арткан саен, ул кешенең Раббысы каршында губудиясе (итагатьлеге вә коллыгы) арта һәм Аллаһтан башка нәрсәләрдән үзен азат вә иреккле хис итә башлый. Ләкин, әгәр адәм баласының теләге кешеләр вә башка мәхлуклар белән бәйле булса (фәлән кеше генә миңа ярдәм итә ала, аннан гына ярдәм сорарга кирәк, дигән кебек), ул вакытта аның йөрәге шул мәхлук белән бәйле булып, аның колы була».***

2 Тирмизий 3370
3 Ибен Мәҗәһ 3827

**7)** Дога, гаҗизлектән саклый:

قال النبي ﷺ: «أَعْجَزُ النَّاسِ مَنْ عَجزَ فِي الدُّعَاءِ، وَأَبْخَلُ النَّاسِ مَنْ بَخِلَ بِالسَّلامِ»

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Иң гаҗиз кеше — дога кылудан гаҗиз булганы, һәм иң саран кеше — сәлам бирүгә саран булганы»[4].***

**8)** Доганың җимеше тәэмин ителгән, иншәАллаһ:

قال النبي ﷺ: «مَا مِنْ أَحَدٍ يَدْعُو بِدُعَاءٍ إِلاَّ آتَاهُ اللَّهُ مَا سَأَلَ أَوْ كَفَّ عَنْهُ مِنَ السُّوءِ مِثْلَهُ مَا لَمْ يَدْعُ بِإِثْمٍ أَوْ قَطِيعَةِ رَحِمٍ»

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кемдә кем гөнаһлы эшләр яки туганлык җепләрен өзүне сорамыйча, башка нинди генә булса да нәрсәне сорап Аллаһка дога кыла икән, Аллаһ аңа сораганын бирә, яки шуңа тиң булган явызлыктан саклый»[5].***

وقال ﷺ: «ما من مؤمنٍ يَنْصِبُ وَجْهَهُ لله يسأله مسألةً إلا أعطاه الله إياها، إما عجّلها له في الدنيا، وإمّا ذخرها له في الآخرة، ما لم يعجل، قالوا: يا رسول الله وما عَجَلَتُه؟ قال: يقول: دعوت ودعوت ولا أراه يُستجاب لي»

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэмин Аллаһ тәгаләдән нәрсә генә сорамасын, һичшиксез Аллаһ аның сораганын бу дөньяда бирер, яки инде аңа ахирәткә калдырыр, әгәр дә ул сораганын ашыктырмаса».*** Пәйгамбәребездән сорадылар: «Ашыктыру нәрсә була, әй Аллаһның расүле?», — дип. Әйтте: ***«Дога кылучы әйтер: мин дога кылдым, кылдым, әмма ләкин кабул булуын күрмәдем»[6].***

Бу ике хәдистә мәселман кешесенең догасы юкка чыкмаганлыгы бәян ителә.

---

4 Әт-тәргыйб вә әт-тәрһийб 2714

5 Тирмизий 3381

6 Әл-әдәп әл-мүфрад 711

Ибен Хәҗәр болай диде: ***«Һәрбер дога кабул була, ләкин аның кабуллыгы төрлечә; кайвакыт соралган нәрсә кабул булса, ә кайвакыт инде шуңа тиң әйбер бирелә».***

**Доганың шартлары:**

Дога кабул булсын өчен берничә шарт бар, ошбу шартлар үтәлгәндә генә дога кабул була, иншәАллаһ. Без шушы шартларның иң мөһимнәрен искә алып узарбыз:

**1)** Дога кылучы, бер Аллаһ кына аның догасын кабул итәргә кадир икәнлеген белергә тиеш.

**2)** Аллаһтан башкага дога белән ялвармаска тиеш. Чөнки Аллаһтан башкага дога кылу ширеккә керә.

**3)** Аллаһ тәгаләгә тәвәссүл кылганда (якынаю юлы эзләгәндә), шәригать буенча рөхсәт ителгән тәвәссүлне генә кулланырга тиеш. Мәсәлән, Аллаһның күркәм исемнәре, яки камил сыйфатлары белән. Шулай ук, үзенең кылган изге гамәлләре яки исән булган вә көче җиткән изге-салих бәндәнең аның өчен дога кылуын сорап һ.б.

**4)** Доганың кабуллыгында ашыктырудан читләшергә тиеш.

**5)** Яхшы нәрсә сорап кына дога кылырга тиеш.

**6)** Аллаһ тәгалә хакында фәкать яхшы гына уйларга тиеш.

**7)** Йөрәге вә күңеле белән сорарга тиеш.

**8)** Хәләл ризык кына ашарга тиеш.

**9)** Мөселманнарга дошманлыктан читләшергә тиеш.

**Доганың әдәпләре:**

Дога камил булсын өчен кайбер әдәпләр булырга тиеш:

**1)** Доганы Аллаһ тәгаләгә хәмд-сәнә һәм пәйгамбәребезгә салават белән башлау.

**2)** Үзеңнең хата вә гөнаһларыңны тану.

**3)** Аллаһка буйсынучанлык вә күндәмлек күрсәтү.

**4)** Өметләнү.

**5)** Курку.

**6)** Катгый үтенеп сорау.

**7)** Җиңеллектә дә, авырлыкта да сорау.

**8)** Өч тапкыр кабатлап сорау.

**9)** Кыйблага таба юнәлү.

**10)** Кул күтәреп сорау.

**11)** Мисвәк куллану.

**12)** Таһәратле булу.

**13)** Сораган нәрсәгә Аллаһ тәгаләнең исемен туры китереп сорау, мәсәлән: Әй Рахмән! Миңа рахимлек күрсәт! Әй Гаффар! Мине гафу ит! Һәм башкалар.

**14)** Кычкырмыйча, ә бәлки басынкы тавыш белән дога кылу.

**15)** Башта үзе өчен, аннары мөселман туганнары вә кардәшләре өчен сорау.

Шулай ук, дога кабул булының сәбәпләреннән: ихласлылык, тәүбә, золымнан ерак булу, гафләттән имин булу, изгелекләр эшләү, явызлыкларны туктату, фарыз гамәлләрдән соң нәфелләр белән Аллаһка якынаю, ата-ана хакын үтәү, дога кабул була торган билгеле вакытларны, хәлләрне, урыннарны сайлау, һ.б.

# Пәйгамбәребезгә мәхәббәт

(сөннәт һәм бидгать арасында)

Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгаләә кешеләргә Үзенең пәйгамбәренә ﷺ итагать итәргә, аны яратырга һәм ихтирам итеп аның хокукларын үтәргә боерды. Сахәбәләр һәм изге сәләфләр бу боерыкны җиренә җиткереп үтәделәр. Алар пәйгамбәребезгә ﷺ карата мәхәббәтләрен белдереп аны ватаннарына, йорт әһелләренә, малларына караганда да ныграк яраттылар. Хәтта үзләренең иң газиз вә кадерле булган нәрсәләрен аның динен куәтләп, һәм пәйгамбәребезне ﷺ яклап Аллаһка корбан иттеләр. Шуның өчен дә, бу дин алар вакытында бик нык таралды, вә Аллаһ алардан разый булды. Ә инде кайчан бу өммәт зәгыйфьләнде, аны башка өммәтләргә дучар булган хәлләр көтте. Араларында фиркалар, ихтиләфләр, дошманлык һәм бер-берсенә карата нәфрәт барлыкка килде. Монафиклар үзләренең күптән көткән мөмкинчелекләрен таптылар, мөртәдләр башларын күтәреп Исламга каршы чыктылар. Ошбу форсатны өметләнеп көткән йәһүдләр, насаралар һәм барча кәферләр үзләренең меңәрләгән еллар җыйган агуларын Исламга вә мөселманнарга чәчә башладылар. Бәндәләр өчен нур һәм бәхет булган, пәйгамбәребез ﷺ алып килгән Ислам гакыйдәсенә, ошбу нурны сүндерергә теләп, көфер вә ширекне зиннәтләп, матурлап, үзләренең ялган вә батылларын керттеләр. Пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәт белдерүне, «аңа гулүү[7] кылып кына була» — дип, мөселманнарны адаштырдылар. Ә инде кемнәр диннәрендә нык булсалар, аларга төрле кушаматлар билгеләделәр. Алай да булмагач, ул кәферләр вә монафиклар үзләренең гәзитләрендә, радио һәм телевидениеларында пәйгамбәребезне ﷺ мыскыллап көлделәр, һәм әлегә кадәр ул кабахәт гамәлләрен дәвам итәләр.

---

7 Гулүү — кирәгеннән артык кылану (аңлатмасы 25нче биттә).

Алар ничек кенә теләмәсеннәр, ләкин Алаһ тәгалә бу динне Кыяматкә кадәр саклаячак:

(يُرِيدُونَ لِيُطْفِئُوا نُورَ اللَّهِ بِأَفْوَاهِهِمْ وَاللَّهُ مُتِمُّ نُورِهِ وَلَوْ كَرِهَ الْكَافِرُونَ ۞ هُوَ الَّذِي أَرْسَلَ رَسُولَهُ بِالْهُدَى وَدِينِ الْحَقِّ لِيُظْهِرَهُ عَلَى الدِّينِ كُلِّهِ وَلَوْ كَرِهَ الْمُشْرِكُونَ) الصف: ٨ - ٩

Мәгънәсе: **«Кәферләр Коръән вә пәйгамбәрне төрлечә яманлап Аллаһның һидәят нурын авызлары белән сүндермәкче булалар, Аллаһ Үзенең һидәят нурын һәм Ислам динен өйрәтүче Коръәнне кыяматкә хәтле яшәтер, гәрчә кәферләр Аллаһның бу эшен сөймәсәләр дә. Мөшрикләр Ислам диненең өстен булуын сөймәсәләр дә, Ислам дине хаклыгы белән барча диннәрдән дә өстен булсын өчен, Аллаһ Үзенең расүле Мөхәммәдне ﷺ һидәят һәм хак булган Ислам дине белән җибәрде».**

Шуның өчен дә, пәйгамбәребезгә ﷺ карата мәхәббәттә, кешеләр хаклык илә батылны белсеннәр дип, ошбу язмаларны тәкъдим итәргә булдым. Аллаһ Раббыбыз ошбу эшләребезне Үзенең ризалыгы өчен ихлас кылып, динебезгә файдалы гамәлләрдән әйләсә иде.

### Мәхәббәтнең мәгънәсе:

**Мәхәббәт** — ул, саф ярату, бәйләнеш, соклану, теләү һәм йөрәкнең шул әйбергә авышуы.

**Пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәт —** ул, мөселман кешесенең йөрәге аңа авышуы. Хәтта аңа пәйгамбәребез ﷺ үзеннән дә, баласыннан да һәм барча кешеләрдән дә сөйкемлерәк вә якынрак була. Расүлгә булган бу мәхәббәт, мөселманны пәйгамбәре белән нык итеп бәйли, һәм аның йөрәген, ниятен, теләген Аллаһ вә Аның расүле яраткан барча тышкы һәм эчке сүзләргә вә гамәлләргә юнәлтә.

### Пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәтнең хөкеме:

Пәйгамбәребезгә ﷺ нәфрәт ничек Иманны юкка чыгара торган игътикади (инану, ныклы ышану) гамәлләрнең берсә булса, расүлебезгә мәхәббәт тә Иманның бер нигезе һәм шәригатебез боерган гамәлләренең берсе булып тора. Мәхәббәтнең дәрәҗәсен тою, Иманның көчлелегенә вә зәгыйфьлелегенә карап сизелә, шуңа да пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәтнең камиллеге — Иманның камиллегеннәндер. Пәйгамбәребез ﷺ шушыны бәян кылып үзенең хәдис-шәрифендә болай диде:

«لاَ يُؤْمِنُ عَبْدٌ حَتَّى أَكُونَ أَحَبَّ إِلَيْهِ مِنْ أَهْلِهِ وَمَالِهِ وَالنَّاسِ أَجْمَعِينَ»

Мәгънәсе: ***«Мин кешегә әһеленнән, малыннан һәм барчасыннан да иң яратканы булмыйча торып, ул иманлы булмас!»[8].***

Бу хәдис, пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәт булмыйча Иманның камил булмаячагын, һәм аңа мәхәббәтнең фарыз икәнен бәян кылган иң ачык дәлилләрдән. Шулай ук, Бухарида килгән икенче хәдис:

8 Мөслим 44

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ هِشَامٍ ﵁ قَالَ: كُنَّا مَعَ النَّبِيِّ ﷺ وَهُوَ آخِذٌ بِيَدِ عُمَرَ بْنِ الْخَطَّابِ فَقَالَ لَهُ عُمَرُ: يَا رَسُولَ اللَّهِ لأَنْتَ أَحَبُّ إِلَيَّ مِنْ كُلِّ شَيْءٍ إِلاَّ مِنْ نَفْسِي. فَقَالَ النَّبِيُّ ﷺ: «لاَ، وَالَّذِي نَفْسِي بِيَدِهِ، حَتَّى أَكُونَ أَحَبَّ إِلَيْكَ مِنْ نَفْسِكَ» . فَقَالَ لَهُ عُمَرُ: فَإِنَّهُ الآنَ وَاللَّهِ لأَنْتَ أَحَبُّ إِلَيَّ مِنْ نَفْسِي. فَقَالَ النَّبِيُّ ﷺ: «الآنَ يَا عُمَرُ».

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Һишәмнән ﵁: «Бервакыт без пәйгамбәребез ﷺ белән бергә идек, һәм ул Гомәр бин әл-Хаттабның ﵁ кулыннан тоткан иде. Гомәр ﵁ әйтте: Йә расүл Аллаһ! Син миңа үземнең нәфсемнән соң, барча нәрсәдән дә сөеклерәксең. Пәйгамбәребез ﷺ аңа әйтте: ***«Юк! (Иман камил булмас) Аллаһ белән ант итәм! Хәтта үзеңнең нәфсеңә караганда да мин сиңа иң сөекле булганчыга кадәр!».*** Шуннан соң Гомәр әйтте: «Аллаһ белән ант итәм, хакыйкатьтә, хәзер син миңа үземнең нәфсемнән дә сөеклерәк». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хәзер (иман камил), йә Гомәр»[9].***

Бу хәдис, пәйгамбәребез ﷺ мөселманның үз нәфсесенә карата да иң сөеклесе була тормыйча, ул иманның хакыйкатенә ирешмәячәклеген аңлата. Шулай ук моны бәян итеп Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде:

(النَّبِيُّ أَوْلَى بِالْمُؤْمِنِينَ مِنْ أَنْفُسِهِمْ) الأحزاب: ٦

Мәгънәсе: **«Пәйгамбәр мөэминнәр өчен үзләренең нәфселәреннән дә әүвәлерәк вә якынырак».**

Әгәр дә мөэминнең йөрәгендә пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәт көчәйсә вә артса, ул Иманның артуын эстәр.

---

9 Бухари 6632

## Пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәтнең җимешләре:

**1)** Иманның тәмен һәм Аллаһка итагатьнең ләззәтен тою:

عن أنسٍ ﵁ أن النبي ﷺ قال: «ثَلاَثٌ مَنْ كُنَّ فِيهِ وَجَدَ حَلاَوَةَ الإِيمَانِ أَنْ يَكُونَ اللهُ وَرَسُولُهُ أَحَبَّ إِلَيْهِ مِمَّا سِوَاهُمَا ، وَأَنْ يُحِبَّ الْمَرْءَ لاَ يُحِبُّهُ إِلاَّ لِلَّهِ ، وَأَنْ يَكْرَهَ أَنْ يَعُودَ فِى الْكُفْرِ كَمَا يَكْرَهُ أَنْ يُقْذَفَ فِى النَّارِ»

Мәгънәсе: Әнәстән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Ошбу өч әйбер кемдә дә булса, ул Иманның тәмен татыр: 1 — Барча әйберләргә караганда да, ул кешегә Аллаһ һәм Аның расүле иң яраткан вә сөеклеләрдән булса. 2 — Әгәр дә бер кешене ярата икән, аны Аллаһ ризалыгы өчен генә яратса. 3 — Утка ташланудан курыккан кебек, көферлеккә чыгудан курыкса»[10].***

Имам ән-Нәвәви ***«Иманның тәме»,*** — дигәнне аңлатып болай диде: ***«Иманның тәме — ул, итагать (гыйбадәт) итү белән ләззәтләнү һәм дин юлында очраган мәшәкатьләргә сабыр итү, ныклы булу».***

**2)** Ахирәттә юлдаш булуы:

عَنْ أَنَسٍ ﵁ أَنَّ رَجُلاً سَأَلَ النَّبِىَّ ﷺ عَنِ السَّاعَةِ، فَقَالَ: مَتَى السَّاعَةُ؟ قَالَ: «وَمَاذَا أَعْدَدْتَ لَهَا». قَالَ: «لاَ شَىْءَ إِلاَّ أَنِّى أُحِبُّ اللَّهَ وَرَسُولَهُ ﷺ». فَقَالَ: «أَنْتَ مَعَ مَنْ أَحْبَبْتَ». قَالَ أَنَسٌ: «فَأَنَا أُحِبُّ النَّبِىَّ ﷺ وَأَبَا بَكْرٍ وَعُمَرَ، وَأَرْجُو أَنْ أَكُونَ مَعَهُمْ بِحُبِّى إِيَّاهُمْ، وَإِنْ لَمْ أَعْمَلْ بِمِثْلِ أَعْمَالِهِمْ»

Мәгънәсе: Әнәс ﵁ әйтте: Бер кеше пәйгамбәребез ﷺ янына килде дә: «Әй расүл Аллаһ! Кайчан Кыямәт сәгате?», — дип сорады. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Син аңа (Кыямәткә) нәрсә әзерләдең?».*** Теге кеше әйтте: «Аллаһка һәм Аның расүленә мәхәббәт (әзерләдем)». Пәйгамбәребез ﷺ аңа әйтте: ***«Хакыйкатьтә, син кемне яратсаң шуның белән булырсың».*** Әнәс ﵁ әйтте:

10 Бухари 16

«Хакыйкатьтә, мин Аллаһны, Аның расүлен, Әбү Бәкерне, Гомәрне яратам, һәм аларның гамәлләре кебек гамәл итә алмасам да, ләкин алар белән бергә булуны телим»,— диде[11].

## Пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәтне арттыру вә көчәйтү сәбәпләре:

Йөрәктә булган мәхәббәт, аны этәрүче вә хәрәкәтләндерүче сәбәпләр белән бик нык тыгыз бәйләнгән. Шушы сәбәпләрнең барлыгыннан мәхәббәт арта вә көчәя, хәтта ул камилләшү мәртәбәсенә җитә.

Пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәтне арттыруның вә көчәйтүнең иң мөһим сәбәпләре:

**1)** Пәйгамбәребезнең ﷺ үзенчәлекләрен вә сыйфатларын белү:

**а** — Аллаһ Сөбхәнәһү вә тәгалә пәйгамбәребезне яратты вә Үзенең мәхлукларыннан сайлады. Шуның өчен дә Аллаһ яратканны ярату — ул, Аллаһны ярату.

**б** — Пәйгамбәребез ﷺ өммәтенә карата рәхимле вә йомшак булды. Аларга һидәят теләп, Җәһәннәм утыннан коткарырга ашкынды. Шушыларны бәян кылып Аллаһ тәгалә Коръәндә аның турында болай диде:

(حَرِيصٌ عَلَيْكُم بِالْمُؤْمِنِينَ رَءُوفٌ رَحِيمٌ) التوبة: ١٢٨

Мәгънәсе: **«Сезнең иманга килүегез өчен нык ашкынучы, мөэминнәргә шәфкатьле, рәхимле».**

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عَمْرِو بْنِ الْعَاصِ أَنَّ النَّبِيَّ ﷺ تَلاَ قَوْلَ اللَّهِ عَزَّ وَجَلَّ فِي عِيسَى عَلَيْهِ السَّلاَمُ: إِنْ تُعَذِّبْهُمْ فَإِنَّهُمْ عِبَادُكَ وَإِنْ تَغْفِرْ لَهُمْ فَإِنَّكَ أَنْتَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ (المائدة: ١١٨) فَرَفَعَ يَدَيْهِ وَقَالَ «اللَّهُمَّ أُمَّتِى أُمَّتِى». وَبَكَى فَقَالَ اللَّهُ عَزَّ وَجَلَّ يَا جِبْرِيلُ اذْهَبْ إِلَى مُحَمَّدٍ فَقُلْ: «إِنَّا سَنُرْضِيكَ فِى أُمَّتِكَ وَلاَ نَسُوءُكَ»

11 Бухари 3688

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Гамр бин әл-Гастан ﷺ: Пәйгамбәребез ﷺ Гыйсәгә ﷺ кагылышлы ошбу аятьләрне укыды (мәгънәсе): **«Әгәр аларны газап кылсаң — алар Синең бәндәләрең, вә әгәр аларны ярлыкасаң, әлбәттә, Син көчле һәм гадел хакимсең»** (әл-Мәидә 118). Шуннан соң кулларын күтәрде һәм: ***«Әй Аллаһ! Өммәтем. Өммәтем»,*** — диде, вә җылый башлады. Аллаһ ﷻ әйтте: ***«Әй Җибрил! Мөхәммәд янына бар һәм әйт: «Хакыйкатьтә, Без сине өммәтеңдә канәгатьләндерербез вә көендермәбез»[12].***

**в** — Пәйгамбәребезнең ﷺ сыйфатларыннан: Ул өммәтенә карата ихсанлы булды һәм тулысынча нәсыйхәт итеп һидәяткә чакырды. Аллаһка якынайтучы барча хәерле эшләрне күрсәтте вә кешене бу дөнъяда да, ахирәттә дә хәсрәткә вә түбәнчелеккә төшерә торган барча гамәлләрдән кисәтте.

**2)** Мәхәббәтне арттыра торган сәбәпләрдән: Пәйгамбәребезнең ﷺ шәхсыятен белү: Әгәр дә мөселман пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәтен арттырырга уйласа, ул һичшиксез аның шәхсыятенә кагылышлы үзенчәлекләрне вә әхлакларны белергә тиеш. Болар барсы да пәйгамбәребезнең ﷺ сирасын (тормыш тарихын), сыйфатларын, гамәлләрен, сөннәтләрен, аның хәдисләрен укып яки аның хакында булган дәресләрне тыңлап кына беленә.

**3)** Пәйгамбәребезнең ﷺ күрсәткән юлында булып, аның сөннәтен эш белән дә, сүз белән дә гамәл кылу: Әгәр дә мөселман һәрбер эшендә пәйгамбәребезнең ﷺ юлы вә сөннәтенә тотынып гамәл итәргә тырышса, аның пәйгамбәргә ﷺ булган мәхәббәте һичшиксез артачак.

---

12 Мөслим 202

**4)** Пәйгамбәребезгә ﷺ салават вә сәламнәрне еш әйтү, аңа мәхәббәтне арттыра: Алаһ тәгалә Коръәндә болай диде:

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا) الأحزاب: ٥٦

Мәгънәсе: **«Әй, мөэминнәр! Пәйгамбәргә салават һәм сәлам әйтегез».**

Шушы аятьтән һәм башка хәдисләрдән билгеле булганча, пәйгамбәребезне ﷺ искә алганда, аңа салават вә сәлам әйтү вәҗиб.

**5)** Пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәтне арттыручы сәбәпләрдән Ислам гыйлемен өйрәнү. Моны, Коръән вә Сөннәтне һәм алар белән бәйле шәргый гыйлемнәрне өйрәнеп кенә була.

## Пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәтнең ачык галәмәтләренең вә әсәрләренең кешедә сизелүе:

Пәйгамбәребезне ﷺ яраткан кешедә, аның дөреслеген исбатлап кайбер ачык галәмәтләр вә әсәрләр күренә. Шуларның иң мөһимнәреннән:

**1)** Пәйгамбәребез ﷺ кушкан әмерләрне үтәп, тыйганнарыннан тыелу. Бу, пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәттә күренгән иң ачык билгеләрдән. Әл-Кадый Гыйад, рахимаһу Аллаһ, болай диде: ***«Пәйгамбәребезне ﷺ яратуы чын булган кешедә галәмәтләр чагыла, һәм шул галәмәтләрнең иң әүвәле аңа иярү, охшарга тырышу, сөннәтен куллану, аның гамәлләрен, сүзләрен кабул итү һәм авырлыкта да, җиңеллектә дә аның әдәп-әхлагы белән әхлаклану».***

Расүлебез ﷺ үзенең бер хәдис-шәрифендә болай диде:

«مَا نَهَيْتُكُم عَنْهُ فاجْتَنِبُوهُ وَ مَا أمْرتُكُمْ بِهِ فأْتُوا مِنْهُ مَا اسْتَطَعْتُم»

Мәгънәсе: ***«Мин сезгә нәрсәне тыйган булсам — аннан сакланыгыз, һәм сезгә нәрсәне әмер кылган булсам — шуның эшли алганын эшләгез»[13].***

**2)** Пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтенә ияру. Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде:

(لَقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ) الأحزاب: ٢١

Мәгънәсе: **«Тәхкыйк, Аллаһ расүлендә, сезгә ияреpгә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар булды».**

**3)** Тормышыбызда барча мәсьәләләрне дә аның шәригатенә кайтып хөкем итү. Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде:

(فَلَا وَرَبِّكَ لَا يُؤْمِنُونَ حَتَّى يُحَكِّمُوكَ فِيمَا شَجَرَ بَيْنَهُمْ) النساء: ٦٥

Мәгънәсе: **«Раббың исеме белән ант итеп әйтәм, мөселманнар үзара бәхәсләшкән эшләре турысында синнән хөкем иттермичә, чын иманлы була алмаслар».**

**4)** Пәйгамбәребезнең ﷺ шәригатен өйрәнергә омтылу.

**5)** Пәйгамбәребез ﷺ яраткан кешеләрне ярату, һәм ул нәфрәтле булганнарга нәфрәт белдерү.

**6)** Аның сөннәтен куәтләү һәм шәригатен саклау: әл-Кадый Гыйад рахимаһу Аллаһ болай диде: ***«Пәйгамбәребезне ﷺ ярату билгесеннән, аның сөннәтен куәтләү һәм шәригатен саклау».***

**7)** Расүлебезне ﷺ искә алганда аңа салават вә сәлам әйтү.

**8)** Пәйгамбәребезне ﷺ хөрмәтләү, аңа ихтирамлы һәм аның белән әдәпле булу: Аны хөрмәтләүнең ни-

13 Бухари, Мөслим

гезе — ул, аның пәйгамбәрлеген исбатлау, аңа итагать итү һәм аның белән әдәпле булу. Кем боларны үтәми икән — ул, аны хөрмәтләмәгән вә ихтирам итмәгән була. Аңа карата ихтирамсызлык ике төрле сәбәптән килә: **Беренчесе** — аңа карата тупас, коры булу. Аның хаклыгына вә тугрылыгына сүз тидерү, сөннәтендә әдәпсезлек күрсәтү вә санга сукмау. Ул искә алынганда аңа салават вә сәлам әйтмәү. **Икенчесе** — аны тиешсездән артык бөекләү, олуглау, хәтта ул Аллаһка тиң, вә аның нурыннан барча галәм яратылды дигән кебек, һәм башка шәригатебезгә муафыйк булмаган гамәлләр кылу вә сүзләр әйту.

**9)** Шулай ук, пәйгамбәребезне ﷺ ярату галәмәтеннән, аңа нәсыйхәтле булу:

قَال رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمَ: «الدِّينُ النَّصِيحَةُ» قُلْنَا: لِمَنْ؟ قَالَ: «لِلَّهِ وَلِكِتَابِهِ وَلِرَسُولِهِ وَلأَئِمَّةِ الْمُسْلِمِينَ وَعَامَّ» (متفق عليه)

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Дин — ул, нәсыйхәт»,*** без сорадык: *«Кемгә карата йә расүл Аллаһ?».* Ул әйтте: ***«Аллаһка, Аның китабына, Аның пәйгамбәренә, мөселманнарның хәкимнәренә һәм гомум мөселманнарга карата»[14].***

Ән-Нәвәви рахимаһу Аллаһ, моны аңлатып әйтте: ***«Әмма Аллаһның пәйгамбәренә карата нәсыйхәт — ул, аның пәйгамбәрлегенә инану һәм ул алып килгән барча нәрсәгә дә иман китерү. Шулай ук, ул кушкан әмерләргә вә тыюларга итагать итү. Кемнәргә нәфрәтле булган икән — шуларга нәфрәт белдерү, һәм кемнәрне якын иткән вә яраткан икән — шуларны якын итү вә ярату. Аның юлын вә сөннәтен торгызу, дәгватын җиткерү, шәригатен тарату һәм аңа чакыру, вә аның әдәбе илә әдәпләнү һәм әһле-бәйтне вә сахәбәләрне ярату, һ.б.».***

---

14 Бухари, Мөслим 55

**10)** Аны күп искә алу, күрергә өметләнү һәм Кыяməттә аның белән очрашырга омтылу:

عن أبي هريرة أن رسول الله صلى الله عليه و سلم قال: «مِنْ أَشَدِّ أُمَّتِى لِى حُبًّا نَاسٌ يَكُونُونَ بَعْدِى يَوَدُّ أَحَدُهُمْ لَوْ رَآنِى بِأَهْلِهِ وَمَالِهِ» (مسلم)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Өммәтемнән мине нык яратучылар миннән соң булырлар, хәтта алар үзләренең әһелләрен вә малларын фида кылып мине күрүне теләрләр»[15].***

Кемдә дә булса ошбу галәмәтләр вә әсәрләр чагыла икән, ул пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәтен белдерүдә чын булыр, иншәАллаһ.

## Сахәбәләрнең пәйгамбәребезгә ﷺ карата булган мәхәббәтләре:

Галидән ﵁: *«Пәйгамбәргә ﷺ булган мәхәббәтегез ничек иде»,* — дип соралгач, ул бу хакта болай дип җавап бирде: ***«Аллаһ белән ант итәм! Ул безгә малларыбыздан да, балаларыбыздан да, ата-аналарыбыздан да һәм бик нык сусаганда эчәсе салкын судан да сөйкемлерәк вә якынырак иде»,*** — диде.

Сахәбәләрнең расүлгә булган мәхәббәтләреннән кайбер мисаллар:

**1)** Әбү Бәкер Сиддыйк ﵁: (Бухаридагы хәдиснең мәгънәсе) Гаишә ﵂, әйтте: *«Бервакыт, көн уртасында, без Әбү Бәкернең ﵁ йортында утырганда, кемдер аңа әйтте: «Карагыз! Менә бу пәйгамбәребез ﷺ йөзен каплап килә. Гадәттә ул безгә бу вакытта килми!». Әбү Бәкер ﵁ әйтте: «Атам һәм анам аңа фида булсын! Аллаһ белән ант итәм, бу вакытта аны монда, иллә-мәгәр бик мөһим эш кенә китерә ала!».* Гаишә әйтте: *«Бераздан пәйгамбәребез ﷺ йортка килде һәм*

15 Мөслим 2832

*керергә рөхсәт сорады. Аңа рөхсәт бирелгәч, ул керде һәм Әбү Бәкергә ﷺ әйтте:* ***«Синең яныңда (йортыңда) булган барсын да чыгар».*** *Әбү Бәкер ﷺ әйтте: «Минем атам сиңа фида булсын йә расүл Аллаһ, алар барсы да синең гаиләң әһелләрең». Шуннан соң пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Миңа (һиҗрәт белән) чыгарга рөхсәт ителде»,*** *һәм Әбү Бәкер ﷺ әйтте: «Атам сиңа фида булсын йә расүл Аллаһ! Мин синең юлдашың буламмы!?». Пәйгамбәребез ﷺ:* ***«Әйе»,*** *— диде».*

Ибен Хәҗәр әйтте: «Ибен Исхак үзенең риваятендә өстәп болай диде: Гаишә әйтте: «Шуннан соң Әбү Бәкернең ﷺ елаганын күрдем, ир кеше шатлыгыннан елый икән дип, беркайчан да уйламас идем».

Әбү Бәкер ﷺ вафат булыр алдыннан сорады: «Бүген нинди көн?» Аңа әйттеләр: «Дүшәмбе». Шуннан соң ул әйтте: «Әгәр дә мин бу төндә үлсәм, мине иртәгәгә калдырмагыз, хакыйкатьтә, пәйгамбәребезгә ﷺ якын булган көннәр вә төннәр, миңа да иң сөеклесе». (Мүснәд Әхмәд, Әхмәд Шәкир сахих диде)

**2)** Гомәр бин әл-Хаттаб ﷺ: (Бухарида килгән (3700) хәдиснең кыскача мәгънәсе): *«Пәйгамбәребез ﷺ һәм Әбү Бәкер ﷺ белән бергә җирләүләрен теләп, Гомәр ﷺ вафат булыр алдыннан Гаишәдән рөхсәт сорады. Гаишә болай дип җавап бирде: «Мин бу урынны үзем өчен тели идем, бүген аны аңа (Гомәргә) тапшырам». Моңа Гомәр бик тә шатланды һәм: «Әлхәмдүлилләһ, миңа моннан да мөһимрәк әйбер юк иде, әгәр дә мин вафат булсам, мине күтәреп алып китегез, һәм сәлам биреп әйтегез (Гаишәгә): «Гомәр рөхсәт сорый, әгәр (Гаишә) рөхсәт итсә, мине шунда алып кереп күмегез, әгәр кире какса, мөселманнар каберенә илтеп күмегез».*

Бу хәдисләрдән күрәбез ки, сахәбәләр пәйгамбәребезне ﷺ бик тә нык ятратканлыктан, хәтта үлгәч тә аның белән бергә булуны теләделәр.

**3)** Ансарлар пәйгамбәребезнең ﷺ Мәдинәгә һиҗрәт белән килүенә шатланалар: Гуруә бин әз-Зүбәердән (мәгънәсе): ***«Мөселманнар пәйгамбәребезнең ﷺ Мәккәдән чыгуын ишеткәч, көндә иртән Харрага[16] чыгып, көндезге өйлә кояшы кыздырып аларны кире йортларына кайтырга мәҗбүр иткәнчегә кадәр, аны көтәләр иде».*** (Бухари 3906). Әнәстән ؓ (мәгънәсе): ***«Пәйгамбәребез ﷺ белән Әбү Бәкер ؓ Мәдинәгә кергән көннән дә нурлырак һәм дә яхшырак көн күрмәдем».*** (Мүснәд Әхмәд 20/290). Бәра бин Газибдан ؓ (мәгънәсе): ***«Мәдинә әһелләренең пәйгамбәребезгә ﷺ (килүенә) шатланган кебек шатланганнарын беркайчан да күргәнем булмады, хәтта кол хатын-кызлар шатлыкларыннан: «Аллаһның расүле (пәйгамбәребез ﷺ) килде», — дип кычкыралар иде».*** (Бухари 3925)

**4)** Үхүд сугышында пәйгамбәребезне ﷺ саклап унике сахәбә сугышты, шуларның унбере вафат булып Тальха бин Губайдуллаһ ؓ гына калды. Ул расүлебезне ﷺ яклап сугышканда, хәтта бармаклары киселеп өзелде. Ахырдан, Аллаһ тәгалә мөшрикләрне кире чигендерде. Кайс бин Әбйии Хазимнән ؓ (мәгънәсе): ***«Мин Тальханың, Үхүд көнендә пәйгамбәребезне ﷺ саклап сугышканнан соң, хәрәкәтләнми торган кулын күрдем».*** (Бухари 4063). Әбү Бәкер ؓ әгәр дә Үхүд көнен исенә төшерсә, елый торган иде, һәм: ***«Ул көн тулысы белән Тальха көне»,*** — дип әйтә иде. Шулай ук, Әнәс ؓ Үхүд көне турында болай дип әйтте (мәгънәсе): ***«Пәйгамбәребез ﷺ кешеләргә карап идарә итә иде, Әбү Тальха ؓ аңа әйтте: Әй Расүл Аллаһ! Минем атам һәм***

16 Мәдинәнең әйләнәсендә булган янар таудан атылып чыга торган, эрегән тау токымнары массасы басуы.

***анам сиңа фида булсын! Идарә итмә (борчылма). Сиңа бер-бер ук тимәсен! Мин үләм, ләкин сиңа тидермим (үземне сине саклап корбан кылам)».*** (Бухари 4064)

**5)** Гамр бин әл-Гастан ﵁ (мәгънәсе): ***«Миңа пәйгамбәребездән дә ﷺ сөйкемлерәк кеше юк иде, һәм аңа карата булган тирән хөрмәтемнән, аңа күземне тутырып карый алмый идем. Әгәр дә миннән аны сыйфатларга сорый торган булсалар, мин аны сыйфатлый алмый идем, чөнки аңа күземне тутырып караганым булмады».***

**6)** Рабига бин Кәгъб әл-Әсләмийидән ﵁ (мәгънәсе): *«Бервакыт пәйгамбәребез ﷺ белән кундым, һәм аңа таһәрат өчен су һәм башка хаҗәтләрен алып килдем, ул миңа:* ***«Нәрсә дә булса сора!»,*** *— диде. Мин әйттем: «Җәннәттә синең юлдашың булуны сорыйм». Әйтте:* ***«Моннан башка тагын бармы?».*** *Мин әйттем: «Анысы да (башка соравым да) шул». Әйтте:* ***«Күп сәҗдә (намаз) кылып үзеңә ярдәм ит».*** (Мөслим 489)

**7)** Гаишәдән (мәгънәсе): *«Бер кеше пәйгамбәребез ﷺ янына килде һәм әйтте: «Әй расүл Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин сине үземнең нәфсемә караганда да, үземнең балама караганда да ныграк яратам. Әгәр дә мин йортта булып сине искә алсам, яныңа килеп сине күрмичә сабыр итә алмыйм. Шулай ук, әгәр дә үземнең һәм синең вафат булуыңны күз алдыма китерсәм, син, әлбәттә, Җәннәткә кергәч пәйгамбәрләр белән югарыда булырсың, ә мин Җәнәткә керсәм (сезнең белән бергә югары дәрәҗәләрдә булмыйча) сине башка күрә алмамын дип куркам». Пәйгамбәребез ﷺ аңа дәшмәде, хәтта Җибрил ошбу аятьлар белән вахи индергәнчегә кадәр:*

(وَمَنْ يُطِعِ اللَّهَ وَالرَّسُولَ فَأُولَئِكَ مَعَ الَّذِينَ أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِمْ مِنَ النَّبِيِّينَ وَالصِّدِّيقِينَ وَالشُّهَدَاءِ وَالصَّالِحِينَ وَحَسُنَ أُولَئِكَ رَفِيقًا) النساء: ٦٩

Мәгънәсе: **«Аллаhка hәм Расүлгә итагать иткән мөэминнәр, Аллаh нигъмәтләгән пәйгамбәрләр, турылык белән алга чыккан ситдыйклар, Аллаh юлында сугышып шәhид булган мөэминнәр, hәм изге-салих бәндәләр белән Җәннәттә бергә булырлар. Шушы дүрт төрле затларга юлдаш булу — ни күркәм, ни хуш юлдашлыктыр».** (Мәҗмәгъ әз-Зәүәид (7/7). Әт-Табараний вә Әбү Нүгайм риваяте)

### Пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәт иттибагъ hәм ибтидагъ (сөннәт hәм бидгать) арасында:

Үткәннәрдән без белдек: Пәйгамбәребезнең ﷺ кушкан әмерләрен үтәп, тыйганнарыннан тыелу — ул, аңа карата булган мәхәббәтнең иң мөhим галәмәтләреннән. Ә инде аңа мәхәббәт белдерүдә бидгать юлларны куллану — ул, пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәтне юкка гына чыгару. Болар арасында нинди аерма бар соң?

**1) Нәрсә ул «Иттибагъ»?**

Пәйгамбәребезгә ﷺ иттибагъ — ул, гамәлләрдә, сүзләрдә hәм ул күрсәткән барча фигыльләрдә аңа охшарга тырышу (ияру).

Аллаh тәгалә пәйгамбәр ﷺ кушканнарга ияреpгә боерды, hәм аңа карышудан вә мәгъсыять кылудан каты кисәтте:

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَطِيعُوا اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَلَا تَوَلَّوْا عَنْهُ وَأَنْتُمْ تَسْمَعُونَ) الأنفال: ٢٠

Мәгънәсе: **«Әй, мөэминнәр! Аллаhка вә Аның расүленә итагать итегез! Вә Аллаh әмерләреннән баш тартмагыз-качмагыз! Һәм сез ишетеп торасыз (сезгә**

**Аллаһ тәгаләнең китабы укыла, хөкемнәре җиткерелә, вә расүлегез вәгазьләр һәм нәсыйхәтләр кыла)».**

(وَمَا آَتَاكُمُ الرَّسُولُ فَخُذُوهُ وَمَا نَهَاكُمْ عَنْهُ فَانْتَهُوا
وَاتَّقُوا اللَّهَ إِنَّ اللَّهَ شَدِيدُ الْعِقَابِ) الحشر: ٧

Мәгънәсе: **«Пәйгамбәр нәрсәне сезгә китерсә — кабул итеп алыгыз, вә сезне нәрсәдән тыйса — тыелыгыз!».**

Шушылардан, безгә бәян булды: Пәйгамбәребезгә ﷺ иттибагъ кылу (ияру) — өммәтебезнең һәрбер мөселманына фарыз. Ә инде иттибагъның ачык галәмәтләре, шул ук пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәт галәмәтләре вә әсәрләредер.

**2) Нәрсә ул «Ибтидагъ»?**

Ибтидагъ — ул, бидгать дигәннән алынган, яки, Коръәндә дә, Сөннәттә дә һәм шәригатебездә дә нигезе булмаган, динебезгә кемнәрдер тарафыннан яңалык итеп кертелгән гыйбадәт.

Пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәт белдерәбез дип ибтидагъ кылуның сәбәбе, ул — ***гулүү***[17]***.*** Ислам гулүүне хәрам кылды һәм аны эшләүдән тыйды:

(لَا تَغْلُوا فِي دِينِكُمْ) النساء: ١٧١

Мәгънәсе: **«Динегездә гулүү кылмагыз!».**

Әл-Куртубый үзенең тәфсирендә болай диде: ***«Гулүүдән тыйды, һәм гулүү — ул, чиктән артык чыгып китү. Шуның кебек үк, мәсәлән, хакның артуы (әйбернең билгеләнгән хакыннан артып китүе). Тәфсир белгечләре әйтеп узганча, монда йәһүдләрнең Гыйсәгә عليه السلام карата тиешле чиктән узып китеп, хәтта***

17 Игътикад (инану, ныклы ышану) яки гамәлләр белән, шәригатебез билгеләгән чиктән чыгып, нәрсәне яки кемне булса да тиешсез артык зурлау, олуглау вә бөекләү.

***Мәрьямгә сүз тидерүләре аңлашыла. Шулай ук, насараларның (христианнар) Гыйсәгә карата гулүү кылып аны хәтта раббы (иләһ) итүләре беленә».***

Ибен Габбастан رضي الله عنه (мәгънәсе): Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әй кешеләр! Диндә гулүү кылудан сакланыгыз, хакыйкатьтә, сезгә кадәр булганнарны, диндә гулүү кылу һәләк итте».*** (Әхмәд,ән-Нәсәи, Ибен Мәҗәһ.

Ибен Тәймийә әйтте: **«Диндә гулүү кылудан сакланыгыз», *— дип әйтүе, ул гулүүнең барча төренә дә кагыла, булсын ул игътикадтә яки гамәлләрдә».***

**— Гулүү ике төрле: игътикадтә (инану, ныклы ышануда), һәм гамәлдә.**

**1)** Игътикадтәге (инану, ныклы ышанудагы) гулүү:

Игътикадтәге гулүү — дөрес гакыйдәдә булган чикләрне чыгып китеп, бозык вә дөрес булмаган гакыйдәгә килеп керүдә чагыла. Игътикадтәге гулүүгә мисал итеп, насараларның Гыйсәгә عليه السلام карата булган гулүүләрен, шулай ук, кайбер суфыйларның пәйгамбәребезгә ﷺ карата булган гулүүләрен китерергә була. Хәтта кайбер суфыйлар пәйгамбәребез ﷺ нурдан яратылган, һәм галәмнәрдә үзе теләгәнчә эш йөртә, дип ышаналар. Багъзе бер суфыйлар үзләренең шәйхларын гөнаһсыз дип уйлап, үлгәч аларның каберләренә барып ярдәм сорап гулүү кылалар. Шигыйләрнең бер төркеме Гали رضي الله عنه «иләһ» дип гулүү кылсалар, икенче бер төркеме аны башкача гулүү кыла.

**2)** Гамәлдәге гулүү:

Гамәлдәге гулүү — шәригатебездәге билгеле хөкемнәргә бәйле. Кемдә кем мәндүб яки сөннәтне фарыз итте икән — ул тиешле чикне чыгып китеп, диндә гулүү кылган булды. Шулай ук, кем мәкруһны

хәрам кылса, мөбаһны мәкруһ яки хәрам кылса, яки никахны үзенә хәрам итсә, һәм шуңа охшашлы башка хөкемнәрне тиешлесеннән арттырып, шәригатебезгә муафыйк булмаган гамәл итсә — ул, гулүү кылган була.

**— Гулүүнең сәбәпләре:**

**1)** Шәригать һәм дин гыйлемендә җәһиллек (гыйлемсезлек).

**2)** Үзеңнең нәфсеңә (һәвәгә) иярү, һәм гакылыңа ошаганча хөкем итү.

**3)** Ялган һәм зәгыйфь хәдисләргә таяну.

### Пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәт белдерәбез дип барлыкка килгән кайбер бидгатьләр:

Бидгатьчеләрнең гыйбадәттә дә, игътикадтә дә бидгать барлыкка китерүләре, пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәт белдерәбез, дип аңа карата **гулүү** кылуның әсәрләреннән булды. Заманалар узган саен ул бидгатьләр дә артты. Шушы бидгатьләрнең кайберләрен әйтеп узарбыз:

**1)** Кайбер суфыйларның пәйгамбәребезне ﷺ тере килеш өндә күрәбез дип ышанулары. Һәм алар үзләрен аның белән бергә җыелып киңәшләшәбез, аларга ул юлны күрсәтә, мәүлид мәҗлесләрендә алар белән бергә була, дип хыялланалар. Бу фикер суфыйларның «Тиҗәния», «Мөхәммәдия», «Әхмәдия» дип аталган фиркаларда нигез итеп алынган.

**2)** Пәйгамбәребез ﷺ һәм аның Аллаһ каршында булган зур дәрәҗәсе белән шәригатебездә тыелган тәвәссүл кылу (якынаю юлы эзләү). Бу тәвәссүлгә алар, пәйгамбәребезнең ﷺ Аллаһ каршында булган

зур дәрәҗәсе белән Аллаһтан ярдәм сорауны, шулай ук, расүлебездән ﷺ үзләренең хаҗәтләрен сорауны кертәләр. Шуңа да, аларда пәйгамбәр белән тәвәссүл кылу дөрес булгач, әүлияләр белән дә тәвәссүл кылу дөрес дип санала. Хакыйкатьтә, пәйгамбәребез ﷺ белән тәвәссүл кылу өчкә бүленә:

а — Аллаһның расүленә иман китереп һәм аңа итагать итеп тәвәссүл кылу. Бу төрле тәвәссүл шәригатебездә дөрес санала, һәм аңа дәлилләр бар.

б — Пәйгамбәребез ﷺ дөнъяда тере вакытта аннан дога кылуын һәм шәфәгать итүен өстәп кылынган тәвәссүл. Моңа дәлил итеп сахәбәләрнең пәйгамбәребез ﷺ тере вакытта, Аллаһтан яңгыр сорап, яки гафу итүне сорап, дога кылуын таләп итүләрен алырга була. Ләкин бу төрле тәвәссүл пәйгамбәребез ﷺ дөнъяда тере вакытта гына кылына иде. Ул вафат булгач аның белән тәвәссүлне сахәбәләр дә, тәбигыйннар да, изге сәләфләр дә кылмады, һәм моңа бернинди дөрес дәлил дә юк.

в — Пәйгамбәребезнең ﷺ заты белән тәвәссүл кылу, һәм аның зур дәрәҗәсе илә Аллаһтан сорау. Бу төрле тәвәссүл шәригатебездә тыелган, чөнки моңа бертөрле сахих дәлил дә юк. Һәм шулай ук пәйгамбәребез ﷺ исән вакытта да, ул вафат булгач та сахәбәләрдән бер әсәр дә килмәде. Ләкин зур кызганычка каршы, хәзерге көндә суфыйларда һәм үзләрен шулар сафына керткән кайбер адашкан мөселманнарда бу төрле тәвәссүл киң таралган вә максат итеп куелган.

**3)** Пәйгамбәребезнең ﷺ каберен зиярат итү белән бәйле кайбер бидгатьләр:

Габдуллаһ бин Гомәр сәфәрдән килгәч пәйгамбәребезнең ﷺ мәчетенә кереп намаз укый иде,

аннары Расүлебезгә, Әбү Бәкергә һәм Гомәргә сәлам бирә иде. Шушы рәвешчә пәйгамбәребезнең ﷺ каберен зиярат кылу, шәригатебезчә була. Ләкин, кайбер кешеләр пәйгамбәребезнең ﷺ каберен зиярат итүдә күп кенә бидгатьләр кылалар:

а — Пәйгамбәребезнең ﷺ каберен зиярат итү ул фарыз, һәм хаҗны камилләштерү гамәленең берсе — дип ышану. (Шулай ук пәйгамбәребез ﷺ белән бәйле булган, хаҗиларның «Нур» тавындагы тау тишегенә кереп намаз укулары, дога кылулары, сыпыру вә үбүләре шәригатебездә дөрес булмаган гамәлләрдән. Алай гына да түгел, ә бәлки кабахәт бидгатьләрдән). Бу ышану, дин хөкемнәрен белмәгәнлектән һәм ялган вә зәгыйфъ хәдисләргә таянудан гына барлыкка килә.

б — Пәйгамбәребезнең ﷺ мәчетенә аннан рөхсәт сорап кергән рәвешле керү.

в — Пәйгамбәребезнең ﷺ каберен зиярат иткәндә, анда намаз укучы кебек басып тору, кыйблага карамыйча, ә кабергә карап дога кылу, һәм башка шәригатебездә каралмаган нинди дә булса тәгаенле гамәлләр кылу.

г — Пәйгамбәребезнең ﷺ бүлмәсен сыпыру, ишектәге тимер челтәрне үбү яки бәрәкәт таләп итеп ул ишекне тоту кебек гамәлләр.

д — Пәйгамбәребез ﷺ зиярат кылучының ниятен, уйларын белә дип ышану.

е — Пәйгамбәребезнең ﷺ каберен аерым тәгаенле бер вакытта гына зиярат итү кебек нәрсәләр.

ж — Пәйгамбәребез ﷺ яткан бүлмәгә карау — ул, гыйбадәт дип ышану.

3 — Пәйгамбәребезгә ﷺ сыену, һәм аңа үзеңнең авырлыкларыңны сөйләп ярдәм сорау кебек нәрсәләр.

**4)** Пәйгамбәребезгә ﷺ **гулүү** сәбәбендә барлыкка килгән бидгатьләрнең тагын берсе — ул, рабигъ әл-Әүвәл аенда «Мәүлид» үткәрү. Ул бидгатьне шәргый бәйрәмгә, һәм Аллаһка якынаюга әйләндерделәр. Билгеле булганча, атналык җомгадан башка шәргый бәйрәмнәр икәү: ураза һәм корбан гаетләре. Изге сәләфләр пәйгамбәребезгә ﷺ кагылышлы хокукларны иң яхшы белүчеләр һәм аны иң яратучы кешеләр булып та, мондый бәйрәмнәр үткәрмәделәр.

Шулай ук, пәйгамбәребезгә ﷺ **гулүү** сәбәбле барлыкка килгән башка бидгатьләр бар. Аллаһу мүстәган!

**Ахырдан:**

Без пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәтнең фарыз икәнлеген, аны көчәйтү вә арттыру сәбәпләрен һәм ул мәхәббәтнең кешедә күренгән галәмәтләрен вә җимешләрен белдек. Шулай ук, мәхәббәтнең мәгънәсен, сахәбәләрнең расүлебезне ﷺ ничек көчле итеп яратканнарын аңладык. Пәйгамбәребезгә ﷺ булган мәхәббәттә **иттибагъ** һәм **ибтидагъны** аердык. Һәм дә ошбу мәхәббәттә ибтидагъның (бидгатьнең) иң мөһим сәбәпләреннән булган **гулүүне** искә алдык.

- Без пәйгамбәребезгә ﷺ иман китереп, анынча гыйбадәт кылып һәм аның әхлаклары белән әхлакланып яшибезме?

- Без үзебезнең йорт-әһелләребезгә, туганнарыбызга пәйгамбәребезгә ﷺ мәхәббәтне өйрәттекме?

- Без аларга расүлебезнең ﷺ сөннәтен, юлын, сыйфатларын өйрәттекме?

- Без пәйгамбәребезнең ﷺ кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелабызмы?

- Без үзебезнең арабызда бер-бер низаг яки бер төрле мәсьәлә килеп чыкса, аның шәригате буенча хөкем итәбезме?

- Без пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтен куәтлибезме?

- Без сөннәт буенча гамәл итеп, аны башкаларга да өйрәтәбезме?

# Сабырларны шатландыр

## Сабырлыкның төшенчәсе:

Сабырлык — ул, кешенең теләге белән бәйле күркәм холык көче. Бу көч белән кеше авырлыкларны, авыртуларны, арыганлыкларны күтәрә һәм тиз ачулану, курку, шәһвәт кебек башка кимчелекле сыйфатлардан үзен саклый.

Сабырлык белән кеше һәрбер нәрсәне үз урынына куеп, сәламәт акыл белән уйлап һәм үлчәп, дөрес эш итә ала. Ә сабырсызлык белдергән кеше, хәтта ул изгелек эшләргә теләсә дә, киресенчә — ашыгып, уйламыйча күпчелек вакыт хаталанып эш итә.

## Сабырлык чагыла торган кайбер урыннар:

А) Кайгы вә хәсрәтләр килгәндә Аллаһ ризалыгы өчен үз-үзеңне тота белү — сабырлыктан.

Б) Озак вакытка сузылган эш эшләгәндә, ялыкмыйча вә җиренә җиткереп эшләү — сабырлыктан.

В) Ашыгыч нәтиҗәләр чыгармау — сабырлыктан.

Г) Үз-үзеңне нәрсәгә булса да тиз рәвештә ачуланудан кулга ала белү — сабырлыктан.

Д) Батырлык күренергә тиеш булган урыннарда курыкмыйча гамәл итә белү — сабырлыктан.

Е) Үз-үзеңне саранлыктан тота белү — сабырлыктан.

З) Шәһвәтләргә һәм нәфсегә иярүдән үз-үзеңне кулга ала белү — сабырлыктан.

К) Тормышта килгән төрле рухи вә бәдәни авырлыкларга, мәшәкатьләргә һәм авырту-сызлануларга бирелмичә үз-үзеңне кулга ала белү — сабырлыктан.

## Сабырлыкның фазыйләте:

Сабырлыкның фазыйләтләре бик күп: Ул кешедә булган теләк көчлелеген, акыл камиллеген күрсәтә. Шулай ук, бу тормышта кешегә очраган төрле мәшәкать вә авырлыкларда хикмәт белән гамәл кылып яшәргә өйрәтә һәм адәм баласына бу дөньяда бирелгән имтиханны үтүдә ярдәм итә. Пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдисендә (Мөслим 223) сабырлыкны нур дип бәян итеп узды. Тормыш авырлыкларын һәм сынауларын үтүгә ярдәм итеп, кешене җиңүгә, бәхеткә вә Җәннәткә илтә торган иң көчле коралларның берсе икәнлеге хакында Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде:

(أَمْ حَسِبْتُمْ أَنْ تَدْخُلُوا الْجَنَّةَ وَلَمَّا يَعْلَمِ اللَّهُ الَّذِينَ جَاهَدُوا مِنْكُمْ وَيَعْلَمَ الصَّابِرِينَ) آل عمران: ١٤٢

Мәгънәсе: **«Әллә сез Җәннәткә авырлыкларсыз, җиңел генә керергә исәплисезме? Сездән Ислам динен куәтләр өчен кәферләр белән сугышкан һәм төрле авырлыкларга сабырлык күрсәткән хак мөэминнәрне Аллаһ белми дип уйлыйсызмы?».**

## Төрле авырлыкларга, авыртуларга вә бәла-казаларга карата сабыр булу хакында

Ислам мөэминнәрне мәшәкатьләргә, төрле авырлыкларга, кайгы-хәсрәтләргә сабыр һәм дә Аллаһ тәгаләнең када-тәкъдиренә риза булырга өнди. Шулай ук, аларга килгән яхшылык Аллаһтан, ә авырлыклар вә кайгы-хәсрәтләр кешеләрнең үз сәбәпләреннән икәнлеген бәян итә. Әгәр дә Аллаһ тәгаләгә итагать

итеп, Аның када-тәкъдиренә риза булып вә ризалыгын өмет итеп сабырлык кылсалар, аларга зур әҗер-савап булачагы белән вәгъдә кыла.

**1)**

(وَلَنَبْلُوَنَّكُمْ بِشَيْءٍ مِنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنْفُسِ
وَالثَّمَرَاتِ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ ۞ الَّذِينَ إِذَا أَصَابَتْهُمْ مُصِيبَةٌ قَالُوا
إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ ۞ أُولَئِكَ عَلَيْهِمْ صَلَوَاتٌ مِنْ رَبِّهِمْ
وَرَحْمَةٌ وَأُولَئِكَ هُمُ الْمُهْتَدُونَ) البقرة: ١٥٥ ــ ١٥٧

Мәгънәсе: **«Без сезне, әлбәттә, куркынычлардан соң куркыныч биреп, ачлык биреп, малларыгызны киметеп, сәламәтлекләрегезне киметеп, көтмәгәндә якыннарыгызны үтереп, игеннәрегезне һәм бакча җимешләрегезне киметеп сыныйбыз. Аллаһтан сынар өчен бирелгән төрле авырлыкларга риза булып, Аллаһ юлыннан баручы сабыр мөэминнәрне шатландыр! Ул чыдамлы мөэминнәргә бер кайгы килсә: «Без, әлбәттә, Аллаһ бәндәләре һәм хөкемгә Аллаһка кайтучыларбыз, шуның өчен Аллаһ биргән казаларга сабыр итәбез», — диләр. Бәла-казаларга риза булып, сабыр итүче мөэминнәргә — Раббыларыннан гафу һәм рәхмәттер. Һәм алар — туры юлга күнүчеләр».**

Бу аять-кәримәдән аңлашылганча, бәла-казалар тәнгә дә, рухка да, мал-мөлкәткә дә вә җиләк-җимешләргә дә зур авырлыклар сиздерә, һәм алар бу тормышта кешегә бирелгән имтиханның бер төре булып килә. Чөнки Аллаһ тәгалә **сынарбыз яки ибтилә кыларбыз** диде, һәм ул бу аятътә имтихан вә игътибар мәгънәсендә килә. Шулай ук, аять-кәримә бәндәнең тормышында очраган авырлыклардан саналган куркуга, ачлыкка, мал-мөлкәтнең кимүенә, туган-тумачаларның үлүенә һәм җиләк-җимешләрнең һәлакәткә очрап юкка чыгуына сабырлык күрсәтеп

түзәргә өнди һәм сабырларның авырлыклар каршында күрсәткән әдәбен бәян итә. Чөнки алар авырлыкларга очраса: **«Без, әлбәттә, Аллаһ бәндәләре һәм хөкемгә Аллаһка кайтучыларбыз»,** – дип, килгән кадага, сабыр итеп, ризалыкларын белдерәләр.

Аллаһ тәгаләнең бәндәләрне имтихан вә игътибар кылуы, вакыты белән җиңеллек вә шатлык биреп — шөкер итсеннәре өчен, һәм вакыты белән авырлык вә кайгы-хәсрәт биреп — сабыр итсеннәре өчен. Боларның ике төре дә — имтихан вә ибтилә. Җиңеллек вә шатлыкларга шөкрана кылып сабырлык күрсәтү, авырлык вә кайгы-хәсрәтләргә чыдап сабырлык күрсәтүгә караганда зуррак имтихан вә ибтилә дип санала.

Бу аятьтә **«Сабырларны шатландыр»,** — дигәне, ике шатлыклы хәбәрне үзенә ала:

а) аларга Аллаһтан гафу һәм мактау;

б) аларга Раббыларыннан рәхмәт.

**2)**

(وَلِكُلِّ أُمَّةٍ جَعَلْنَا مَنْسَكًا لِيَذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ عَلَى مَا رَزَقَهُمْ مِنْ
بَهِيمَةِ الأَنْعَام فَإِلَهُكُمْ إِلَهٌ وَاحِدٌ فَلَهُ أَسْلِمُوا وَبَشِّرِ الْمُخْبِتِينَ (٤٣)
الَّذِينَ إِذَا ذُكِرَ اللَّهُ وَجِلَتْ قُلُوبُهُمْ وَالصَّابِرِينَ عَلَى مَا أَصَابَهُمْ
وَالْمُقِيمِي الصَّلَاةِ وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنْفِقُونَ) الحج: ٣٤ - ٣٥

Мәгънәсе: **«Сезнең иләһәгез бер Аллаһ, Аңа кайтыгыз вә итагать итегез, мөхбитләрне шатландыр. Ул мөхбитләргә Аллаһ зикер ителсә, аларның йөрәкләре тетрәр һәм ирешкән бәла-казага сабыр итәрләр, вә намазларын вакытында үтәрләр, вә Без биргән малдан, Аллаһ күрсәткән урыннарга, садака бирерләр».**

Гарәп телендә, Раббыларына мөхбитләр: алар Аллаһка тулысынча буйсынып, түбәнчелек, курку

белдерүчеләр, чөнки мөхбит сүзе «الْخَبْتِ» — «әл-хәбт» дигәннән алынган, һәм ул — түбән, тыныч вә буйсынучан дигәнне аңлата. Ә шәргый төшенчәсе: әгәр дә аларга Аллаһ зикер ителсә — аларның йөрәкләре тетри, бәла-казаларга сабыр итәләр, намазларын вакытында үтәп Аллаһ ризалыгын өмет итеп, тиешле урыннарга зәкәт вә садакаларын бирәләр.

## Аллаһ ризалагы өчен авырлыкларга сабырлык күрсәтү – гөнаһларга кәффәрат

Авырлыклар соңында Раббысыннан әҗер-савап һәм гөнаһларга кәффәрат булуын белү, мөэминне сабыр һәм чыдамлы булырга этәрә. Авырлыкларга сабырлык күрсәтү гөнаһларга кәффәрат булуы хакында пәйгамбәребезнең ﷺ кайбер хәдис-шәрифләрен искә алып үтәрбез:

٥٦٤٢ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ عَنْ النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «مَا يُصِيبُ الْمُسْلِمَ مِنْ نَصَبٍ وَلا وَصَبٍ وَلا هَمٍّ وَلا حُزْنٍ وَلا أَذًى وَلا غَمٍّ حَتَّى الشَّوْكَةِ يُشَاكُهَا إِلا كَفَّرَ اللَّهُ بِهَا مِنْ خَطَايَاهُ» (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөселман, нәрсәгә генә дучар булмасын, арумы яки чирме, куркумы яки кайгымы, изамы яки хәсрәтме, хәтта, кечкенә генә энә яки шырпы кадалуы булсынмы, болар өчен Аллаһ аның гөнаһларын ярлыкый».***

٧٤٦٥ - عَنْ عَبْدِ اللَّهِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ :أَتَيْتُ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فِي مَرَضِهِ وَهُوَ يُوعَكُ وَعْكًا شَدِيدًا وَقُلْتُ: إِنَّكَ لَتُوعَكُ وَعْكًا شَدِيدًا، قُلْتُ: إِنَّ ذَاكَ بِأَنَّ لَكَ أَجْرَيْنِ؟ قَالَ: «أَجَلْ مَا مِنْ مُسْلِمٍ يُصِيبُهُ أَذًى إِلا حَاتَّ اللَّهُ عَنْهُ خَطَايَاهُ كَمَا تَحَاتُّ وَرَقُ الشَّجَرِ» (البخاري)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгудтән ﵁: *Пәйгамбәребез ﷺ авырган вакытта мин аның янына*

*кердем, аның тәне ут кебек кызу иде, әйттем: «Синең тәнең бик тә нык кызу, (башкаларга караганда) сиңа икеләтә әҗер булган өченме бу?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Әйе, мөселман нинди генә авырлык күрмәсен, Аллаһ тәгалә аның гөнаһларын, агач яфраклары коелган кебек, кояр (ярлыкар)».***

٥٤٦٥ - حَدَّثَنَا عَبْدُ اللَّهِ بْنُ يُوسُفَ أَخْبَرَنَا مَالِكٌ عَنْ مُحَمَّدِ بْنِ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عَبْدِ الرَّحْمَنِ بْنِ أَبِي صَعْصَعَةَ أَنَّهُ قَالَ: سَمِعْتُ سَعِيدَ بْنَ يَسَارٍ أَبَا الْحُبَابِ يَقُولُ سَمِعْتُ أَبَا هُرَيْرَةَ يَقُولُ : قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «مَنْ يُرِدْ اللَّهُ بِهِ خَيْرًا يُصِبْ مِنْهُ» (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә кемгә хәерлене (яхшылыкны) теләсә, шул кешене (авырлыклар белән) сыный».***

٢٣٩٦- عن أنس قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: «إذا أراد الله بعبده الخير عجل له العقوبة في الدنيا وإذا أراد الله بعبده الشر أمسك عنه بذنبه حتى يوافي به يوم القيامة» ( سنن الترمذي، حسن صحيح)

Мәгънәсе: Әнәстән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә Аллаһ тәгалә Үзенең колына (бәндәсенә) хәерлене (яхшылыкны) теләсә, аңа бу дөньяда ук җәзасын бирер (авырлыклар белән сынар һ.б.), әгәр дә Аллаһ колына начарлыкны теләсә, Кыямәт көнендә каты газап кылыр өчен аның гөнаһына карата булган җәзасын бу дөньяда кичектерер».***

٩٩٣٢ - عن أبي هريرة قال: قال رسول الله صلى الله عليه وسلم: «ما يزال البلاء بالمؤمن والمؤمنة في نفسه وولده وماله حتى يلقى الله وما عليه خطيئة» ( سنن الترمذي حسن صحيح)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэмин һәм мөэминә үзләрендә, балаларында һәм малларында бәла-каза күрүдән туктамас, хәтта***

***Аллаһ тәгаләне очратканда аларның бер гөнаһ-хатасы да калмас».***

## Авырлыкларга түзә алмыйча үлем теләү ярамаганлыгы хакында

Мөселманның барча тормышы аңа изге гамәлләрне күбрәк кыларга һәм гөнаһларына тәүбә итәргә зур форсат. Чөнки алда искә алганыбызча, ул Аллаһ ризалыгы өчен, авырлыкларга сабыр итә икән — аңа әҗер-савап һәм гөнаһ-хаталарына ярлыкау. Аллаһ тарафыннан бирелгән бу нигъмәтне тулы акыллы мөселман инкяр итмәс. Ничек кенә булмасын, пәйгамбәребез ﷺ үлем теләүдән тыйды.

٥٣٢٧ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «لا يَتَمَنَّى أَحَدُكُمْ الْمَوْتَ إِمَّا مُحْسِنًا فَلَعَلَّهُ يَزْدَادُ وَإِمَّا مُسِيئًا فَلَعَلَّهُ يَسْتَعْتِبُ» (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Берегез дә үзенә үлем теләмәсен, әгәр дә изгелек кылучылардан булса, ул тагын да күбрәк изгелек эшләргә тырышыр, ә гөнаһ кылучылардан булса — гөнаһ-хаталарына тәүбә кылып изгелек эшләргә тырышыр».***

١٧٦٥ - عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «لا يَتَمَنَّيَنَّ أَحَدُكُمْ الْمَوْتَ مِنْ ضُرٍّ أَصَابَهُ فَإِنْ كَانَ لا بُدَّ فَاعِلا فَلْيَقُلْ اللَّهُمَّ أَحْيِنِي مَا كَانَتْ الْحَيَاةُ خَيْرًا لِي وَتَوَفَّنِي إِذَا كَانَتْ الْوَفَاةُ خَيْرًا لِي» (البخاري)

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәликтән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Берегез дә үзенә килгән кайгыдан үлем теләмәсен, ә инде аның башка чарасы калмаса, болай дип әйтсен: «Йә Аллаһ! Яшәү миңа хәерле булганга кадәр минем гомеремне сакла, ә инде әгәр миңа үлем хәерле булса, мине үлеләндер».***

Бу хәдисләрдән аңлашылганча, мөэмин үзенә мотлак рәвештә үлем теләргә тиеш түгел, бәлки Аллаһның тәкъдире белән риза булып һәм изге гамәлләр кылып тормышын дәвам итәргә тиеш. Ә кем Аллаһка һәм Кыямәт көненә ышануны кире кага икән, ул кеше тормышында иң беренче авырлыкка очрау белән борчыла башлый вә төшенкелеккә бирелә. Авырлыклар ешайган саен ул кешенең «сулышы» кысыла, һәм ул үзенә «сулыш» алыр өчен бер генә юл да таба алмый. Бу кеше авырлыкларны күтәрә алмыйча үз-үзенә кул сала, яки акылдан яза, яки җинаять юлына баса, яки инде хәмер, исерткечләр вә наркотикка бирелеп тормышын юкка чыгара. Авырлыклар килгәндә кеше таба алмаган «сулыш», иллә-мәгәр Аллаһка, Аның фәрештәләренә, китапларына, расүлләренә, Кыямәт көненә һәм тәкъдиргә иман белән генә табыла. Шуның өчен дә, мөэминнәр кәферләр дучар булган исерткеч, наркотик, үз-үзенә кул салу һәм башка төрле җинаятьләрдән вә бәлаләрдән ераклар һәм сәламәтләр. Мөселман илләре иң имин вә тыныч илләр, мәгәр соңгы вакытларда кайбер мөселман яшьләре кәферләрнең агулары белән агуланып, хак юлдан тайпыла башладылар һәм үзләрен бәла-казага салдылар. Болар һәммәсе дә Аллаһ тәгаләдән вә Аның кануннарыннан ераклашу нәтиҗәсе, Аллаһу мүстәган.

## Сабырлык – тормыш заруратлары

Кеше тормышында сабырлык барча файдалы гамәлләрдә дә кирәк, шуңа да сабырлык ул тормыш заруратлары булып тора. Ризык кәсеп итү — сабыр-

лыкка мохтаҗ, кешеләр белән мөгамәлә кылу — сабырлыкка мохтаҗ, гыйбадәт — сабырлыкка мохтаҗ, шәригатебезне үтәү — сабырлыкка мохтаҗ, хәрамнардан вә мәкруһлардан саклану — сабырлыкка мохтаҗ, Аллаһ юлында җиһәд кылу — сабырлыкка мохтаҗ, тормыш авырлыкларына бирелмичә алга бару — сабырлыкка мохтаҗ. Ягъни, адәм баласының тормышы тулысы белән сабырлыкка мохтаҗ. Моңа шулай ук Коръән аятьләре дә ишарәт итә:

**1)** Гыйбадәт сабырлыкка мохтаҗ икәнлеккә ишарәт кылган аятьләрдән:

(رَبُّ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَمَا بَيْنَهُمَا فَاعْبُدْهُ وَاصْطَبِرْ
لِعِبَادَتِهِ هَلْ تَعْلَمُ لَهُ سَمِيًّا) مريم:٦٥

Мәгънәсе: **«Ул — Аллаһ, җир вә күкләр, һәм алар арасында булган нәрсәләрнең Раббысы, Аңа гыйбадәт кыл, һәм гыйбадәттә бик тә нык сабыр бул! Син беләсеңме Аңа тиңне? Юк әлбәттә! (Күркәм исемнәрдә, камил сыйфатларда, рубубияттә вә иләһияттә Аңа һичнәрсә тиң түгел, шуның өчен дә фәкать Ул гына хакыйкый гыйбадәткә лаек, һәм Аңа булган гыйбадәттә бик тә нык сабыр бул)».**

Бу аять шәрифтән күренгәнчә, Аллаһ тәгалә Үзенә гыйбадәт белән әмер кылгач, гади сабырлык белән генә түгел, ә бәлки бик тә нык каты сабырлык белән боерды. Чөнки Аның кушканнарын үтәү һәм тыйганнарыннан тыелу зур сабырлыкка мохтаҗ.

**2)** Кешеләр белән аралашу вә мөгамәлә кылу сабырлыкка мохтаҗ икәнлекне бәян кылган аятьләрдән:

(وَمَا أَرْسَلْنَا قَبْلَكَ مِنَ الْمُرْسَلِينَ إِلَّا إِنَّهُمْ لَيَأْكُلُونَ الطَّعَامَ وَيَمْشُونَ فِي
الْأَسْوَاقِ وَجَعَلْنَا بَعْضَكُمْ لِبَعْضٍ فِتْنَةً أَتَصْبِرُونَ وَكَانَ رَبُّكَ بَصِيرًا)

Мәгънәсе: **«Бәгъзегезне бәгъзегезгә (берәүләрегезне икенчеләрегезгә) фетнә кылдык, сабыр итәрсезме икән? Раббың хәлегезне күрүче булды, вә һәркемгә тиешле җәзасын ( әҗерен яки газабын) бирер».** Әл-Фуркан 20

Бу аятьтә күргәнебезчә, Аллаһ тәгаләнең кешеләрне бер-берсе белән сынавы, шулай ук Аның тарафыннан билгеләнгән имтихан, һәм бу имтиханны уңышлы үтү өчен сабырлык кирәк. Шуңа да Аллаһ тәгалә «сабыр итәрсезме», — диде, ягъни бу имтиханда, җиңүгә вә уңышка ирешер өчен сабыр булырсызмы, дигән мәгънәдә.

**3)** Аллаһ юлында җиһәд кылу зур сабырлыкка мохтаҗ икәнлекне бәян кылып бик күп аятьләр вә хәдисләр килде. Чөнки җиһәдтә мөселман үзенең җанын Аллаһ ризалыгы өчен корбан кылырга әзер булырга тиеш, шуңа да җиһәд бик тә көчле иманга вә зур сабырлыкка мохтаҗ.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آَمَنُوا اصْبِرُوا وَصَابِرُوا وَرَابِطُوا
وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ) آل عمران: ٢٠٠

Мәгънәсе: **«Әй, мөэминнәр! Тормыш авырлыкларына, дин мәшәкатьләренә, төрле казаларга һәм дошманнарның һөҗүмнәренә сабыр итегез! Сабырлыкта бик тә нык вә даими булыгыз. Һәм Аллаһка тәкъва булыгыз, шаять өстенлек табарсыз!».**

Аллаһ Сөбхәнәһү вә тәгалә бу аятьтә мөэминнәрне сабыр булырга өнди, һәм дә сабырлыкның югары дәрәҗәдәгесен күрсәтергә боера. Әгәр дә дошманнар сугышта сабырлык вә чыдамлык күрсәтсә, мөҗәһидләр аларның сабырлыгыннан да артыграк сабыр вә чыдам булып, дошманнарның сабырлыгын сындырырга вә аларны сугыш мәйданыннан качарга мәҗбүр итәргә тиеш. Ихлас ният белән, Аллаһ риза-

лыгы өчен, җиһәд кылган мөҗәһидкә ике бәхетнең берсе: яки җиңү, яки шәһид булу.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا لَقِيتُمْ فِئَةً فَاثْبُتُوا وَاذْكُرُوا اللَّهَ كَثِيرًا لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ ۞ وَأَطِيعُوا اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَلَا تَنَازَعُوا فَتَفْشَلُوا وَتَذْهَبَ رِيحُكُمْ وَاصْبِرُوا إِنَّ اللَّهَ مَعَ الصَّابِرِينَ) الأنفال: ٤٥ ــ ٤٦

Мәгънәсе: **«Әй, мөэминнәр! Әгәр дә сез сугышта кәферләр гаскәренә юлыксагыз, чыдамлы булыгыз, качмагыз вә Аллаһны күп зикер итегез, шаять җиңәрсез, өстен булырсыз. Аллаһка вә Аның расүленә итагать итегез! Вә үзара низаглашмагыз, әгәр низаглашсагыз көчегез, гайрәтегез китәр, таралырсыз. Сабыр булыгыз! Хакыйкатьтә, Аллаһ сабырлар белән, аларга ярдәм бирә».**

Аллаһ тәгалә бу аятьтә мөэминнәргә, сугыш мәйданында кәферләргә очрасалар, чыдамлы вә сабыр булырга боерды. Аять азагында Раббыбызның **«Сабыр булыгыз! Аллаһ сабырлар белән»,** — дигәне, алар шундый сабырлар ки: **а)** Аллаһка иман китерүчеләр; **б)** Аңа һәм расүленә итагать итүчеләр; **в)** Аны күп зикер итүчеләр; **г)** араларында низаглашмыйча бер әмир астында җыелучылар; **д)** шулай ук мәтди яктан әзерләр.

Бу вакытта Аллаһ аларны үзләренең карамагына калдырмый, бәлки Үзе аларга ярдәм вә җиңү бирә.

**4)** Ачуны тоту, ярсыган вакытта үз-үзеңне кулга алып тынычлану һәм яхшылык белән җавап бирү, шулай ук сабырлык холкының зур өлешенә мохтаҗ. Сабыр холыклы булмаган кеше, ачулы вакытта, үз-үзен кулга алып тынычлана алмый, һәм шулай ук явызлыкка яхшылык вә изгелек белән җавап бирә алмый.

(وَلَا تَسْتَوِي الْحَسَنَةُ وَلَا السَّيِّئَةُ ادْفَعْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ فَإِذَا الَّذِي بَيْنَكَ وَبَيْنَهُ عَدَاوَةٌ كَأَنَّهُ وَلِيٌّ حَمِيمٌ ۞ وَمَا يُلَقَّاهَا إِلَّا الَّذِينَ صَبَرُوا وَمَا يُلَقَّاهَا إِلَّا ذُو حَظٍّ عَظِيمٍ ۞ وَإِمَّا يَنْزَغَنَّكَ مِنَ الشَّيْطَانِ نَزْغٌ فَاسْتَعِذْ بِاللَّهِ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ) فصلت: ٣٤ – ٣٦

Мәгънәсе: **«Яхшылык илә явызлык бертигез булмаслар, чөнки яхшылыкта файда һәм сәваб бар, явызлыкта зарар һәм газап бар. Әгәр сиңа берәү явызлык кылса, син аңа җавап итеп яхшылык кыл, ул кеше сиңа явызлыкны дошманлык белән кыладыр, әмма син сабыр ит һәм дә аның явызлыгына каршы һәрвакыт изгелек ит, соңра ул синдә явызлыкның юклыгын белеп, явызлык итүеннән туктар һәм тәүбә итеп синнән гафу сорар, аннары бер-берегезгә якын дус булырсыз. Ләкин бу эшне һәр кеше эшли алмас, мәгәр көчле иманлы, чын сабыр мөэминнәр генә эшли алырлар, вә явызлыкка каршы изгелек итү һәрбер кешегә бирелмәс, мәгәр олуг бәхетле, күркәм холыклы кешегә генә бирелер. Әгәр явызлык итүчегә изгелек итәргә шәйтан сиңа ирек бирмәсә, шәйтанның вәсвәсәсеннән Аллаһка сыгын, Ул сине шәйтан вәсвәсәсеннән саклар, аннары явызлыкка каршы изгелек итә алырсың. Бит, Ул — Аллаһ, ишетүче вә белүче».**

Аллаһ Сөбханәһү вә тәгалә бу аятьтә явызлыкка каршы изгелек белән җавап бирергә боерды, һәм шуннан соң, бу гамәлне барча кеше дә эшли алмас, илләмәгәр күркәм сабырлык белән сыйфатланганнар гына эшли алыр, диде. Кешеләр арасында кайберәүләр икенчеләргә төрлечә явызлык кыла: кемдер кардәшенә тел тидерә, кемдер кул күтәрә, ә кемдер малын хаксыз ала, һәм башкалар. Күргәнебезчә, Аллаһ тәгалә бу аятьтә явызлыкка шундый ук явызлык белән кайтарганчы, яхшылык вә ихсанлык белән җавап бирү

хәерлерәк дигәнне бәян итте, һәм бу сабырлыктагы иң күркәм өлеш. Бу күркәм холыкка әмирләр, түрәләр, патшалар бик тә мохтаҗ булса, моңа шулай ук гади кешеләр дә мохтаҗ. Чөнки мондый күркәм холык җәмгыятьтә дәва кебек, кешеләрнең бер-берсенә мәхәббәт вә дуслык тудыра. Шулай ук бу хакта тагын берничә аять:

(وَسَارِعُوا إِلَى مَغْفِرَةٍ مِنْ رَبِّكُمْ وَجَنَّةٍ عَرْضُهَا السَّمَوَاتُ وَالْأَرْضُ أُعِدَّتْ لِلْمُتَّقِينَ ۞ الَّذِينَ يُنْفِقُونَ فِي السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ) آل عمران: ١٣٣ – ١٣٤

Мәгънәсе: **«Раббыгызның ярлыкавына, һәм җир вә күкләр киңлегендә булган Җәннәтләр тарафына ашыгыгыз! Ул Җәннәтләр тәкъва мөэминнәргә әзерләнде. Ул мөэминнәр җиңел һәм авыр вакытларда да Аллаһ күрсәткән урыннарга садака бирәләр, ачулары килгәндә үзләрен кулга алып тынычланалар, кешеләрне гафу итәләр. Яхшылык кылучыларны Аллаһ сөядер».**

(فَمَا أُوتِيتُمْ مِنْ شَيْءٍ فَمَتَاعُ الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَمَا عِنْدَ اللهِ خَيْرٌ وَأَبْقَى لِلَّذِينَ آمَنُوا وَعَلَى رَبِّهِمْ يَتَوَكَّلُونَ ۞ وَالَّذِينَ يَجْتَنِبُونَ كَبَائِرَ الْإِثْمِ وَالْفَوَاحِشَ وَإِذَا مَا غَضِبُوا هُمْ يَغْفِرُونَ ۞ وَالَّذِينَ اسْتَجَابُوا لِرَبِّهِمْ وَأَقَامُوا الصَّلَاةَ وَأَمْرُهُمْ شُورَى بَيْنَهُمْ وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنْفِقُونَ ۞ وَالَّذِينَ إِذَا أَصَابَهُمُ الْبَغْيُ هُمْ يَنْتَصِرُونَ ۞ وَجَزَاءُ سَيِّئَةٍ سَيِّئَةٌ مِثْلُهَا فَمَنْ عَفَا وَأَصْلَحَ فَأَجْرُهُ عَلَى اللهِ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الظَّالِمِينَ ۞ وَلَمَنِ انْتَصَرَ بَعْدَ ظُلْمِهِ فَأُولَئِكَ مَا عَلَيْهِمْ مِنْ سَبِيلٍ ۞ إِنَّمَا السَّبِيلُ عَلَى الَّذِينَ يَظْلِمُونَ النَّاسَ وَيَبْغُونَ فِي الْأَرْضِ بِغَيْرِ الْحَقِّ أُولَئِكَ لَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ ۞ وَلَمَنْ صَبَرَ وَغَفَرَ إِنَّ ذَلِكَ لَمِنْ عَزْمِ الْأُمُورِ) الشورى: ٣٦ – ٤٣

Мәгънәсе: **«Аллаһтан сезгә бирелгән дөньядагы барча нәрсә, фәкать вакытлыча дөнья тереклеге һәм дөнья зиннәтедер. Әмма Аллаһ хозурында булган, бетми торган мәңгелек ахирәт нигъмәтләре, Аңа иман ки-**

**тереп тәвәккәл итүчеләр өчендер. Алар шулай ук зур гөнаһлардан һәм фәхеш эшләрдән сакланырлар, һәм аларны берәү ачуландырса, гафу итәрләр. Вә алар Аллаһның һәр боерыгын кабул итәрләр, вә намазларын вакытында укырлар, вә киңәш лязем җирдә үзара киңәш итәрләр, вә Без биргән малдан мохтаҗларга, вә Аллаһ юлына садака бирерләр. Вә араларыннан берсе залимнәрдән хаксыз җәберләнсә, бергәләшеп ярдәм итеп, ул җәберләнгән мөэмин кардәшләрен коткарырлар. Явызлык илә золым итүчегә үзе золым иткән хәтле генә җәза бирелә, әгәр мәзълум кеше залимне гафу итсә һәм араларын төзәтсә, бу эшнең әҗере Аллаһ хозурында сакланыр, әмма Аллаһ залимнарны сөймидер. Бер мәзълум хаксыз золым итүчедән арттырмыйча үч алса, аңа гөнаһ юк һәм аңардан үч алу да юктыр. Кешеләргә золым итеп җир өстендә хаксыз явызлык кылучы залимнәргә җәза бирергә шәригатьтә юл бардыр, ул залимнәргә ахирәттә рәнҗеткүче газаб булыр. Әмма берәү хаксыз золымга сабыр итсә, һәм залимне гафу да итсә, бу эш, ягъни үч алмыйча сабыр итү һәм Аллаһ ризасы өчен гафу итү, шәригать тарафыннан таләп ителгән эштер».**

## Сабырларның Аллаһ каршындагы фазыйләте

Бу дөньяда кеше гаять зур сабырлыкка мохтаҗ, чөнки аның гомере тулысы белән имтихан:

(الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ
عَمَلًا وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ) الملك: ٢

Мәгънәсе: **«Ул үлемне һәм тереклекне халикъ кылды, йөкләмәләр йөкләп сезнең кайсыларыгыз яхшырак**

**гамәлле икәнлеген сынамак өчен. Ул һәрнәрсәдән өстен вә ярлыкаучы».**

Бу дөньядагы имтихан зур сабырлык тәлап иткәч, сабырлыкның Аллаһ каршында урыны да зур. Шуңа да, Аллаһ тәгалә сабырларны ярата вә аларга ярдәмен бирә, дип Коръәндә бәян итте:

(وَاللَّهُ يُحِبُّ الصَّابِرِينَ) آل عمران: ١٤٦

Мәгънәсе: **«Аллаһ сабырларны ярата».**

(الْآنَ خَفَّفَ اللَّهُ عَنْكُمْ وَعَلِمَ أَنَّ فِيكُمْ ضَعْفًا فَإِنْ يَكُنْ مِنْكُمْ
مِئَةٌ صَابِرَةٌ يَغْلِبُوا مِائَتَيْنِ وَإِنْ يَكُنْ مِنْكُمْ أَلْفٌ يَغْلِبُوا
أَلْفَيْنِ بِإِذْنِ اللَّهِ وَاللَّهُ مَعَ الصَّابِرِينَ) الأنفال: ٦٦

Мәгънәсе: **«Хәзер инде Аллаһ сезгә җиңеллек кылды, һәм сезнең арагызда зәгыйфьләр барлыгын белде, сездән чыдамлы вә сабыр бер йөз кеше булса, ике йөз кәферне җиңәрләр, әгәр сездән мең чыдамлы вә сабыр кеше булса, Аллаһның ярдәме белән ике мең кәферне җиңәрләр, Аллаһ сабырлар белән».**

Аллаһ тәгалә сабырларга хисапсыз әҗерләр бирүе хакында болай диде:

(قُلْ يَا عِبَادِ الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا رَبَّكُمْ لِلَّذِينَ أَحْسَنُوا فِي هَذِهِ الدُّنْيَا حَسَنَةٌ
وَأَرْضُ اللَّهِ وَاسِعَةٌ إِنَّمَا يُوَفَّى الصَّابِرُونَ أَجْرَهُمْ بِغَيْرِ حِسَابٍ) الزمر: ١٠

Мәгънәсе: **«Әй, Мөхәммәд ﷺ, әйт: «Әй, иман китергән Аллаһның бәндәләре, Раббыгызга тәкъва булыгыз! Дөньяда вакытта Аллаһка итагать итеп, гыйбадәтләр вә изге гамәлләр кылган хак мөэминнәргә, ахирәттә Җәннәт нигъмәтләре бар. Аллаһ тәгаләнең җире киң, торган җирегездә дингә тарлык булса, һиҗрәт кылыгыз! Хакыйкатьтә, сабыр итүчеләргә хисапсыз әҗерләр бирелер».**

Шулай ук, пәйгамбәребез дә ﷺ бәла-казаларга сабыр итүчеләрнең фазыйләтен һәм аларга зур әҗер-саваб булуы хакында үзенең хәдис-шәрифләрендә бәян итте:

٦٤٢٤ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «يَقُولُ اللَّهُ تَعَالَى: مَا لِعَبْدِي الْمُؤْمِنِ عِنْدِي جَزَاءٌ إِذَا قَبَضْتُ صَفِيَّهُ مِنْ أَهْلِ الدُّنْيَا ثُمَّ احْتَسَبَهُ إِلا الْجَنَّةُ» (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә әйтә: Әгәр дә Мин мөэмин колымның бу дөньяда иң яраткан кешесен алсам, һәм ул Аллаһтан әҗер өмет итеп, када вә тәкъдиргә риза булып, барча килгән авырлыкларга сабыр итсә, аңа Җәннәттән башка җәза (әҗер) булмас (ягъни, аңа Җәннәт булыр)».***

٣٥٦٥ - عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ قَالَ: سَمِعْتُ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَقُولُ: «إِنَّ اللَّهَ قَالَ: إِذَا ابْتَلَيْتُ عَبْدِي بِحَبِيبَتَيْهِ فَصَبَرَ عَوَّضْتُهُ مِنْهُمَا الْجَنَّةَ» يُرِيدُ عَيْنَيْهِ. (البخاري)

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәликтән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә әйтте: Әгәр дә Мин колымның ике сөеклесен (ике күзен, чөнки күзләр кешегә тәнендәге иң сөекле нәрсәләр) алып сынасам, һәм ул сабырлык күрсәтсә, моның өчен аңарга Миннән Җәннәт булыр!».***

**Сабырлык иң беренче мизгелдә чагылырга тиеш:**

Авырлыкка яки бәла-казага дучар булган кеше, күпмедер вакыт узгач бу кайгыны оныта һәм аның күңеле тынычлана. Кешенең иң авыр хәле кайгы килгәннең иң әүвәлге мизгелендә, шуңа да пәйгамбәребез ﷺ, сабырлык беренче мизгелдә чагылырга тиешлеген бәян итеп узды. Чөнки билгеле бер кайгыдан соң вакыт узып онытылгач һәм күңел ты-

нычлангач, ул кайгы-сабырлыкка мохтаҗ түгел, һәм аңа әҗер савап та юк, Аллаһу әгъләм.

١٢٨٣- عَنْ أَنَسِ بْنِ مَالِكٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ قَالَ: مَرَّ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ بِامْرَأَةٍ تَبْكِي عِنْدَ قَبْرٍ فَقَالَ: «اتَّقِي اللَّهَ وَاصْبِرِي» قَالَتْ: إِلَيْكَ عَنِّي فَإِنَّكَ لَمْ تُصَبْ بِمُصِيبَتِي وَلَمْ تَعْرِفْهُ، فَقِيلَ لَهَا: إِنَّهُ النَّبِيُّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ، فَأَتَتْ بَابَ النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَلَمْ تَجِدْ عِنْدَهُ بَوَّابِينَ فَقَالَتْ: لَمْ أَعْرِفْكَ، فَقَالَ: «إِنَّمَا الصَّبْرُ عِنْدَ الصَّدْمَةِ الأولَى» (البخاري)

Мәгънәсе: Әнәс бин Мәлик ﵁ риваять итеп әйтте: Пәйгамбәребез ﷺ кабер янында елап торган бер хатын-кыз яныннан узып барганда (туктап) аңа әйтте: ***«Аллаһка тәкъва бул, һәм сабыр ит!».*** Ул (хатын) аның расүл ﷺ икәнлеген белмичә әйтте: «Калдыр мине, чөнки сиңа минеке кебек кайгы төшкәне юк!». Аңа әйттеләр: «Хакыйкатьтә, ул бит пәйгамбәребез ﷺ!». Шуннан соң ул хатын пәйгамбәребез ﷺ (йорты) янына килде, әмма ләкин аның ишеге янында бер сакчы да күрмәде (чөнки ул, пәйгамбәребез ﷺ патшалар кебек яши дип уйлаган иде) һәм әйтте: «Мин сине белмәдем!». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, сабырлыкны, кайгының иң беренче мизгелендә күрсәтергә кирәк!».***

Әл-Хаттабий әйтте: *«Кеше мактала (әҗер-савапка лаек була) торган сабырлык — ул, кешегә кинәт кенә килгән кайгының (авырлыкның) иң беренче мизгелендә күренгән сабырлык...».* Чөнки кайгыдан соң вакыт узып беленгән сабырлыкта, кеше инде тынычланган була. Шулай ук, кеше кайгы өчен савапка лаек булмый, чөнки кайгы аның теләге белән түгел, ә бәлки ошбу кайгыда ныклы вә күркәм сабырлы булуы өчен әҗер-саваплы була.

## Сабырлык – идарәлек һәм имамлыкның бер шарты

Иң әүвәл сабырлык белән сыйфатланырга тиеш булган кешеләр: Әмирләр, патшалар, галимнәр һәм имамнар. Чөнки аларның эшләре сабырлык белән бәйле, һәм җәмгыятьнең уңышка яки уңышсызлыкка ирешүенең дә бер сәбәбе, аларның сабыр булуларында. Моның шулай булуын шәргый нусуслар, тарихтагы һәм тормыштагы тәҗрибәләр исбатлый.

(وَلَقَدْ آتَيْنَا مُوسَى الْكِتَابَ فَلَا تَكُنْ فِي مِرْيَةٍ مِنْ لِقَائِهِ وَجَعَلْنَاهُ هُدًى لِبَنِي إِسْرَائِيلَ ۞ وَجَعَلْنَا مِنْهُمْ أَئِمَّةً يَهْدُونَ بِأَمْرِنَا لَمَّا صَبَرُوا وَكَانُوا بِآيَاتِنَا يُوقِنُونَ) السجدة: ٢٣ ـ ٢٤

Мәгънәсе: **«Тәхкыйк, Мусага Тәүратны бирдек, инде син Муса белән очрашуыгызда шик тотма, Тәүратны Бәнү Исраильгә һидәят итеп кылдык. Вә алардан имамнар, галимнәр кылдык, алар сабыр булып вә аятьләребезгә ышанып Тәүраттагы Безнең хөкемнәребез белән гамәл кылалар иде, үзләре һидәяттә булып башкаларны да һидәяткә күндерәләр иде».**

Бу аятьтән күренгәнчә, сабырлык — Аллаһ китабы белән һидәяттә булган кешеләрне имамлык дәрәҗәсенә ирештерә. Шулай ук, Йосыф عليه السلام һәм аның кардәшләре хакында Аллаһ тәгалә болай диде:

(قَالُوا أَئِنَّكَ لَأَنْتَ يُوسُفُ قَالَ أَنَا يُوسُفُ وَهَذَا أَخِي قَدْ مَنَّ اللَّهُ عَلَيْنَا إِنَّهُ مَنْ يَتَّقِ وَيَصْبِرْ فَإِنَّ اللَّهَ لَا يُضِيعُ أَجْرَ الْمُحْسِنِينَ) يوسف: ٩٠

Мәгънәсе: **«Сорадылар: «Син әллә Йосыфмы?». Йосыф әйтте: «Әлбәттә, мин Йосыфмын, ә ошбу минем кардәшем, тәхкыйк Аллаһ безгә нигъмәт вә дәрәҗәләр бирде. Берәү Аллаһка тәкъвалык кылып башына**

**килгән бәла-казаларга сабыр итсә, әлбәттә, Аллаһ мөхсиннәрнең (изге гамәл кылучыларның) әҗерен юкка чыгармый».**

Бу аятьтән мәгълүм булганча Аллаһ тәгалә Йосыфка ﷺ дәүләт идарәлеге мәртәбәсен, тәкъвалык вә сабырлыктан соң бүләк итте.

(وَأَوْرَثْنَا الْقَوْمَ الَّذِينَ كَانُوا يُسْتَضْعَفُونَ مَشَارِقَ الْأَرْضِ وَمَغَارِبَهَا الَّتِي بَارَكْنَا فِيهَا وَتَمَّتْ كَلِمَةُ رَبِّكَ الْحُسْنَى عَلَى بَنِي إِسْرَائِيلَ بِمَا صَبَرُوا وَدَمَّرْنَا مَا كَانَ يَصْنَعُ فِرْعَوْنُ وَقَوْمُهُ وَمَا كَانُوا يَعْرِشُونَ) الأعراف: ١٣٧

Мәгънәсе: **«Фиргавен заманасында зәгыйфь саналган Бәнү Исраильне мәшрикъ тарафында булган вә мәгъриб тарафында булган җирләргә хуҗа кылдык (Мисыр һәм Шәм җирләре), ул шәһәрләрне без бәрәкәтле кылдык һәм Бәнү Исраиль сабыр иткәннәре өчен аларга Аллаһ тарафыннан вәгъдә ителгән яхшы сүзләр вә ярдәм тәмам булды** (128 аятьтә вә шулай ук әл-Касас сүрәсендәге 5-6нче аятьтә әйтелгән вәгъдә)**. Фиргавен вә кавеме төзегән төзелешләрне һәм күтәреп ясаган биналарны һәлак иттек».**

Бәнү Исраиль кавеме, Фиргавен һәм аның гаскәре тарафыннан кимсетелгән, түбәнсетелгән вә зәгыйфьләндерелгән кавем иде. Аларга Аллаһтан һидәят килде вә Раббыларының әмерләренә буйсындылар, һәм Аллаһ ризалыгын өмет итеп, авырлыкларга вә газапларга сабыр иттеләр. Аллаһ тәгалә аларны дошманнар кулыннан саклады, идарәлек вә җитәкчелек биреп, аларны бәрәкәтле җирләрдә хөкем итүдә билгеләде. Моның сәбәбен бәян кылып **«сабыр иткәннәре өчен»,** — диде.

## Сабырлык – дәгъватчыларның (Аллаһка чакыручыларның) күркәм холыкларының асылы

Аллаһка вә Исламга чакыручы кеше сабырлык белән сыйфатланырга тиеш, әгәр дә аның сабырлыгы булмаса, ул дәгъватында уңышка ирешә алмый. Моны барча дәгъватчы да яхшы белә, чөнки сабырлык — Аллаһка өндәүче пәйгамбәрләр сыйфаты. Алар барчасы да бу юлда искиткеч зур вә күркәм сабырлык мисалы күрсәттеләр һәм үзләренә йөкләнгән, бер Аллаһка чакыруда, уңышларга ирештеләр.

Нухның ﷺ кавеменә сабырлыгы:

Нух ﷺ кавемен 950 ел буе Аллаһка чакырып искиткеч сабырлык күрсәтте. Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәндә болай диде:

(وَلَقَدْ أَرْسَلْنَا نُوحًا إِلَى قَوْمِهِ فَلَبِثَ فِيهِمْ أَلْفَ سَنَةٍ إِلَّا خَمْسِينَ عَامًا فَأَخَذَهُمُ الطُّوفَانُ وَهُمْ ظَالِمُونَ ۞ فَأَنْجَيْنَاهُ وَأَصْحَابَ السَّفِينَةِ وَجَعَلْنَاهَا آيَةً لِلْعَالَمِينَ) العنكبوت: ١٤ ـ ١٥

Мәгънәсе: **«Тәхкыйк, Нухны кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрдек, ул кавеме эчендә аларны дингә өндәп тугыз йөз илле ел торды, кавеме исә иман китермичә залим булдылар һәм аларны Туфан суы тотты. Әмма Нухны вә аның белән бергә көймәдә булган мөэминнәрне Туфан суыннан коткардык, вә Без бу эшне бөтен галәмгә зур гыйбрәт кылдык».**

(قَالَ رَبِّ إِنِّي دَعَوْتُ قَوْمِي لَيْلًا وَنَهَارًا ۞ فَلَمْ يَزِدْهُمْ دُعَائِي إِلَّا فِرَارًا ۞ وَإِنِّي كُلَّمَا دَعَوْتُهُمْ لِتَغْفِرَ لَهُمْ جَعَلُوا أَصَابِعَهُمْ فِي آذَانِهِمْ وَاسْتَغْشَوْا ثِيَابَهُمْ وَأَصَرُّوا وَاسْتَكْبَرُوا اسْتِكْبَارًا ۞ ثُمَّ إِنِّي دَعَوْتُهُمْ جِهَارًا ۞ ثُمَّ إِنِّي أَعْلَنْتُ لَهُمْ وَأَسْرَرْتُ لَهُمْ إِسْرَارًا

﴿فَقُلْتُ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ إِنَّهُ كَانَ غَفَّارًا﴾ نوح: ٥ ـ ١٠

Мәгънәсе: **«Нух әйтте: «Әй, Раббым, мин кавемемне Ислам диненә кичләрен дә, вә көндезләрен дә чакырдым. Минем өндәвем аларны Ислам диненнән качуны гына арттырды. Әй, Раббым, һәркайчан мин аларны Синең ярлыкавыңа, гафу итүеңә чакырсам, минем сүземне ишетмәс өчен бармакларын колакларына тыгалар һәм киемнәренә бөркәнделәр, вә көферлектә дәвам иттеләр һәм каты тәкәбберләнү илә тәкәбберләнделәр. Моннан соң мин аларны ачык рәвештә чакырдым. Сонра Исламга чакыруымны барчасына да ачык игълан кылдым, вә шулай ук яшерен генә берәм-берәм аулакта да өндәп карадым. Һәм әйттем аларга: Тәүбә итеп, Раббыгыздан истигъфар кылыгыз, гафу сорагыз, шиксез, Ул гөнаһларны ярлыкаучы».**

Ибраһимның ﷺ сабырлыгы:

Ибраһим ﷺ шулай ук Аллаһка чакыру юлында утка ыргытылудан да курыкмыйча вә зарланмыйча, искиткеч сабырлык мисалы күрсәтте. Аллаһ тәгалә аңа зур могъҗиза күрсәтеп, ул ыргытылган утны аның өчен суык вә имин кылды.

﴿قُلْنَا يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَى إِبْرَاهِيمَ﴾ الأنبياء: ٦٩

Мәгънәсе: **«Әйттек: «Әй, ут! Ибраһимгә салкын вә сәламәт бул», — дип».**

Аллаһ Сөбхәнәһү вә тәгалә пәйгамбәребезгә ﷺ Исламны иң күркәм рәвештә кешеләргә җиткерүдә, расүлләрдән булган «Үлү әл-Газм» (базымлы, сабырлык вә кыюлык хуҗалары) кебек сабыр булырга әмер итте. Бу әмер динне таратуда барча дәгъватчыга да кагыла, чөнки без барыбыз да пәйгамбәребездән ﷺ

үрнәк алып, яшәешебездә аңа охшарга тырышырга тиешбез.

(فَاصْبِرْ كَمَا صَبَرَ أُولُو الْعَزْمِ مِنَ الرُّسُلِ وَلَا تَسْتَعْجِلْ لَهُمْ كَأَنَّهُمْ يَوْمَ يَرَوْنَ مَا يُوعَدُونَ لَمْ يَلْبَثُوا إِلَّا سَاعَةً مِنْ نَهَارٍ بَلَاغٌ فَهَلْ يُهْلَكُ إِلَّا الْقَوْمُ الْفَاسِقُونَ) الأحقاف: ٣٥

Мәгънәсе: **«Әй Мөхәммәд! Кавемеңнең төрлечә каршылык күрсәтүләренә пәйгамбәрләрнең «Үлү әл-Газмнары» (базымлы вә каты чыдамлылары) чыдаган кебек сабыр ит, нык чыдамлы бул, вә аларга (сине ялганга тотып иза кылган кавемеңә) газапны ашыктырып сорама! Кәферләр үзләренә вәгъдә ителгән газабны күргәч, гүя дөньяда көндезен бер генә сәгать тордык, дип уйларлар. Ошбу Коръән, пәйгамбәрнең Аллаһтан кешеләргә ирештермәгедер, алар һәлак булмас, мәгәр Коръән илә гамәл кылмаучы фасыйклар һәлак булырлар».**

Аллаһ тәгалә бу аятьтә пәйгамбәребезгә ﷺ, аны ялганга тоткан вә иза кылган кавеменә газап сорауны ашыктырмаска кушты. Чөнки халыкларның йөзәрләгән еллар көферлектә булып урнашкан гадәтләренә, гакыйдәләренә вә аңлаешларына каршы килгән яңалыкны тиз генә кабул итү авыр, шуның өчен ул дәгъват күпмедер вакытка вә тырышлыкка мохтаҗ, һәм бу иллә-мәгәр сабырлык белән генә мөмкин. Аллаһ тәгаләнең хикмәте белән билгеләнгән тиешле вакыт узгач, һәм адашкан кавемнәр хаклыкны кабул итмичә үзләренең көферлекләрендә кала биреп җир йөзендә бозыклык вә фәсәд таратуларын дәвам иткәч, Аллаһ тәгалә аларга азга гына да кичектермичә тиешле гадел газапны бирә. Моңа ошбу ишарәт итә: **«Кәферләр үзләренә вәгъдә ителгән газапны күргәч, гүя дөньяда көндезен бер генә сәгать тордык, дип уйлар-**

**лар. Ошбу Коръән, пәйгамбәрнең Аллаһтан кешеләргә ирештермәгедер, алар һәлак булмас, мәгәр Коръән илә гамәл кылмаучы фасыйклар һәлак булырлар».**

Аллаһ тәгалә хак дингә чакыручыларны сабыр булырга өндәп, Үзенең расүленә болай диде:

(ادْعُ إِلَى سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ وَجَادِلْهُمْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ إِنَّ رَبَّكَ هُوَ أَعْلَمُ بِمَنْ ضَلَّ عَنْ سَبِيلِهِ وَهُوَ أَعْلَمُ بِالْمُهْتَدِينَ ۞ وَإِنْ عَاقَبْتُمْ فَعَاقِبُوا بِمِثْلِ مَا عُوقِبْتُمْ بِهِ وَلَئِنْ صَبَرْتُمْ لَهُوَ خَيْرٌ لِلصَّابِرِينَ ۞ وَاصْبِرْ وَمَا صَبْرُكَ إِلَّا بِاللَّهِ وَلَا تَحْزَنْ عَلَيْهِمْ وَلَا تَكُ فِي ضَيْقٍ مِمَّا يَمْكُرُونَ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ) النحل: ١٢٥ ــ ١٢٨

Мәгънәсе: **«Раббыңның юлы булган Ислам диненә кешеләрне хикмәт вә тәэсирле яхшы вәгазьләр белән чакыр! Дәхи кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен алар белән иң күркәм юл белән бәхәсләш! Әлбәттә, синең Раббың Аның юлыннан адашкан кешеләрне белә; һәм Ул Коръән юлында булган хак мөэминнәрне дә белә. Әгәр бер кешегә, үч алып газаб бирергә теләсәгез, ул сезгә газаб биргән хәтле генә аңа газаб бирегез! Анықыннан арттырмагыз, бер мәртәбә сугучыга ике мәртәбә сукмагыз! Әгәр үч алмыйча сабыр итеп калсагыз, сабыр итүчеләр өчен бу бик тә хәерледер! Сабыр итү хәерле булгач, сабыр ит! Мәгәр сабыр итә алмассың, фәкать Аллаһ тәгалә сабырлык куәтен бирсә генә сабыр итә алырсың! Һәм кәферләрнең Исламга килмәгәннәре өчен үзеңне кайгыга салма, вә аларның хәйлә-мәкерләре өчен күңелең тарыкмасын! Тәхкыйк, Аллаһ Коръән хөкемнәренә хыйлафлык кылудан сакланучы тәкъва кешеләр белән һәм яхшылык вә изге гамәлләр кылучы хак мөселманнар белән бергәдер».**

Аллаһ тәгалә тарафыннан пәйгамбәребезгә ﷺ сабыр булырга кушылган әмер, Исламга чакыручы

барча мөселманга да кагыла. Бу аятьтән күренгәнчә пәйгамбәребезнең ﷺ кавеме белән булган урыны дүрт нәрсәдә билгеләнә:

**1. Кавемен Аллаһка чакыру**, һәм бу чакыру гади рәвештә генә түгел, ә бәлки хикмәт вә яхшы вәгазь белән булырга тиешле. Шулай ук, әгәр дә алар белән бәхәс булса, ул да күркәм вә яхшы рәвештә булырга тиеш. Моңа бу аятьтә ошбу ишарәт итә: **«Раббыңның юлы булган Ислам диненә кешеләрне хикмәт вә тәэсирле яхшы вәгазьләр белән чакыр! Дәхи кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен алар белән иң күркәм юл белән бәхәсләш!».**

**2. Кавеме тарафыннан күргән иза вә авырлыклар белән бәйле күренеш.** Бу вакытта Аллаһ тәгалә аларга карата ике төрле чара кулланырга рөхсәт итүе билгеле: **Беренчесе:** Гаделлек белән эш итү. **Икенчесе:** Ихсанлык белән эш итү. Иза кылган кешеләргә гаделлек белән эш кылу; арттырмыйча алар иза кылган кебек кенә иза кылу. Чөнки Аллаһ тәгалә: **«Әгәр бер кешегә үч алып, газап бирергә теләсәгез, ул сезгә газап биргән хәтле генә аңа газап бирегез! Анрыкыннан арттырмагыз, бер мәртәбә сугучыга ике мәртәбә сукмагыз!»,** – дигән мәгънәдә әйтте. Ләкин моңа карамастан ихсанлык күрсәтү хәерлерәк вә яхшырак дип бәян кылды вә ихсанлыкка өндәде. Ихсанлык сабырлык белән килә, һәм шуннан соң гына явызлыкларны гафу итәргә мөмкин, моңа аятьнең ошбу мәгънәсе ишарәт итә: **«Әгәр үч алмыйча сабыр итеп калсагыз, сабыр итүчеләр өчен бу бик тә хәерледер! Сабыр итү хәерле булгач, сабыр ит! Мәгәр сабыр итә алмассың, фәкать Аллаһ тәгалә сабырлык куәтен бирсә генә сабыр итә алырсың!».** Авырлыкларга сабыр итү фәзыйләтен,

Аллаһка сыгынып һәм сабырларга әзерләнгән әҗер-савапны өмет итеп үзеңдә булдырырга мөмкин.

**3. Кавеменең хаклыкны кабул итмәгәнлегенә карата булган пәйгамбәребезнең ﷺ рухи хәле.** Барча ысуллар белән дә чакырып, хаклыкны кабул итмичә кавеменең көферлектә калганнарына Аллаһ тәгалә пәйгамбәребезгә ﷺ кайгырмаска кушты, һәм бу хакта мондый мәгънәдә әйтте: **«Һәм кәферләрнең Исламга килмәгәннәре өчен үзеңне кайгыга салма».**

**4. Кәферләрнең пәйгамбәребезгә ﷺ каршы корган төрле мәкерлекләренә карата булган хәле.** Моңа карата Аллаһ тәгалә Үзенең расүленә борчылмаска кушты, чөнки Ул аны ярдәмсез калдырмаячак вә кәферләрнең мәкерлекләрен юкка чыгарачак. Бу хакта болай диелде: **«Аларның хәйлә-мәкерләре өчен күңелең тарыкмасын! Тәхкыйк, Аллаһ, Коръән хөкемнәренә хыйлафлык кылудан сакланучы тәкъва кешеләр белән һәм яхшылык вә изге гамәлләр кылучы хак мөселманнар белән бергәдер».**

Пәйгамбәребезгә карата әйтелгән бу юлламалар, Аллаһ юлына чакыручы барча мөселманга да кагыла, шуңа да һәрбер мөселман мөмкинчелегеннән килгәнчә башкаларны Исламга чакырырга тиеш.

**Аллаһка чакыручылар бу изге юлда авырлыкларга очраганнан соң, төшенкелеккә бирелеп өметләрен өзмәскә тиеш:** Аллаһка чакыручының вазыйфасы кешеләрне һидәяткә кертү яки мәҗбүриләү түгел, бәлки аларга хаклыкны җиткерү вә аңлатудыр. Шуңа да Раббысының ризалыгын вә ахирәтне тәлап иткән кеше, әгәр дә Исламга чакыру юлында авырлыкларга очрый икән, төшенкелеккә бирелеп күңеле кайтмаска тиеш. Төшенкелеккә бирелеп күңелнең кире кайтуы вә өметнең өзелүе шәйтан вәсвәсәсеннән, һәм бу сыйфат

дөрес гакыйдәле вә ныклы иманлы мөселманга муафыйкъ түгел. Шуңа да, Ибраһим ﷺ аны бала белән шатландырган Аллаһ илчеләре булган фәрештәләргә болай диде:

(قَالَ وَمَنْ يَقْنَطُ مِنْ رَحْمَةِ رَبِّهِ إِلَّا الضَّالُّونَ) الحجر: ٥٦

Мәгънәсе: **«Ибраһим әйтте: «Әлбәттә, мөэмин бәндә Раббысының рәхмәтеннән өмет өзмәс, мәгәр адашкан кешеләр генә өмет өзәрләр».**

Шулай ук, Ягъкуп ﷺ балаларына болай диде:

(يَا بَنِيَّ اذْهَبُوا فَتَحَسَّسُوا مِنْ يُوسُفَ وَأَخِيهِ وَلَا تَيْئَسُوا مِنْ رَوْحِ اللَّهِ إِنَّهُ لَا يَيْئَسُ مِنْ رَوْحِ اللَّهِ إِلَّا الْقَوْمُ الْكَافِرُونَ) يوسف: ٨٧

Мәгънәсе: **«Әй улларым, Мисыр шәһәренә барып Йосыф вә аның кардәше турында сораштырып карагыз, алар хакында берәр хәбәр булмасмы, Аллаһ рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез! Дөреслектә, Аллаһ рәхмәтеннән кәферләрләр генә өметләрен өзәләр».**

Бу дөнья мәсъәләсендә, кешеләрне хаклыкка өндәп Аллаһ диненә, һидәяткә чакыруда бертөрле өметсезлек, күңелнең кире кайтуы турында сүз дә булу мөмкин түгел.

Ислам дине тарала башлаганда барча дөньяда фәсәд вә адашу иде. Шулай ук, барча матди көч кәферләр вә явызлар кулында булды. Аллаһ юлына чакыручы беренче мөэминнәр бармак белән генә санарлык булып, кәферләрдән барча төрле газапларны күрделәр. Ләкин: «Көч вә мал явызлар кулында һәм без көчсез», — дип төшенкелеккә бирелмәделәр вә Аллаһның рәхмәтеннән өметләрен өзмәделәр, бәлки Аның ризалыгы өчен сабыр булып, Аллаһтан ярдәм буласына ныклы иман белән ышандылар һәм җиңделәр.

Хәзерге көндә, кайбер мөселманнар иманнарының зәгыйфьлеге сәбәпле, төшенкелеккә биреләләр, һәм Исламның киләчәктә бердәнбер дин булачагына өметләрен өзеп, башка мөселманнарга да шик-шөбһә салалар. Болар барчасы да шәйтан вәсвәсәсе. Әйе, дин дошманнары Ислам дине нурын сүндерер өчен иксез-чиксез акчалар, байлыклар түгәләр. Ләкин ничәмә меңнәр ел батыл белән хаклык арасында көрәш баруга карамастан, кәферләр Аллаһ тәгаләнең нурын сүндерә алмаячаклар, ә бәлки ул нур көннән-көн арта вә зурая гына бара. Хәзерге көндә дә дөньяның төрле почмакларында хәерле кешеләр, көчле мөэмин-мөселманнар бик күп, әлһәмдүлилләһ. Шулай ук, күп кенә кешеләр хаклыкны, Исламны кабул итәргә әзерләр, бәлки Аллаһка тәвәккәллек кылып, Аннан һидәят сорап, ихласлылык вә сабырлык белән дәгъват кылырга вә гамәл итәргә генә кала.

## Садака, сабырлык, теләнчелек һәм ният хакында

٢٣٢٥ - عنِ أبي كبشة الأنماري أنه سمع رسول الله ﷺ يقول: «ثَلاَثَةٌ أُقْسِمُ عَلَيْهِنَّ وَأُحَدِّثُكُمْ حَدِيثًا فَاحْفَظُوهُ». قَالَ: «مَا نَقَصَ مَالُ عَبْدٍ مِنْ صَدَقَةٍ وَلاَ ظُلِمَ عَبْدٌ مَظْلِمَةً فَصَبَرَ عَلَيْهَا إِلاَّ زَادَهُ اللَّهُ عِزًّا وَلاَ فَتَحَ عَبْدٌ بَابَ مَسْأَلَةٍ إِلاَّ فَتَحَ اللَّهُ عَلَيْهِ بَابَ فَقْرٍ أَوْ كَلِمَةً نَحْوَهَا وَأُحَدِّثُكُمْ حَدِيثًا فَاحْفَظُوهُ قَالَ: «إِنَّمَا الدُّنْيَا لأَرْبَعَةِ نَفَرٍ عَبْدٍ رَزَقَهُ اللَّهُ مَالاً وَعِلْمًا فَهُوَ يَتَّقِى فِيهِ رَبَّهُ وَيَصِلُ فِيهِ رَحِمَهُ وَيَعْلَمُ لِلَّهِ فِيهِ حَقًّا فَهَذَا بِأَفْضَلِ الْمَنَازِلِ وَعَبْدٍ رَزَقَهُ اللَّهُ عِلْمًا وَلَمْ يَرْزُقْهُ مَالاً فَهُوَ صَادِقُ النِّيَّةِ يَقُولُ لَوْ أَنَّ لِى مَالاً لَعَمِلْتُ بِعَمَلِ فُلاَنٍ فَهُوَ بِنِيَّتِهِ فَأَجْرُهُمَا سَوَاءٌ وَعَبْدٍ رَزَقَهُ اللَّهُ مَالاً وَلَمْ يَرْزُقْهُ عِلْمًا فَهُوَ يَخْبِطُ فِى مَالِهِ بِغَيْرِ عِلْمٍ لاَ يَتَّقِى فِيهِ رَبَّهُ وَلاَ يَصِلُ فِيهِ رَحِمَهُ وَلاَ يَعْلَمُ لِلَّهِ فِيهِ حَقًّا فَهَذَا بِأَخْبَثِ الْمَنَازِلِ وَعَبْدٍ لَمْ يَرْزُقْهُ اللَّهُ مَالاً وَلاَ عِلْمًا فَهُوَ يَقُولُ لَوْ أَنَّ لِى مَالاً لَعَمِلْتُ فِيهِ بِعَمَلِ فُلاَنٍ فَهُوَ بِنِيَّتِهِ فَوِزْرُهُمَا سَوَاءٌ» رواه الترمذي وقال: هذا حديث صحيح

Мәгънәсе: Әбү Кәбшә әл-Әнмәридән ﵁, ул пәйгамбәребезнең ﷺ болай дип әйткәнен ишетте: ***«Мин (сезгә) өч әйбердә ант итәм һәм сезгә бер нәрсә әйтәм, сез аны исегездә калдырыгыз! Ант итәм, садака бирү кешенең байлыгын киметми. Әгәр бер кешегә золым кылсалар, ә ул сабыр итсә, Аллаһ һичшиксез аны гыйззәтләр. Әгәр дә кеше сорану вә теләнчелек ишеген ачса, Аллаһ һичшиксез аның каршында фәкыйрьлек ишекләрен ачар!***

***Һәм мин сезгә әйтәм, ә сез исегездә калдырыгыз: Дөреслектә, бу дөнья дүрт төрле кеше өчен: Шуларның беренчесенә Аллаһ тәгалә гыйлем һәм байлык биргән, ул байлыгында Раббысына тәкъва булган, һәм туганлык бәйләнешләрен тоткан, бу нәрсәләрдә Аллаһның хакы барлыгын белгән, мондый кеше Аллаһ каршында иң яхшы дәрәҗәләрдә булыр. Икенче төрле кешегә Аллаһ байлык бирмичә гыйлем биргән, ул үзенең ниятләрендә ихлас булып: «Әгәр мин бай булсам, фәлән кебек үк эшләр идем», — дип әйтүче, ул ниятенә карата беренче кеше кебек үк әҗерен алыр. Өченче төрле кешегә Аллаһ гыйлем бирмичә байлык биргән, ул байлыгын гыйлемсез, үзенең шәһвәтенә бирелеп сарыф иткән. Байлыгында Раббысына тәкъва булмаган һәм туганлык җепләрен тотмаган, бу байлыкта Аллаһның хакы барлыгын белмәгән. Бу төрле кеше Аллаһ каршында иң начар вә иң түбән халәттә булыр. Дүртенче төрле кешегә Аллаһ гыйлем дә, байлык та бирмәгән, һәм ул: «Әгәр минем байлыгым булса, фәлән (өченче төргә кергән кеше) кебек үк эшләр идем!», — дип уйлый, һәм ул ниятенә карата җәзасын алыр, вә өченче төрле кеше кебек үк гөнаһлары да бертигез булыр».***

Бу хәдис шәрифтә өч кагыйдә, һәм дүрт төр кешенең сыйфаты билгеләнә:

**Беренче кагыйдә:** Садака бирүдән кешенең малы (байлыгы) кимими. Чөнки Аллаһ ризалыгы өчен ихлас күңелдән садака бирүчеләрнең малы Кыямәт көнендә аңа артыгы белән кайта.

**Икенче кагыйдә:** Кемгә гаделсез рәвештә золым ителеп ул аңа сабырлык күрсәтсә, Аллаһ тәгалә ул сабыр кешенең гыйзззәтен генә арттыра.

**Өченче кагыйдә:** Әгәр дә кеше үзенә теләнчелек ишекләрен ачса — Аллаһ ул кешегә фәкыйрьлек ишекләрен генә ача. Чөнки теләнүче кеше саран һәм комагай була, хәтта ул үзенә дә, гаиләсенә дә акча-байлыгын тотарга кызгана. Малын җыйган саен аның фәкыйрьлеге арта, ул беркайчан да булганы белән канәгатьләнми, аңа ул җитми һәм тагын да күбрәк кирәк була башлый.

Хәдистә килгән дүрт төр кешенең сыйфаты:

**1)** Аллаһ тәгалә байлык һәм гыйлем белән ризыкландырган кеше. Ул байлыгында Аллаһка тәкъва булып, туганлык җепләрен токан һәм байлык белән гыйлемдә Аллаһның хакы барлыгын белгән кеше. Мондый кеше Аллаһ каршында иң хәерле кеше.

Бу төрле кеше мал һәм гыйлем туплаган һәм хикмәт белән сарыф иткән, чөнки хикмәтсез гыйлем — гыйлемгә керми, бәлки ул кеше ниндидер мәгълүматләр иясе генә була.

Аллаһка байлыкта тәкъвалык — ул, малны шәригать кушканча хәләл юл белән табып, Аллаһ ризалыгы өчен хәләлгә сарыф итү. Мондый кеше байлыгын кәсеп иткәндә дә, сарыф иткәндә дә Аллаһтан куркып вә Аның ризалыгын өмет итеп шәригать бу-

енча гамәл кыла, һәм аңа моңарда хикмәтле гыйлеме (шәригать гыйлеме, чөнки дөньяви гыйлем — гыйлем түгел) сәбәп вә ярдәм итә. Гыйлемле вә тәкъва кеше, байлыкны хәләл юл белән генә кәсеп итеп, хәләл юлга гына сарыф итә, һәм туганлык җепләрен ныгытуда да аңа ошбу малы һәм гыйлеме зур сәбәп була.

**2)** Икенче төрле кешегә Аллаһ байлык бирмичә гыйлем биргән, ул үзенең ниятләрендә ихлас булып: «Әгәр мин бай булсам, фәлән кебек үк эшләр идем», — дип әйтүче. Бу төрле кешенең байлыгы булмаса да, ләкин ул гыйлем вә хикмәт иясе һәм ул ихлас ниятенә карата беренче кеше кебек үк әҗерен ала.

**3)** Өченче төрле кешегә Аллаһ гыйлем бирмичә байлык биргән, ул байлыгын гыйлемсез, үзенең шәһвәтенә бирелеп сарыф иткән. Байлыгында Раббысына тәкъва булмаган һәм туганлык җепләрен тотмаган, бу байлыкта Аллаһның хакы барлыгын белмәгән. Бу төрле кеше Аллаһ каршында иң начар вә иң түбән халәттә булыр. Бу төр кешенең байлыгы бар, әмма ләкин аның ошбу байлыкны хәләл юл белән кәсеп һәм сарыф итүдә гыйлеме дә хикмәте дә юк. Ул Аллаһтан курыкмыйча, хәләлне хәрамнан аермыйча мал туплый, шулай ук ул байлыкны исраф кылып, хәләлгәме әллә хәрамгамы булганын да уйламыйча үзенең шәһвәтләренә бирелеп гөнаһлы эшләргә сарыф итә. Әгәр дә аңа хәерле вә изге эшкә акча бирергә кушсаң яки сорасаң, ул саранлана, акчам юк,— дип мескенләнә һәм шулай мал-байлык җыя-җыя, аңа бирелгән ул байлыкта Аллаһ тәгаләнең хакы бар икәнлекне белмичә яки белергә теләмичә үлеп китә. Үзеннән соң балаларына фетнә вә талаш калдыра, чөнки андый тупланган байлыкта бер төрле бәрәкәт тә булмый.

Мондый төр кеше иң кабахәт кеше һәм Аллаһ каршында да иң начар вә түбән дәрәҗәдәдер. Чөнки аңа Раббысы тарафыннан бирелгән байлыкны иң явыз рәвештә, гыйлемсез вә хикмәтсез кулланып адашуда була.

**4)** Дүртенче төрле кешегә Аллаһ гыйлем дә, байлык та бирмәгән, һәм ул: «Әгәр минем байлыгым булса, фәлән (өченче төргә кергән кеше) кебек үк эшләр идем!», — дип уйлый, һәм ул ниятенә карата җәзасын ала, вә өченче төрле кеше кебек үк гөнаһлары да бертигез була.

Бу төрле кеше ахмаклыкның иң югары дәрәҗәсендә. Чөнки ул җәһилләр кебек акылсыз, гыйлемсез вә хикмәтсез булган байлык вә көч иясе булуын, һәм алар кебек шәһвәткә бирелеп кабахәт гамәлләр кылуны тели. Бу төр кеше алдагы кеше кебек үк гөнаһлар вә явызлыклар иясе, һәм ниятләре өчен җәзаны да аның кебек бертигез ала, чөнки аның мал-байлыгы булса, ул өченче төр кешенең явызлыкларыннан бер дә ким кылмас иде.

# Яланбаш намаз уку хакында

Бездә, Хәнәфиләрдә, вәҗиб гамәлне юри калдыру мәкруһ тәхримгә керә, ә инде намазда намаз укучы сөннәтне юри калдырса яки намазда вакытта күндәмлекне һәм буйсынучанлыкны юкка чыгара торган гамәл эшләсә, мәкруһ санала. Ошбу төргә яланбаш намаз уку да керә, чөнки башка кимичә намаз уку — намазга зиннәтләнегез дигән әмерне үтәмәүгә керә.

(يَا بَنِي آَدَمَ خُذُوا زِينَتَكُمْ عِنْدَ كُلِّ مَسْجِدٍ وَكُلُوا وَاشْرَبُوا
وَلَا تُسْرِفُوا إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ) الأعراف: ٣١

Мәгънәсе: **«Әй, Адәм балалары! Һәр мәчеттә намазга зиннәтле киемнәрегезне алып киегез...».**

٢١٧٧ - عن ابن عمر رضي الله عنهما قال: قال رسول الله صلى الله عليه و سلم: «إذا صلى أحدكم فليلبس ثوبيه ، فإن الله أحق من يزين له». (أخرجه الطحاوي في «شرح معاني الآثار»، قال الألباني في "السلسلة الصحيحة - ١٣٦٩" )

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр берәрегез намаз укырга теләсә (гаурәтләрен каплап, матур) киемнәрен кисен, хакыйкатьтә, Аллаһ өчен зиннәтләнү (башкалар өчен зиннәтләнүдән) әүвәлерәк».***

Ошбулардан чыгып, гыйлем әһелләре башны каплауны зиннәткә керә диделәр. Шәйх Әлбәний «Тәмәм әл-миннә фи-т-тәгълик галә фикһ әс-сүннә» китабында башка кимәүне тәнкыйтьләп узды. Мөселман, Раббысы каршына намазга басканда, пәйгамбәребез ﷺ кебек иң күркәм хәлдә басарга тиеш.

Ә инде башка киеп укыганчы яланбаш намаз уку яхшырак диючеләр, яки зәгыйфь хәдис кулландылар, яки инде бу мәсьәләгә туры килмәгән мәгънә белән

аңлаттылар. Без сезгә аларның кайберләрен искә алып узарбыз:

Яланбаш намаз укырга рөхсәт итүчеләр Бохарида (275) Әбү Һүрайрадан ﵁ килгән: ***«Һәм ул (пәйгамбәребез ﷺ) өенә кайтып госел коенгач безнең янга (намазга) чыкты, һәм аның башыннан су тамчылары тамып тора иде»,*** — дигән хәдисне дәлил итеп китерделәр. Ләкин, бу хәдистә пәйгамбәребезнең ﷺ яланбаш булганлыгына бер ишарәт тә юк, чөнки башка киелгән булса да аннан су тамчылары тамуы мөмкин, бигрәк тә әгәр ул вакытлардагы гадәт кебек чәч озын булса.

روى ابن عساكر عن ابن عباس: «أن النبي صلى الله عليه وسلم كان ربما نزع قلنسوته فجعلها سترة بين يديه». (ضعفه الشيخ الألباني في الضعيفة ٢٥٣٨)

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵁: ***«Пәйгамбәребез ﷺ (намаз укыганда) үзенең баш киемен салып алдына куя иде».***

Бу хәдис зәгыйфь, хәтта дөрес булган очракта да яланбаш намаз укуны хуплый дигәнгә дәлил түгел, чөнки намаз укучының алдында ким дигәндә ияр кашы кадәр әйбер булырга тиешлеген бәян итеп сахих хәдисләр килде.

و أما حديث علي رضي الله عنه مرفوعا : «ائتوا المساجد حسرا ومعصبين فإن العمائم تيجان المسلمين» (فهو ضعيف جدا من رواية ميسرة بن عبد ربه و هو وضاع، ضعفه الشيخ الألباني في الضعيفة ١٢٩٦)

Шулай ук, Галидән ﵁ риваять ителгән, мәгънәсе: ***«Мәчетләргә яланбаш яки башларыгызга кигән хәлдә килегез, хакыйкатьтә чалма мөселманның тажы»,*** — дигән хәдис, бик тә зәгыйфь.

Ә инде яланбаш намаз укучыны хажда ихрам хәлендә булган кешегә кыяс кылу (охшату) дөрес түгел. Чөнки хаҗның башка гыйбәдәтләрдән аерым булган үзенең хөкемнәре бар.

**Нәтиҗә:**

Шулай итеп яланбаш укуны хуплаучылар бу мәсьәләгә кагылышлы бер төрле хас дәлил дә китермәделәр. Ә инде моңа карата хас дәлил булмагач, бу мәсьәлә гомуми, һәр мәчеттә намазга зиннәтләнү, дәлиле астында кала. Шуңа да яланбаш намаз уку мәкруһ була, Аллаһу әгъләм.

# Оекбашка (носкига) мәсех кылырга ярыймы?

Бу мәсьәләне аңлатыр өчен иң беренче без гарәп телендә билгеле булган җәүрабның һәм бездәге оекбашның (носкиның) нәрсә икәнлеген аңлатып узарбыз.

Бездәге оекбаш йон яки мамык җептән бәйләнә һәм йока булу сәбәпле аңа су үтеп керә вә үзе генә итексез, салкыннан яки яңгырдан сакламый. Ә гарәпчәдәге «җәүраб» калын йоннан тукылып аякның башыннан алып балтырга кадәр каплый торган була. Ул калын булу сәбәпле аның үзен генә киеп шактый гына йөрергә мөмкин, сынмый, бөгелми, таш яки чәнечкеләрдән саклый һәм шулай ук аңа су үтеп керми. Бездәге киез итеккә тиң аяк киеме була. (әл-Камус әл-Фикъһий, әл-Ифсах фи Фикһ әл-Лүгъа һ.б.ны кара)

Бу төрле аяк киеменең (җәүрабның) аскы өлеше күн-тире кебек нәрсә белән ябыштырылган булмаса яки кәвеш кебек аяк киемсез генә киелгән булса, аңа мәсех кылырга ярыймы әллә юкмы дигән мәсьәләдә гыйлем әһелләре төрле карашларга бүленделәр. Мугъний китабында (1/374) Әбү Хәнифә, Мәлик, Шәфигый һәм әл-Әүзәгый җәүрабның астында күн кебек нәрсә булмаса, аңа мәсех кылырга ярамый, чөнки аның белән җәяүләп йөреп булмый һәм ул йока оекбаш кебек диделәр. Әл-Кәсәний «әл-Бәдәигъ»та болай диде: «Әгәр дә җәүрабның аскы өлеше күн-тире белән ябыштырылган булса, яки кәвеш кебек кунычсыз аяк киеме белән киелгән булса, бездә бер капма-каршылыксыз ярый. Ә инде йока булып күн-тире ябыштырылмыйча яки кәвеш кебек аяк киемсез киелгән булса, берсүзсез мәсех кылырга ярамый. Калын һәм тыгыз булса Әбү Хәнифәдә ярамый, ә аның шәкертләре Әбү Йосыф белән Мөхәммәдтә ярый. Шулай ук Әбү Хәнифә хәзрәтләре үлер алдыннан шәкертләренең карашлары-

на кайтуы риваять ителде. Имам Шәфигыйда җәүраб тубыкка кадәр күн-тиредән булса гына мәсех кылырга ярый, ә инде аскы өлешенә күн-тире ябыштырылган булса да һәм кәвеш кебек кунычсыз аяк киеме белән киелгән булса да, мәсех кылырга ярамый».

Болардан билгеле булганча, җәүраб калын вә тыгыз булып аның белән йөрерлек мөмкинчелеге булырга тиеш.

Имам Әхмәд җәүрабка мәсех кылуны рөхсәт итеп сахәбәләрдән килгән риваятьләргә таянды. Әбү Давытта 159, Тирмизидә 327, ибен Мәҗәһдә 559 һәм башкаларда Мугыйрадан килгән хәдистә пәйгамбәребез ﷺ җәүрабка мәсех кылды дип әйтелде. Әбү Давыд тугыз сахәбәнең җәүрабка мәсех кылганнарын искә алып узды, ә әл-Зәркаший аларга тагын дүрт сахәбәне өстәп искә алды. Ләкин әйткәнебезчә алар вакытындагы җәүраб калын һәм тыгыз итеп ясалган иде. Бу хәдисне Тирмизий хәсән дисә дә, әс-Сәүрий, ибен Мәһдий, ибен әл-Мәдиний, имам Әхмәд һәм ибен әл-Каттаннар зәгыйфь дип әйтеп узды.

Мугънийда җәүрабка мәсех кылуның ике шарты искә алынып үтелде: 1) аякның шәкелен бәян итмәслек калын булырга тиеш. 2) аның белән җәяүләп йөрү мөмкинчелеге булырга тиеш. Имам Әхмәд кәвешсез киелгән җәүрабка мәсех кылуны аңлатып болай диде: «Әгәр дә ул аны киеп җәяүләп йөри ала икән һәм аягыннан төшми торган булса, аңа мәсех кылса бер зыян да юк, яки рөхсәт ителә».

Бу мәсьәләгә карата хәзерге гыйлем әһелләреннән ибен Гусаймин, шәйх Әлбәний һәм башкалар җәүрабның калын булуы шарт түгел, бәлки йока оекбаш (носки) кебек аяк киеменә дә мәсех кылу ярый, чөнки мәсех кылуның сәбәбе таһәрат алучы-

га җиңеллек китерү диделәр. Шәйх Габдуллаһ бин Җибрийн җәүрабның калын һәм тыгыз булуы шарт, чөнки сәләфләрдәге җәүрабның мәгънәсе хәзерге оекбаш яки носки мәгънәсендә түгел дигәнне хуплады. Шулай итеп, сәләфләрнең һәм күпчелек гыйлем әһелләренең карашы буенча, оекбашка һәм аңа охшаш йока аяк киемнәренә мәсех кылынмый булып чыкты, Аллаһу әгъләм.

# Тәвәссүл

**Тәвәссүл** — ул, доганың кабул булуы өчен һәм таләп ителгән нәрсәнең хакыйкатькә чыгуын эстәп, Аллаһ тәгаләгә якынаю юлы эзләү.

**Тәвәссүл ике төрле:**

**Беренчесе:** Ислам шәригате буенча рөхсәт ителгән.

**Икенчесе:** Ислам шәригате буенча тыелган.

Без, иң әүвәле Ислам шәригате буенча рөхсәт ителгән тәвәссүлне аңлатып узарбыз.

**Беренчесе:** Шәригатебездә дәлилләр белән ныгытылып килгән тәвәссүл — рөхсәт ителгән тәвәссүл була, һәм ул берничә:

**1)** Аллаһ сөбханәһү вә тәгаләгә Аның күркәм исемнәре белән гомуми яки хосусый рәвештә тәвәссүл кылу (якынаю). Гомуми рәвештә тәвәссүл кылу ул болай була: Аллаһ тәгаләнең Үзе зикер итеп узган яки пәйгамбәренә ﷺ белгерткән күркәм исемнәре бар, шушы исемнәрне гомуми рәвештә әйтеп: «Йә Раббым, Синең зикер итеп узган, яки пәйгамбәреңә белгерткән күркәм исемнәрең белән сорыйм, мине туры юлга күндер», — дип дога кылу.

Моңа дәлил булып Коръәндә бу аять килә:

(وَلِلَّهِ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَى فَادْعُوهُ بِهَا) الأعراف: ١٨٠

Мәгънәсе: **«Аллаһның күркәм исемнәре бар, шул исемнәр белән дога кылыгыз».**

Шулай ук бу хакта пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә дә килә.

Ә инде Аллаһ тәгаләнең бер тәгаенле, вә хас исемен әйтеп дога кылу, ул хосусый тәвәссүл була, мәсәлән: «Йә Аллаһ! Син гафу итүчесең, мине гафу ит!».

Монда тәвәссүл исеме догага мөнәсиб (сорауга туры килүче) булырга тиеш. Мәсәлән син: «Йә Аллаһ, Син каты газап кылучы, мине гафу ит», — дип әйтергә ярамый, бәлки «Син гафу итүче, мине гафу ит», — дию тиешледер. Моңа, яки хосусый тәвәссүлгә, имам Бохарида 834нче сан белән килгән хәдис дәлил итеп алына:

Бервакыт Әбү Бәкер Сиддыйк пәйгамбәребездән ﷺ намазда укырга дип, ана берәр дога өйрәтүен сорады, Расүлебез ﷺ Әбү Бәкергә әйтте: ***«Син әйт: Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин үземне бик зур золым белән золымладым, Синнән башка гөнаһларны ярлыкаучы юк, Үзеңнең Гафулыгың белән мине гафу ит, вә миңа рәхимлелек кыл, хакыйкатьтә Син — Гафу Итүче вә Рәхимлесең».***

**2)** Аллаһ тәгаләгә Аның сыйфатлары белән тәвәссүл кылу (якынаю). Бу шулай ук гомуми яки хосусый рәвештә була. Мәсәлән, гомуми рәвештә син: «Әй Аллаһ, мин Синең бөек сыйфатларың белән сорыйм...», — дип дога кыласың. Ә хосусый рәвештә болай була: «Аллаһның Гыйззәте вә Кодрәте белән барча начарлыклардан, Аңа сыенам». Бу тәвәссүл Аллаһның сыйфатларыннан булган «Гыйззәт» сыйфаты белән тәвәссүл кылу (Аңа якынаюдыр). Шушыңа бәйле хәдисне Мөслим риваятендә 2202нче сан белән табырга мөмкин.

**3)** Аллаһка вә Аның Расүленә ﷺ иман китереп тәвәссүл кылу. Мәсәлән: «Әй Аллаһ! Сиңа вә Расүлеңә китергән иманым белән сорыйм, мине гафу ит». Моңа дәлил итеп түбәндәге аятьләне китерергә мөмкин:

(إِنَّهُ كَانَ فَرِيقٌ مِنْ عِبَادِي يَقُولُونَ رَبَّنَا آمَنَّا فَاغْفِرْ لَنَا
وَارْحَمْنَا وَأَنْتَ خَيْرُ الرَّاحِمِينَ) المؤمنون: ١٠٩

Мәгънәсе: **«Хакыйкатьтә, Минем колларымнан бер җәмәгать әйтер булды: «Әй Раббыбыз, без Сиңа иман китердек, безне ярлыка һәм безгә рәхимлелек кыл, Син бит Рәхим Итүчеләрнең иң хәерлесесең».**

**4)** Кеше үзенең Аллаһ каршында фәкыйрьлеге вә ихтыяҗлы булуы белән Аңа тәвәссүл кылуы. Мәсәлән: «Әй Аллаһ, мин Синең каршыңда фәкыйрь вә мескен бәндәңдер, минем иманымны арттыр, вә динеңдә ныклы кыл...», һәм башкалар. Моңа дәлил итеп Коръәннән Зәкәриянең ﷺ сүзләрен китерергә мөмкин:

(قَالَ رَبِّ إِنِّي وَهَنَ الْعَظْمُ مِنِّي وَاشْتَعَلَ الرَّأْسُ شَيْبًا
وَلَمْ أَكُنْ بِدُعَائِكَ رَبِّ شَقِيًّا) مريم: ٤

Мәгънәсе: **«Әйтте (Зәкәрия ﷺ): «Әй Раббым, минем сөягем зәгыйфьләнде, вә башым ак чәчләр белән тулды, вә мин Сиңа кылган догамнан кире кайтарылучы булмадым, һәрвакыт догамны кабул кылдың».**

**5)** Тере булган бер изге-салих кешедән сиңа дога кылуын сорап Аллаһка тәвәссүл кылу. Мәсәлән, Аллаһның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, намазларын тиешенчә үтәп, хәрамнардан тыелып яшәгән бер салих кеше хаҗга яки гомрәгә барганда аңардан сиңа Гарәфәдә дога кылуын сорау, яки сәфәрдә вакытта догада булуын сорау һәм башкалар. Моңа дәлил итеп сахәбәләрнең расүлебездән ﷺ дога кылуын сорап кылган фигыльләрен китерергә мөмкин. Моңа шулай ук, Бохаридагы вә Мөслимдәге хәдисләрне китерергә була, мәгънәсе: «Пәйгамбәребез ﷺ җомга хөтбәсе сөйли иде, бер кеше аның янына килеп: «Әй Аллаһның илчесе, малларыбыз вә чәчүлекләребез һәлак булды, Аллаһтан безгә яңгыр җибәрүен сора», —

диде. Пәйгамбәребез яңгыр сорап дога кылды...» (озын хәдис, Бохари 1021, 5752. Мөслим 220, 798).

Ләкин, бу тәвәссүлдә дога кылуны таләп итеп соралган кешенең тере булуы тиеш, әмма үлгәннәрдән сорау катгый рәвештә тыела. Чөнки, ул үлгәннән соң дога кыла алмый, ә киресенчә ул мәет булгач, Аллаһтан аның гөнаһларын ярлыкавын сорап, үзенә дога кылырга кирәк.

**6)** Изге гамәлләр белән Аллаһка тәвәссүл кылу. Монда инде кеше Аллаһка дога кылганда, Аның ризалыгы өчен эшләгән изге гамәлләрен искә алып уза.

Моңа мисал вә дәлил итеп Бохарида вә Мөслимдә килгән хәдисне алырга була. Кыскача мәгънәсе: Бу хәдистә, өч кеше сәфәрдә булып төнгә калалар һәм төн уздырырга дип бер тау куышына кереп ышыкланалар. Алар керүләре була, тау тишегенең авызына зур таш төшеп, чыга торган юлны томалый. Инде алар бу ташны бергәләшеп этеп карасалар да аны селкетә дә алмыйлар. Шуннан бер-берсенә: «Үзегезнең изге гамәлләрегезне искә алып, Аллаһка ялварыгыз, дога кылыгыз, изге-салих эшләрегез белән Раббыгызга тәвәссүл итегез», — диешәләр. Һәрберсе үзенең изге гамәлен искә алып дога кыла һәм Аллаһ тәгалә аларны ошбу тау тишегеннән чыгара.

**Икенчесе:** Ислам дине буенча тыелган тәвәссүл.

Без моңа кадәр Коръәндә вә пәйгамбәребез ﷺ сөннәтендә шәргый дәлиле булып, Ислам динендә рөхсәт ителгән Аллаһка тәвәссүл кылуны аңлатып узган идек. Инде хәзер тыелган тәвәссүлне бәян кылып узарбыз.

Ул шундый тәвәссүл ки, аңа Коръәндә дә, пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтендә дә шәргый дәлил юк.

Бу тыелган тәвәссүл шулай ук берничә:

**1)** Аллаһ тәгаләгә ниндидер дә булса бер кешенең бөек дәрәҗәсе, урыны белән, яки Пәйгамбәребезнең ﷺ Аллаһ каршында булган дәрәҗәсе белән тәвәссүл кылу. Мәсәлән, бер кешенең: «Әй Аллаһ, мин Синнән расүлеңнең Синең каршында булган бөек дәрәҗәсе, хөрмәте илә сорыйм, миңа...», — дип соравы.

Пәйгамбәребез ﷺ нинди генә зур дәрәҗәдә булса да, әмма ошбу рәвештә Аллаһка тәвәссүл кылу тыелган, чөнки моңа карата бер төрле дәлил дә юк. Ә инде пәйгамбәребезнең ﷺ дәрәҗәсе, урыны белән Аллаһка тәвәссүл кылынмый икән, башка кешеләрнең дәрәҗәләре, урыннары белән тәвәссүл кылу турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Бу хакта барча дүрт имам да килешкән.

Үзебезнең Хәнәфи мәзһәбендә зур фәкыйһләрдән (галимнәрдән) булган Әбү әль-Хөсәен әль-Кудури үзенең “Шәрех әль-Кәрхий” дигән китабында болай диде: «Бишер бин әль-Вәлид әйтте (Хәнәфиләрдә мәшһүр галим): Әбү Йосыф (Әбү Хәнифәнең шәкерте) болай дип әйткәнен ишеттем: Әбү Хәнифә рәхимәһүллаһу әйтте: «Нинди генә кеше булса да, аңа Аллаһтан башка берәүдән сорау катгый рәвештә тыела».

Ә инде әйтүебезчә: «Әй Аллаһ, Синә вә Расүлеңә булган иманым белән сорыйм», — дию, рөхсәт ителә, чөнки ул Аллаһка үзенең изге гамәле белән тәвәссүл кыла, башка кешенең кылган гамәле белән түгел.

**2)** Аллаһка мәет аша тәвәссүл кылу. Бу шулай ук тыелган. Кабергә, мәет янына барып аңардан сорау, болар барсы да Ислам шәригатенә каршы килә. Сахәбәләр пәйгамбәребез ﷺ исән булганда аңардан дога кылуны сораган булсалар да, Расүлебез ﷺ вафат булганнан соң аның каберенә барып сорамаганнар, ә белүебезчә сахәбәләр пәйгамбәрләрдән ﷺ соң иң хәерле кешеләр.

**3)** Аллаһ тәгаләгә потлар, әүлияләр, төрбәләр аша тәвәссүл кылу, шулай ук шәригатебездә тыелган гамәлләрдән. Болай тәвәссүл кылу кабахәт ширки тәвәссүл. Аның асылы мөшрикләр гамәле, чөнки алар Аллаһка якынаер өчен потларга табынып алардан сорый торган иделәр. Бу хакта Аллаһ тәгалә Коръәни Кәримдә болай диде:

(أَلَا لِلَّهِ الدِّينُ الْخَالِصُ وَالَّذِينَ اتَّخَذُوا مِنْ دُونِهِ أَوْلِيَاءَ مَا نَعْبُدُهُمْ
إِلَّا لِيُقَرِّبُونَا إِلَى اللَّهِ زُلْفَى إِنَّ اللَّهَ يَحْكُمُ بَيْنَهُمْ فِي مَا هُمْ فِيهِ
يَخْتَلِفُونَ إِنَّ اللَّهَ لَا يَهْدِي مَنْ هُوَ كَاذِبٌ كَفَّارٌ) الزمر: ٣

Мәгънәсе: **«Әгаһ булыгыз! Ширектән вә риядан пакь булган дин — Аллаһка хас. Аллаһтан башка сыннарны дус тоткан мөшрикләр:» Без аларга гыйбадәт кылмыйбыз, мәгәр безне Аллаһка якын кылсыннар өчен генә аларга гыйбадәт кылабыз», — диләр. Аллаһ Кыямәт көнендә мөэминнәр илә мөшрикләр арасын дин эшләрендә ихтиләф иткәннәре өчен хөкем итәр. Дөреслектә, Аллаһ Исламга көферлек итүчене, вә ялганчыны туры юлга күндермәс».**

# Мәүлид кичәсен бәйрәм итү

**Бу бидгатьнең барлыкка килүе.**

Мөселман календаре буенча беренче, икенче, өченче гасырларда Мәүлид бәйрәме хакында бу вакыттагы тарихларда искә алынмады. Пәйгамбәребезнең ﷺ сахәбәләре дә, алардан соң килгән тәбигыйннәр дә, һәм тәбигыйннәрдән соң килгән изге сәләфләр дә, пәйгамбәребезгә ﷺ үзләренең мәхәббәтләрен белдерәбез дип мондый бәйрәм яки искә алулар үткәрмәделәр. Ә сахәбәләр белүебезчә, пәйгамбәребезне ﷺ иң яратучы кешеләр булдылар. Татар халкының күренекле шәхесе Ризаэтдин бин Фахретдин хәзрәтләре үзенең «Җәүәмигъ әль-кәлим шәрхе» китабында бу бәйрәмнең дөрес түгеллеген аңлатып каты тәнкыйтьләп язды.

**Кайдан килеп чыга соң бу бәйрәм яки искә алу?**

Кыскача гына әйткәндә, иң беренче бу искә алуны Гөбәйд Ал-Каддах төркеме башлап җибәрде. Алар үзләрен Фатымийлар дип ялганлыйлар иде. Бу вакыйга якынча 362нче һиҗри (1040нчы миләди) елларда булды. Бу төркем, Исламнан ераклашкан “Батиния” төркемен нигезләүчеләрдән иделәр. Алар мөселманнарны дөрес юлдан адаштырып, үзләренең ялганына якынайтыр өчен диндә булмаган төрле бәйрәмнәр уйлап чыгардылар, һәм мөселманнарны дөрес юлдан тайпылдыра башладылар.

**Мәүлиднең шәригатебездәге урыны.**

Динебездә пәйгамбәребез ﷺ тарафыннан күрсәтелмәгән һәм шәригатебезгә муафыйк булмаган яңа гамәл-гыйбадәткә «бидгать» дип әйтелә, һәм шәригатебездә аңа карата бер төрле дөрес дәлил дә юк. Мәүлид уздыру, шушы сәбәпле бидгать гамәл һәм бу бидгать гамәл Әбү Хәнифә, Мәлик, Шәфигый һәм Әхмәд бин Хәнбәл мәзһәбләрендә дә юк. Юк кына түгел, ә катгый

рәвештә тыела. Исламда мәшһүр булган галимнәрдән ибен Тәймия болай дип әйтте: «Мондый бәйрәмнәр яки искә алулар ике сәбәпле тыела:

**Беренчесе:** Кәферләргә охшау була. Чөнки насаралар Гыйсәнең ﷺ туган көнен бәйрәм итәләр, ә яһүдләр шулай ук үзләренең бәйрәмнәрен билгеләп узалар. Пәйгамбәребез ﷺ ул эшләрне кылмаган, ә киресенчә андый нәрсәләрдән тыйган, һәм үзенең бер хәдисендә:

«مَنْ تَشَبَّهَ بِقَوْمٍ فَهُوَ مِنْهُمْ» ( أبو داود )

Мәгънәсе: ***«Кемдә кем бер кавемгә охшарга тырышса, ул шулардандыр»,*** — дип әйтте.

**Икенчесе:** Ул бәйрәмне уздыру — бидгать һәм шәригатебезгә туры килмәгән яңа гамәл. Пәйгамбәребез ﷺ әйтүенчә:

«فَإِنَّ أَصْدَقَ الحَدِيثُ كِتَابُ اللهِ، وخيرَ الهَدْيِ هَدْيُ مُحَمَّدٍ، وشَرَّ الأُمُورُ مُحْدَثَاتُها، وكُلَّ مُحْدَثَةٍ بِدْعَةٌ، وَكُلَّ بِدْعَةٍ ضَلالَةٌ»( مسلم )

Мәгънәсе: ***«...барча яңалык — бидгать һәм барча бидгать — адашу».***

Шуңа да, шушы Җәһәннәм утына илтүче адашулардан ерак булыр өчен, без расүлебез ﷺ әйткәнчә Коръәнгә һәм аның Сөннәтенә тотынырга тиеш, шушы вакытта гына без дөньяда да, ахирәттә дә бәхеткә ирешәбез.

Сахәбәләр, тәбигыйннәр, алардан соң килгән сәләфләр һәм башка гыйлем ияләре дә мондый динебездә нигезе булмаган гамәлләрдән ерак торганнар һәм башкаларны да адашуга илтүче эшләрдән кисәткәннәр вә тыйганнар.

(وَمَنْ يُشَاقِقِ الرَّسُولَ مِنْ بَعْدِ مَا تَبَيَّنَ لَهُ الْهُدَى وَيَتَّبِعْ غَيْرَ سَبِيلِ الْمُؤْمِنِينَ نُوَلِّهِ مَا تَوَلَّى وَنُصْلِهِ جَهَنَّمَ وَسَاءَتْ مَصِيرًا) النساء: ١١٥

Мәгънәсе: **«Берәү Коръән дәлилләре белән туры юл күрсәтелеп шәригать хөкемнәре өйрәтелгәннән соң расүлгә хилафлык китергән эшләрне эшләсә, мөэминнәр юлыннан тыш башка юлны ихтыяр итсә, риза булып шул юлга керсә, әлбәттә аның күңелен шул юлга беркетербез, аннары шул юл белән Җәһәннәмгә барып керер, ул Җәһәннәм кайтачак урынның нинди яманыдыр».**

Безгә, мөселманнарга, мөселман булмаган кешеләр юлына керү (кирәк ул насара яки яһүд яки башка диндә булсын) аларның гадәтләрен үзләштерү, аларга иярү катгый рәвештә тыела.

(إِنَّمَا كَانَ قَوْلَ الْمُؤْمِنِينَ إِذَا دُعُوا إِلَى اللَّهِ وَرَسُولِهِ لِيَحْكُمَ بَيْنَهُمْ أَنْ يَقُولُوا سَمِعْنَا وَأَطَعْنَا وَأُولَئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ وَمَنْ يُطِعِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَيَخْشَ اللَّهَ وَيَتَّقْهِ فَأُولَئِكَ هُمُ الْفَائِزُونَ) النور: ٥١ - ٥٢

Мәгънәсе: **«Хак мөэминнәрнең сүзләре шул булды, әгәр Аллаһка вә Аның расүленә араларында хөкем итмәк өчен чакырсалар, «ишеттек вә итагать иттек» дип әйтерләр, әнә шундый хак мөэминнәр мәңгелек бәхеткә ирешүчеләр. Берәү Аллаһка вә расүлгә итагать итсә вә Аллаһтан курыкса һәм гөнаһлы булудан сакланса, алар бөек дәрәҗәгә ирешүчеләрдер».**

Пәйгамбәребезне ﷺ ярату — аның Сөннәтенә, ул алып килгән шәригатькә тотынудан гыйбәрәттер. Без Аллаһның расүле ﷺ юлыннан барып, ул ераклашкан һәм тыйган эшләрдән тыелып, үзебезнең мәхәббәтебезне белдерәбез.

# Гает намазы җомгага туры килсә?

Гает намазы җомга көненә туры килсә, җомга намазы укыламы әллә юкмы дигән мәсьәләдә кайбер хәдисләр вә әсәрләр килде. Без иң беренче ошбу хәдис вә әсәрләрне һәм аларның дөресме яки зәгыйфьме икәнлеген искә алып узарбыз:

**Хәдисләр:**

١٠٧٣- عَنْ أَبِى هُرَيْرَةَ عَنْ رَسُولِ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم أَنَّهُ قَالَ: «قَدِ اجْتَمَعَ فِى يَوْمِكُمْ هَذَا عِيدَانِ فَمَنْ شَاءَ أَجْزَأَهُ مِنَ الْجُمُعَةِ وَإِنَّا مُجَمِّعُونَ». (سنن أبي داود، ابن ماجه ١٣١١. إسناده ضعيف. بقية بن الوليد يدلس تدليس التسوية و لم يصرح بالتحديث في طول السند، و كذلك المغيرة بن مِقْسَم الضَّبيُّ مدلس و قد عنعن)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бу көнне сезнең ике гаетегез бергә туры килде, теләгәннәрегезнең җомгасыннан булды, без хакыйкатьтә берләштерәбез».*** Бу хәдиснең иснәде зәгыйфь.

١٥٩١- عَنْ إِيَاسِ بْنِ أَبِى رَمْلَةَ قَالَ: «سَمِعْتُ مُعَاوِيَةَ سَأَلَ زَيْدَ بْنَ أَرْقَمَ أَشَهِدْتَ مَعَ رَسُولِ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم عِيدَيْنِ؟ قَالَ: نَعَمْ، صَلَّى الْعِيدَ مِنْ أَوَّلِ النَّهَارِ ثُمَّ رَخَّصَ فِى الْجُمُعَةِ».(سنن النسائي، و أخرجه أبو داود ١٠٧٠، و ابن ماجه ١٣١٠. إسناده ضعيف من أجل إياس ابن أبي رملة، فإنه مجهول)

Мәгънәсе: Ияс бин Әбий Рамлә әйтте: «Мин ишеттем, Мугавия Зәйд бин Аркамнан: ***«Син пәйгамбәребез ﷺ белән ике гаетне бергә үткәргәнең булдымы?», — дип сорады. Зәйд бин Аркам әйтте: «Әйе, гает намазын көннең әүвәлендә (иртә белән) укыды, аннан соң җомгага рөхсәт бирде».*** (Ягъни кем гает намазын укыган булса, җомга вакыты җиткәч, тели икән җомга намазын укый, теләми икән укымый). Иснәде зәгыйфь.

١٣١٢- عَنِ ابْنِ عُمَرَ قَالَ: اجْتَمَعَ عِيدَانِ عَلَي عَهْدِ رَسُولِ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم فَصَلَّى بِالنَّاسِ ثُمَّ قَالَ: «مَنْ شَاءَ أَنْ يَأْتِىَ الْجُمُعَةَ فَلْيَأْتِهَا وَمَنْ شَاءَ أَنْ يَتَخَلَّفَ فَلْيَتَخَلَّفْ». ( سنن ابن ماجة، إسناده ضعيف لأن جُبارةُ بن المُغَلِّس و مِنْدَل بن علي ضعيفان )

Мәгънәсе: Ибен Гомәр ﵁ әйтте: «Пәйгамбәребез ﷺ вакытында ике гает бергә туры килде (гает белән җомга), ул (гает) намазын укыды һәм әйтте: ***«Кем җомгага килергә теләсә килсен, ә кем теләми икән килмәсен».*** Иснәде зәгыйфь.

**Сахәбәләрдән килгән әсәрләр:**

٥٥٧٢- قَالَ أَبُو عُبَيْد - مولى ابن أزهر - : «ثُمَّ شَهِدْتُ الْعِيدَ مَعَ عُثْمَانَ بْنِ عَفَّانَ، فَكَانَ ذَلِكَ يَوْمَ الْجُمُعَةِ، فَصَلَّى قَبْلَ الْخُطْبَةِ، ثُمَّ خَطَبَ، فَقَالَ: يَا أَيُّهَا النَّاسُ، إِنَّ هَذَا يَوْمٌ قَدْ اجْتَمَعَ لَكُمْ فِيهِ عِيدَانِ فَمَنْ أَحَبَّ أَنْ يَنْتَظِرَ الْجُمُعَةَ مِنْ أَهْلِ الْعَوَالِي فَلْيَنْتَظِرْ وَمَنْ أَحَبَّ أَنْ يَرْجِعَ فَقَدْ أَذِنْتُ لَهُ». (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Гобәйд әйтте: Мин Госман бин Гаффан вакытында гаетнең җомгага туры килгәненә шәһид булдым. Гает намазын хотбәгә кадәр укыды һәм намаздан соң хотбә кылып әйтте: ***«Әй кешеләр! Бу көнне сезгә ике гает бергә туры килде, әгәр дә Гавалий әһелләре (Мәдинә тирә-янындагы калкулыктарак урнашкан авыллар әһелләре) җомга намазын көтеп торасылары килсә — көтсеннәр, ә инде кемнең өенә кайтасы килсә — аңа рөхсәт итәм».*** Сахих.

٥٧٣١ - عبد الرزاق عن الثوري عن عبد الله عن أبي عبد الرحمن السلمي عن علي قال : «اجتمع عيدان في يوم فقال : «من أراد أن يجمع فليجمع، ومن أراد أن يجلس فليجلس» قال سفيان : «يعني يجلس في بيته». (صحيح بمجموع طرقه)

Мәгънәсе: Ике гает бер көнгә туры килгәч Гали ﵁ әйтте: ***«Кем берләштерәсе килсә — берләштерсен, ә кем өендә каласы килсә — өендә калсын».*** Сахих.

١٥٩١ - عن وَهْبُ بْنُ كَيْسَانَ قَالَ : «اجْتَمَعَ عِيدَانِ عَلَى عَهْدِ ابْنِ الزُّبَيْرِ فَأَخَّرَ الْخُرُوجَ حَتَّى تَعَالَى النَّهَارُ ثُمَّ خَرَجَ فَخَطَبَ فَأَطَالَ الْخُطْبَةَ ثُمَّ نَزَلَ فَصَلَّى وَلَمْ يُصَلِّ لِلنَّاسِ يَوْمَئِذٍ الْجُمُعَةَ فَذُكِرَ ذَلِكَ لابْنِ عَبَّاسٍ فَقَالَ أَصَابَ السُّنَّةَ». (أخرجه النسائي. أثر ابن الزبير له حكم الرفع و لكن فيه مقال)

Мәгънәсе: Үәһб бин Кәйсән әйтте: ***«Ибен Зөбәйр вакытында ике гает бергә туры килде һәм ул соңгарак калып чыкты, шуннан соң озак итеп хотбә сөйләде, аннары намаз укыды. Бу көнне кешеләр җомга укымадылар, һәм ибен Габбаска бу хәлне әйткәч, ул: «Ибен Зөбәйр сөннәт буенча кылды», — диде».*** Бу хәдиснең иснәдендә һәм мәтенендә гыйлем әһелләре арасында төрле карашлар бар.

٥٧٢٧ - عبد الرزاق عن الثوري عن الحكم عن إبراهيم قال : «يجزئ واحد منهما عن صاحبه». (مصنف عبد الرزاق، صحيح)

Мәгънәсе: Ибраһим Нәхагый әйтте: ***«(Гает белән җомга бергә туры килгәндә) кем дә кем икесенең берсен укый икән — рөхсәт ителә».*** Сахих.

٥٨٤٩ - حدثنا معاوية عن هشام قال نا سفيان عن مجالد عن الشعبي قال: «إذا كان يوم جمعة وعيد أجزأ أحدهما من الآخر». (مصنف ابن أبي شيبة، إسناده ضعيف لضعف مجالد بن سعيد)

Мәгънәсе: Шәгъбий әйтте: ***«Әгәр дә җомга белән гает бергә туры килсә, берсе икенчесен алыштыра».*** Иснәде зәгыйфь.

٥٨٤٤ - عن عطاء قال: «إذا اجتمع عيدان في يوم فأيهما أتيت أجزأك». (مصنف ابن أبي شيبة، إسناده ضعيف لضعف ليث بن أبي سليم)

Мәгънәсе: Гата бин Әбий Рабәх әйтте: ***«Әгәр дә ике гает бер көнгә туры килсә, кайсысын укысаң да дөрес була».*** Иснәде зәгыйфь.

**Гыйлем әһелләренең карашлары:**

Бу мәсьәләдә гыйлем әһелләре дүрт карашка бүленделәр:

— **Хәнәфи, Мәлики, ибен Хәзм һәм ибен әл-Мүнзир карашлары буенча,** әгәр дә гает намазы белән җомга намазы бер көнгә туры килсә, икесе дә укыла. Кем иртән гает намазын укыган икән аның өстеннән җомга намазы төшми, җомга намазы фарыз булып кала. Чөнки гает намазы сөннәт (яки вәҗиб), ә җомга намазы фарыз хөкемендә кала диделәр. Имам Шәфигый шулай ук бу карашны үзләренең шәһәрендә яки авылында җомга укылучыларга фарыз диде.

— **Имам Шәфигый һәм кайбер Мәликиләр** сахрада һәм шәһәр читендә җомга укылмый торган авыл әһелләренә шәһәргә килеп гает укысалар, аларга җомгага килмәскә рөхсәт ителә диделәр. Чөнки Госман ﵁ гает белән җомга бер көнгә туры килгәч, гает намазыннан соң хотбә сөйләгәндә андый кешеләргә рөхсәт бирде.

— **Имам Әхмәд һәм ибен Тәймия** бу мәсьәләдә мондый караштa булдылар: кем гает намазын укыган булса, аның өстеннән җомга намазы төшә (һәм аңа өйлә намазы гына тиешле була), ләкин җомга укырга теләүчеләр өчен һәм гаетне укымыйча калганнар өчен имам җомга намазын үткәрергә тиеш.

— Әгәр гает җомга белән бер көнгә туры килсә, гает намазын укыган кешенең өстеннән җомга да өйлә намазы да төшә һәм ул көнне аңа икенде намазынан

гына башлап намазлар тиешле була. Бу карашны Гата бин Әбий Рабәх ибен Зөбәйр һәм Галидан риваять кылды. Ләкин моны барча диярлек гыйлем әһелләре дә хата һәм ялгыш караш дип тәнкыйтьләп чыкты, чөнки ибен Зөбәйрдән килгән әсәрдә моны бәян иткәнлеге беленми.

**Кыскасы:**

Безгә дөресрәк дип күренгәне — ибен Тәймиянең карашы. Әгәр дә гает белән җомга бер көнгә туры килсәләр, кем гает намазын укыган булса, аңа җомгага килмәскә рөхсәт ителә, ләкин аның өстеннән өйлә намазы төшми. Кемнәр гаеткә килә алмаганнар икән, аларга җомга фарыз булып кала, һәм имам гает намазы укымаган кешеләргә вә гаетне укыган булса да әҗер өмет итеп җомгага килгән кешеләргә җомга намазы үткәрергә тиеш. Имамның өстеннән җомга төшми, һәм әгәр дә ул җомганы калдырса зур гөнаһлы була дип Әбү Хәнифә, Шәфигый, Мәлик, Гата, әл-Хәсән һәм имам Әхмәд бер риваятендә әйттеләр. Әхмәд икенче риваятендә гает укыса, җомга имамның өстеннән төшә диде (әгәр дә җомга укырга кеше килмәсә). Аллаһу әгъләм.

# Хәнәфиләрдә җыр һәм музыка ярыймы?

Музыканың хәрамлыгы турында безнең мәзһәбтә бер капма каршылык та юк. Шулай ук, музыкалы җырны башкару да тыңлау да хәрам дигәнгә хәнәфиләрдә бердәм караш хөкем сөрә. Шуның өчен музыкалы җыр тыңлауны үзенә максат итеп кую да, андый мәҗлесләрдә катнашу да ярамый. Әгәр дә мөселман ниндер дә булса мәҗлескә чакырылса һәм анда музыкалы җырлар буласын белсә, бармаска тиеш, ә инде анда музыка һәм җырлар буласын белмичә барса, андый мәҗлестән чыгып китәргә тиеш. Абруйлы һәм сүзе үтә торган мөселман булса, мондый кабахәт гамәлләрне тыярга тиеш.

Музыкасыз коры җыр гына булса, бу мәсьәләдә хәнәфи галимнәре төрле карашларга килделәр. Берәүләре җырны башкару, җырлау тулысы белән берсүзсез хәрам, ә аны тыңлау гөнаһ дисәләр, икенчеләр, әгәр дә кеше гел ялгыз берүзе генә икән (төрмәдәге кеше яки урмандагы көтүче кебек) бу вакытта кыргыйлыктан сакланыр өчен яхшы мәгънәле җырлар җырларга ярый диделәр. Бу хакта «Фәтәвә әл-Һиндия»дә болай әйтелде: ***«Әгәр дә кеше гел ялгызы гына булып кыргыйлыктан курыкса, бу вакытта аңа җырларга ярый, ә инде хәзерге вакыттагы кебек музыка кораллары белән җырланган җырларны тыңлау да, андый мәҗлесләрдә катнашу да хәрам һәм ярамый торган гамәлләр».*** «Тәбәййин әл-Хакаикъ»та болай әйтелде: ***«Әбү Хәнифә әйтте: Бу нәрсә (җыр) белән мин бер тапкыр сыналдым. Әгәр дә абруйлы кеше мондый гамәлне тыя алмый икән, ул бу мәҗлестә утырмыйча чыгып китәргә тиеш, чөнки мондый гамәлләр динне пычрата һәм гөнаһлы эшләргә ишекләрне ача. Ә инде кеше җырлы һәм музыкалы мәҗлескә чакырылса, бармаска тиеш...».*** Габдуррахман әл-Кәйбулийның

«Мүҗаммагъ әл-Әнһәр»ында болай диелде: ***«Уен кораллары белән уйналган музыка тыңлау — гөнаһ, ә андый мәҗлесләрдә утыру — бозыклык вә азгынлык...».*** Галәветдин әл-Хаскәфий «Әд-Дүр әл-Мухтәр»да болай диде: ***«Җыр мәҗлесендә утырган кешенең яки җыр тыңлаучының шәһәдәте кабул ителми».*** Шушы ук мәгънәдә ибен Габидин «Рад әл-Мухтәр галә әд-Дүр әл-Мухтәр»да, әл-Кәсәний «Бәдәигъ»та, әс-Сәрхасий «әл-Мәбсут»та әйтеп уздылар.

Хәнәфиләрнең бу карашларына китергән кайбер дәлилләре:

(وَمِنَ النَّاسِ مَنْ يَشْتَرِي لَهْوَ الْحَدِيثِ لِيُضِلَّ عَنْ سَبِيلِ اللَّهِ بِغَيْرِ عِلْمٍ وَيَتَّخِذَهَا هُزُوًا أُولَئِكَ لَهُمْ عَذَابٌ مُهِينٌ) لقمان: ٦

Мәгънәсе: **«Кешеләрнең кайберләре бернинди белемсез Аллаһ юлыннан адаштырыр өчен һәм Аллаһ аятьләрен кимсетмәк өчен, үзләренә күңел ачу сүзләре (музыка, җыр) сатып алырлар. Аларга хур итүче каты газап булачак».**

Бу аятьтәге **«күңел ачу сүзләре»** дигәнне ибен Габбас ﵁ җыр һәм шуңа охшашлар дип тәфсир кылды. Шушы ук мәгънәдә Габдуллаһ бин Мәсгуд, Җәбир, Гыйкримә, ән-Нәхагый, Сәгыйд бин Җүбәйр, Мөҗәһид әйттеләр. Әл-Хәсән әл-Бәсрый ***«Җыр һәм музыка кораллары»,*** — диде.

(وَإِذَا سَمِعُوا اللَّغْوَ أَعْرَضُوا عَنْهُ) القصص: ٥٥

Мәгънәсе: **«Әгәр дә яман һәм файдасыз сүз ишетсәләр, алардан читләшерләр...».**

Бу аятьтә, файдасыз вә яман сүзләрне тыңламыйча чыгып китүчеләр мактала. Шушыларга әлбәттә гөнаһка китерә торган музыка һәм җырлардан читләшүчеләр дә керә.

٥٥٩٠ - قَالَ هِشَامُ بْنُ عَمَّارٍ حَدَّثَنَا صَدَقَةُ بْنُ خَالِدٍ حَدَّثَنَا عَبْدُ الرَّحْمَنِ بْنُ يَزِيدَ بْنِ جَابِرٍ حَدَّثَنَا عَطِيَّةُ بْنُ قَيْسٍ الْكِلَابِيُّ حَدَّثَنَا عَبْدُ الرَّحْمَنِ بْنُ غَنْمٍ الْأَشْعَرِيُّ قَالَ حَدَّثَنِي أَبُو عَامِرٍ أَوْ أَبُو مَالِكٍ الْأَشْعَرِيُّ وَاللَّهِ مَا كَذَبَنِي سَمِعَ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَقُولُ: «لَيَكُونَنَّ مِنْ أُمَّتِي أَقْوَامٌ يَسْتَحِلُّونَ الْحِرَ وَالْحَرِيرَ وَالْخَمْرَ وَالْمَعَازِفَ...». (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Гамир әл-Әшгарийдан риваять ителүе буенча, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Минем өммәтемнән шундый кешеләр булырлар, алар зинаны, (ирләргә) ефәк куллануны, хәмер эчүне һәм музыканы рөхсәт итәрләр...».*** (Бохари)

Бу хәдистә пәйгамбәребез ﷺ өммәтебездә хәрамнарны хәләл кылучы кешеләр булуы хакында искә алды һәм ошбу хәрамнардан музыканы әйтеп узды. Хәзерге көндә кайберәүләрнең музыканы рөхсәт итүләре, пәйгамбәребез ﷺ мең ел ярым элек әйтеп калдырган ошбу хәрамны рөхсәт итүчеләр сыйфатына керүләре гаҗәеп түгел. Хәдис шулай ук музыка тыңларга яки андый уен коралларында уйнарга һәм аны сатырга вә сатып алырга хәрам икәнлеген бәян итте.

٢٢١٢ - عن عمران بن حصين أن رسول الله صلى الله عليه وسلم قال: «في هذه الأمة خسف ومسخ وقذف»، فقال رجل من المسلمين: يا رسول الله ومتى ذاك؟ قال: «إذا ظهرت القينات والمعازف وشربت الخمور». (أخرجه الترمذي، صحيح)

Мәгънәсе: Гыймран бин Хусайннан, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Бу өммәттә олагу (җир йоту), кешенең шәкелен кабахәт итеп бозу һәм яла ягу булачак».*** Шуннан соң берәү сорады: «Йә расүл Аллаһ! Болар кайчан булачак?». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Әгәр дә җырчы хатын-кызлар, музыка һәм хәмер эчү барлыкка килсә».*** (Тирмизи, сахих)

Бу хәдистә пәйгамбәребез ﷺ ошбу нәрсәләр барлыкка килсә, бу өммәткә җәза һәм кайгы киләчәге белән кисәтте. Элекке кавемнәрдән билгеле булганча, җәза һәм кайгы, Аллаһның кешеләргә билгеләгән чиген үтеп, хәрам эшләргә кергәннән була. Аллаһ сакласын!

٢٨١١ - عن عقبة بن عامر الجهني عن النبي صلى الله عليه وسلم قال: «... وكل ما يلهو به المرء المسلم باطل إلا رميه بقوسه وتأديبه فرسه وملاعبته امرأته...». (أخرجه ابن ماجه، وصحح الألباني هذه العبارة من حديث عقبة)

Мәгънәсе: Гукъбә бин Гамир әл-Җүһәнийдән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөселманның җәядән атудан, атта чабудан һәм хатыны белән ләззәтләнүдән башка нәрсәләр белән күңел ачуы — батыл (дөрес түгел)».*** (Ибен Мәҗәһ, сахих)

**Нәтиҗә:**

Музыка яки музыкалы җырларны тыңлау Хәнәфиләрдә гөнаһ һәм тыелган нәрсәләрдән, ә инде андый мәҗлесләрдә утыру бозыклык вә азгынлык була. Мөселман белмичә анда барса, чыгып китәргә тиеш, чөнки ул мәҗлесләр гөнаһка ишек ача. Музыкасыз җырлар мәсьәләсендә ике төрле караш:

**1** — Җырлар тулысы белән хәрам һәм аны тыңлау гөнаһ.

**2** — Әгәр дә кеше ялгызы гына булып кыргыйланудан курка икән, бу вакытта яхшы мәгънәле җырлар җырларга рөхсәт ителә. Аллаһу әгъләм.

# Дәваланырга ярыймы?

**Дәвалануның төшенчәсе:**

Аллаһ теләге белән авырудан шифа була торган медицина, шәригать буенча өшкерү, дару үләннәре кебек нәрсәләрне куллану фикһ әһелләрендә дәвалану дип атала. (Мүгъҗам әл-Фукаһа)

**Дәвалануның хөкеме:**

Гомумән алганда, дәвалану пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләреннән күренгәнчә шәригатебездә каралган нәрсә.

٥٦٧٨ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ عَنْ النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «مَا أَنْزَلَ اللَّهُ دَاءً إِلا أَنْزَلَ لَهُ شِفَاءً». (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә нинди генә булса да авыру, чир иңдерсә, һичшиксез ул авыруга дәва иңдерә».***

٣٨٧٤ - عَنْ أَبِى الدَّرْدَاءِ ﷺ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم «إِنَّ اللَّهَ أَنْزَلَ الدَّاءَ وَالدَّوَاءَ وَجَعَلَ لِكُلِّ دَاءٍ دَوَاءً فَتَدَاوَوْا وَلاَ تَدَاوَوْا بِحَرَامٍ». (سنن أبي داود، تحقيق الألباني : ضعيف)

Мәгънәсе: Әбү Дәрдәдән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә авыруны вә дәваны булдырды, һәм һәрбер авыруга дәва билгеләде. Дәваланыгыз, иллә-мәгәр хәрам белән дәваланмагыз».*** (Әбү Дауыд, зәгыйфь хәдис)

Ләкин, гыйлем әһелләре арасында дәвалануның асыл хөкемендә: Мөбахмы, мөстәхәбме әллә дәваланмау хәерлерәкме дигән мәсьәләдә төрле карашлар барлыкка килде:

Хәнәфиләр һәм Мәликиләр дәвалану мөбах диделәр. Бу караш әһелләре түбәндәге дәлилләрне китерделәр:

٥٦٧٨ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ عَنْ النَّبِيِّ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «مَا أَنْزَلَ اللَّهُ دَاءً إِلا أَنْزَلَ لَهُ شِفَاءً». (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә нинди генә булса да авыру, чир иңдерсә, һичшиксез ул авыруга дәва иңдерә».***

٢٢٠٤ - عَنْ جَابِرٍ ﷺ عَنْ رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ أَنَّهُ قَالَ: «لِكُلِّ دَاءٍ دَوَاءٌ فَإِذَا أُصِيبَ دَوَاءُ الدَّاءِ بَرَأَ بِإِذْنِ اللَّهِ عَزَّ وَجَلَّ». (مسلم)

Мәгънәсе: Җәбирдән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Һәрбер авыруга дәва бар, әгәр дә дәва авыруга ирешсә Аллаһ теләге белән сәламәтләнә».*** (Мөслим)

Бу хәдисләрдән аңлашылганча, Аллаһ тәгаләнең һәр чиргә дәва булдыруы, дәвалануга рөхсәт икәнлекнең галәмәте булып тора.

Шәфигыйлар һәм кайбер Хәнбәлиләр дәвалану мөстәхәб дигән карашны алдылар. Үзләренең карашларына түбәндәге дәлилләрне китерделәр:

**А)** Хәнәфиләр һәм Мәликиләр китергән хәдисләр.

**Б)** Һәм бу хәдисләр:

٣٨٧٤ - عَنْ أَبِى الدَّرْدَاءِ ﷺ قَالَ: قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صلى الله عليه وسلم «إِنَّ اللَّهَ أَنْزَلَ الدَّاءَ وَالدَّوَاءَ وَجَعَلَ لِكُلِّ دَاءٍ دَوَاءً فَتَدَاوَوْا وَلاَ تَدَاوَوْا بِحَرَامٍ». (سنن أبي داود، تحقيق الألباني : ضعيف)

Мәгънәсе: Әбү Дәрдәдән ﷺ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Аллаһ тәгалә авыруны вә дәваны булдырды, һәм һәрбер авыруга дәва билгеләде. Дәваланыгыз, иллә — мәгәр хәрам белән дәваланмагыз».*** (Әбү Дауыд, зәгыйфь хәдис)

Бу хәдистә пәйгамбәребез ﷺ хәләл белән дәваланырга кушты, һәм шулай ук башка хәдисләрдә расүлебезнең ﷺ хиҗәмә ясатуы (кан алдыру) дәвалануның мөстәхәблыгын күрсәтә.

Әхмәд бин Хәнбәлнең карашы буенча дәваланмау хәерлерәк, чөнки ул Аллаһка тәвәккәллеккә якын-

рак. Шуңа да бу хакта имам Әхмәд болай диде: «Кем бик тә нык тәвәккәллек кыла икән, аңа дарулар белән дәвалануны ташлау хәерлерәк». (Әл-Әдәп әш-Шәргыя). Бу карашны түбәндәгечә дәлилләделәр:

٦٤٧٢ - عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «يَدْخُلُ الْجَنَّةَ مِنْ أُمَّتِي سَبْعُونَ أَلْفًا بِغَيْرِ حِسَابٍ هُمْ الَّذِينَ لا يَسْتَرْقُونَ وَلا يَتَطَيَّرُونَ وَعَلَى رَبِّهِمْ يَتَوَكَّلُونَ». (البخاري)

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Минем өммәтемнән җитмеш мең кеше Җәннәткә хисапсыз керә. Алар (авырсалар) башкалардан үзләрен өшкерергә сорамыйлар, кошлар очуы буенча начарга юрамыйлар (кызганычка каршы хәзерге заманда да мондый хорафатлар киң таралган, мәсәлән кара мәче юлны аркылы чыкса юл уңмый дип начарга юраулар, һ.б.), үзләренең яраларына тимер кыздырып басмыйлар бәлки һәрвакытта да Раббыларына тәвәккәллек кылалар».*** (Бохари)

Пәйгамбәребез ﷺ бу хәдистә искә алынган төр кешеләрне мактады, чөнки алар Аллаһка тәвәккәллек кылып дәвалануны ташладылар, һәм Ана гына таяндылар.

**Без дөресрәк дип тапкан караш:**

Ибен Хәҗәр әйтүенчә, кем Аллаһка һәм аңа билгеләнгән тәкъдиргә ныклы ышанудa була икән, ул кеше пәйгамбәребезнең ﷺ сөннәтендә билгеле булганча дәвалану сәбәпләре кылса, аның тәвәккәллегенә бер нәрсә дә зыян итә алмый.

Ибен Тәймия бу хакта болай диде: «Гыйлем әһелләре дәвалану вәҗибме, мөстәхәбме әллә мөбахмы дигән мәсьәләдә төрле карашларга бүленделәр. Без дөрес дип тапканы дәвалану төрле хөкемдә, кайсысы хәрам,

мәкруһ, мөстәхәб, ә инде кайберсе хәтта вәҗиб хөкемендә дә булырга мөмкин».

Әгәр дә, авыру кешенең дәвалануны ташлавы үлемгә, яки тәненең икенче бер әгъзасын югалтуга яки инде чирнең тагын та артуына һәм башка әгъзаларга таралуына китерә икән, бу вакытта дәвалану вәҗиб була.

Әгәр дә, дәвалануны ташлау алда әйтеп узганча булмыйча, фәкать тәннең зәгыйфьлегенә китерә икән, бу вакытта дәвалану мөстәхәб була.

Әгәр дә, алда әйтеп узган ике төргә дә кермәсә, дәвалану мөбах була.

Әгәр дә, нинди дә булса дарулар белән дәваланудан чирнең артуыннан курыкса, бу вакытта хәлгә карап мәкруһ яки тыелган хөкемендә була. Аллаһу әгъләм.

# Ялган сөйләп кешеләрне көлдерү ха-
# кында

٤٩٩٠ - قال رسول الله ﷺ: «وَيْلٌ لِلَّذِى يُحَدِّثُ فَيَكْذِبُ لِيُضْحِكَ بِهِ الْقَوْمَ وَيْلٌ لَهُ وَيْلٌ لَهُ». (سنن أبي داود، حسن)

Мәгънәсе: Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кешеләрне көлдерер өчен ялган сөйләүчеләргә хәсрәт булыр, хәсрәт булыр, хәсрәт булыр».***

Билгеле булганча, ялган сөйләү хәрам, иллә-мәгәр өч очрактан башка: Сугыш мәйданында, яки ике мөселманның арасын яхшырту нияте белән (мәсәлән: берсенә барып ул кардәш синнән гафу үтенде һәм икенчесенә барып шулай ук әйтү, һ.б.) һәм ир хатынына ә хатын иренә карата булган кайбер очракларда (мәсәлән: яратмаса да яратам дип әйтү, һ.б.). Бу искәрмәгә кергән өч очрак хакында пәйгамбәребездән ﷺ килгән Бохарида, Мөслимдә һәм башка сөннәт китапларында дөрес хәдисләр бар, һәм болар барсы да зарури вакытта кулланыла. Ләкин безнең мәсьәлә кешеләрне көлдерү өчен сөйләнә торган ялган сүз белән бәйле. Бик зур кызганычка каршы хәзерге вакытта мондый сүзләр, анекдотлар сөйләү кешеләр арасында һәм шулай ук хәзрәтләр арасында бик тә нык таралган. Бу ялган көлдерүләрдә бер зарурат та, файда да юк, бәлки гөнаһ кына бар. Пәйгамбәребез ﷺ бу кабахәт сыйфаттан кисәтеп, ялган сүз сөйләп кешеләрне көлдерүчеләргә хәсрәт булыр диде. Мулла Гали Карый бу хәсрәтне аңлатып болай диде: ***«Ялган сөйләп кешеләрне көлдерүчеләргә хәсрәт булыр дип өч тапкыр катгый рәвештә ныгытып әйтелде, яки инде бу өч тапкыр хәсрәт дип әйтелүнең бу төрле кешеләргә беренчесе — кабердә хәсрәт, икенчесе — Кыямәт мәхшәрендә басып торганда хәсрәт, ә өченчесе — Җәһәннәм утында хәсрәткә ишарәт».*** Аллаһ сакласын. Шулай ук, хәдистән аңлашылганча, әгәр дә кеше дөрес сүз сөйләп башкаларның күңелен күтәрү өчен көлдерә икән, бу вакытта бер зарар да юк. Моңа Гомәрнең ؓ, пәйгамбәребез ﷺ хатыннарына ачулангач, аны көлдерүе ишарәт итә. Аллаһу әгъләм.

# Золым хакында

Гомуми әйткәндә, золым кешедә рәхимлелек сыйфатының юклыгын күрсәткән каты бәгырьлектә, хаклыктан тайпылуда һәм хаклыкны яратмауда яки инде аны кабул итмәдә күренә.

**Золымның мәгънәсе:** Нинди дә булса бер нәрсәне тиешле урынына куймау золым дип атала. Мәсәлән, шундый мәкаль бар: «Кем бүрене сарык көтәргә куйса — золым кылды». Бу мәкаль ачыктан-ачык золымны бәян итә. Чөнки бүренең урыны сарык көтү түгел, бу урын аңа тиеш түгел, бәлки аны көтүлектән ераграк тоту кирәк. Шуңа да бүрене аңа тиешле булмаган урынга кую, хакыйкатьтә, золым икәнлекне күрсәтә.

Коръәндә килгән шушы мәгънәдән чыгып, Аллаһ сөбхәнәһү вә тәгаләгә ширек кату иң зур золым булды. Чөнки хакыйкый вә чын гыйбадәткә Ул гына лаек, һәм иләһият Аңа гына хас. Ә кем инде Аллаһка гына хас булган гыйбадәтләрне башка берәүгә кыла икән, ул кеше аларны тиеш булмаган урынга куйган булып чыга һәм Аллаһка гына хас булган күркәм исемнәрендә, камил сыйфатларында вә иләһияттә, башка берәүне Аңа тиңдәш кыла, Аллаһ сакласын бу адашудан. Бу мәсьәләдә золым Аллаһ тәгаләнең хакы белән бәйле булганга, иң зур вә иң куркыныч золым булып саналды.

## Нәрсәләрдә золым чагылырга мөмкин

Золым чагыла торган урыннар бик күп:

**1)** Бәндәләр Аллаһ каршында булган йөкләмәбурычларын үтәүдә золым кылырга мөмкин. Әгәр дә адәм баласы гакыйдәдә, гыбадәттә, итагатьтә, Аның әмерләрендә яки тыюларында Аллаһка башка нәрсәне тиңли икән, золым кылган була.

**2)** Бәндәләрнең бер-берсенә карата хокукларын бозуда шулай ук золым булырга мөмкин.

**3)** Шулай ук адәм баласы шәһвәткә бирелеп үзен нинди дә булса куркыныч вә һәләкәткә дучар итә икән, ахыргы нәтиҗәсендә үз-үзенә золым кылырга мөмкин.

**4)** Золым шулай ук нинди дә булса җан иясенә карата булырга мөмкин. Рәхимлелеккә ия булган җан иясенә карата золымны каты бәгырьле, үз-үзен генә яратучы һәм башкаларга авырту, сызлану китереп ләззәтләнә торган кабахәт кеше генә эшли ала.

Нинди генә золым булмасын, залим аның өчен җәзага тартыла, чөнки ул шәригатькә муафыйкъ булмаган гамәле белән үзенә һәм башкаларга золым кылган була. Кешенең үз-үзенә золым кылуы аның наданлыгын, ахмаклыгын вә диваналыгын гына күрсәтә. Югарыда искә алып узган золым чагыла торган урыннарга өстәп хаклыкны яшереп калдыру, ялган шәһидлек, мәчетләрдә Аллаһны зикер итүдән тыю, ялган вә батыл белән кешеләрнең хакларын алу, Аллаһның хөкеме искә алынгач аны инкяр итү, хаксызга үтерү, урлау, ялганлау, яла ягу, гайбәт, кешеләр арасын бозу һәм башка гөнаһлы гамәлләрне әйтергә мөмкин.

## Ислам динендә золымга урын юк

Коръән һәм пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә золым вә залимнар хакында, һәм аларны нинди җәзалар көткәнлеге турында бик күп искә алынды. Алардан ошбу нокталарны чагылдырып үтәргә мөмкин:

**1.** Аллаһка ширек кату (Аңа башканы тиңдәш кылу) иң зур вә бик тә куркыныч золымга керә. Шуның өчен дә Локман үзенең улына васыять итеп болай диде:

(وَإِذْ قَالَ لُقْمَانُ لِابْنِهِ وَهُوَ يَعِظُهُ يَا بُنَيَّ لَا تُشْرِكْ
بِاللَّهِ إِنَّ الشِّرْكَ لَظُلْمٌ عَظِيمٌ) لقمان: ١٣

Мәгънәсе: **«Локман улын вәгазьләп әйтте: «Әй улым! Аллаһны бер дип бел, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш итмә! Хакыйкатьтә, ширек (Аллаһка нәрсәне булса да тиңдәш кылу) бик зур золым».**

Чынлыкта да, Аллаһка ширек кату иң зур золым. Чөнки адәм балаларының Аллаһ каршында булган йөкләмә-бурычларыннан: Аңа иман китерергә, тиңдәш кылмыйча бер Аңа гына гыйбадәт кылырга һәм кушканнарын үтәп тыйганнарыннан тыелырга тиешләр. Кем инде Аллаһка гыйбадәт кыласы урынга башкага кечкенә генә гыйбадәт кылса да (мәсәлән бер кешенең әмерен (законын) Аллаһ канунына тиңләсә яки өстенрәк күрсә, дөресрәк дисә) ул үзенең гыйбадәтен тиешсез урынга кылып, ниндидер мәхлукны Аллаһка тиңләде һәм иң зур золымны кылды. Аллаһтан башка, Аның белән тиң дәрәҗәдә һичнәрсә дә гыйбадәт кылынырга тиеш түгел.

(الَّذِينَ آمَنُوا وَلَمْ يَلْبِسُوا إِيمَانَهُمْ بِظُلْمٍ أُولَئِكَ لَهُمُ
الْأَمْنُ وَهُمْ مُهْتَدُونَ) الأنعام: ٨٢

Мәгънәсе: **«Иман китереп, иманнарына золым эшләрне катыштырмаган хак мөэминнәр, Аллаһ газабыннан имин булачаклар һәм алар туры юлга күнүчеләр».**

Бу аятьтә **«золым»** дип килгән сүзнең мәгънәсе ибен Мәсгудтан Бохарида һәм Мөслимдә килгән хәдистә **«ширек»** дип тәфсирләнде:

٣٤٢٩ - عَنْ عَبْدِ اللَّهِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ قَالَ : لَمَّا نَزَلَتْ { الَّذِينَ آمَنُوا وَلَمْ يَلْبِسُوا إِيمَانَهُمْ بِظُلْمٍ } شَقَّ ذَلِكَ عَلَى الْمُسْلِمِينَ فَقَالُوا: يَا رَسُولَ اللَّهِ، أَيُّنَا لا يَظْلِمُ نَفْسَهُ؟ قَالَ: «لَيْسَ ذَلِكَ، إِنَّمَا هُوَ الشِّرْكُ أَلَمْ تَسْمَعُوا مَا قَالَ لُقْمَانُ لابْنِهِ وَهُوَ يَعِظُهُ { يَا بُنَيَّ لَا تُشْرِكْ بِاللَّهِ إِنَّ الشِّرْكَ لَظُلْمٌ عَظِيمٌ }». و في رواية (٦٩٣٧): «ليس كما تظنون، إنما هو كما قال لقمان لابنه». (البخاري)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгуд ﵁ әйтте: «*Иман китереп, иманнарына золым эшләрне катыштырмаган хак мөэминнәр...», — дигән аять иңгәч, сахәбәләр бу аятьны аңлауда авырлык таптылар, һәм: «Әй расүл Аллаһ! Безнең кайсыбыз гына үзенә золым итми икән?», — диделәр. Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:* ***«Сез уйлаганча түгел, хакыйкатьтә, ул (золым) — ширек, сез әллә Локманның үз улына әйткән ошбу сүзләрен ишетмисезме: «Әй улым! Аллаһны бер дип бел, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш итмә! Хакыйкатьтә, ширек (Аллаһка нәрсәне булса да тиңдәш кылу) — бик зур золым».***

**2.** Аллаһ билгеләгән чикләрне узу шулай ук золымга керә. Чикнең асылы билгеле булганча җир белән бәйле. Бер кешенең җиренә икенче берәү узып кермәсен өчен, ул җиргә чик куялар. Аллаһ тәгаләнең кешеләргә билгеләгән чиге ул — Аның шәригате (кешеләргә билгеләгән хәләл вә хәрам, фарызлар вә вәҗибләр кебек). Ул билгеләгән ошбу чикләрне үтеп китү — Аңа буйсынмау була, ә бу инде, бәндәләрнең Раббылары каршында булган йөкләмә-бурычны үтәмәү, золымга керә. Чөнки Аллаһка хас булган буйсынуны, тиешсез урынга куйган була. Шуңа да буйсынмаучылар, гөнаһ кылучылар вә фәсикълар мөселман булсалар да золым сыйфатлары белән сыйфатландылар.

(تِلْكَ حُدُودُ اللَّهِ فَلَا تَعْتَدُوهَا وَمَنْ يَتَعَدَّ حُدُودَ اللَّهِ
فَأُولَئِكَ هُمُ الظَّالِمُونَ) البقرة: ٢٢٩

Мәгънәсе: **«Бу бәян ителмеш хөкемнәр Аллаһ чикләгән чиктер, бу чиктән үтмәгез! Берәү Аллаһ чигеннән үтеп китсә, ул, әлбәттә, залим».**

Бу аятьтә искә алынган **«Аллаһ чикләгән чик»,** — дигән хөкемнәр, моннан алда искә алынган хәмер, отыш уеннар, ятимнәр хакы, никах, хатыннарга яхшы мөгамәләдә булу, ант вә нәзер, талак һәм башка хөкемнәр белән бәйле.

**3.** Аллаһ тәгалә, мәгъсыять кылган Бәнү Исраил кавеменең золым эшләүләре хакында болай диде:

(فَبَدَّلَ الَّذِينَ ظَلَمُوا مِنْهُمْ قَوْلًا غَيْرَ الَّذِي قِيلَ لَهُمْ فَأَرْسَلْنَا عَلَيْهِمْ
رِجْزًا مِنَ السَّمَاءِ بِمَا كَانُوا يَظْلِمُونَ) الأعراف: ١٦٢

Мәгънәсе: **«Аларның залимнәре, шәһәргә кергәндә әйтер өчен Аллаһ өйрәткән сүзне, башка сүзгә алыштырды. Золым итүләре сәбәпле Без аларга күктән газап җибәрдек».**

(فَبِظُلْمٍ مِنَ الَّذِينَ هَادُوا حَرَّمْنَا عَلَيْهِمْ طَيِّبَاتٍ أُحِلَّتْ لَهُمْ وَبِصَدِّهِمْ عَنْ
سَبِيلِ اللَّهِ كَثِيرًا ۞ وَأَخْذِهِمُ الرِّبَا وَقَدْ نُهُوا عَنْهُ وَأَكْلِهِمْ أَمْوَالَ النَّاسِ
بِالْبَاطِلِ وَأَعْتَدْنَا لِلْكَافِرِينَ مِنْهُمْ عَذَابًا أَلِيمًا) النساء: ١٦٠ - ١٦١

Мәгънәсе: **«Яһүдләрдән золым итүчеләре вә күп кешеләрне Аллаһ юлыннан тыючылары булу сәбәпле, әүвәлдә аларга хәләл булган нәрсәләрне, хыянәтләре соңында хәрам кылдык. Янә Аллаһ тарафыннан катгый тыелган булсалар да, риба, ришвәт алулары һәм кеше малын хаксыз ашаулары сәбәпле, яһүдләрнең кәфер булганнарына каты газап әзерләдек».**

**4.** Байлар вә абруйлы кешеләр Исламга килсәләр алардан файда күбрәк булыр дип, аларга якы-

наеп үзеңнең яныңнан мөселман фәкыйрьләрне читләштерү, шулай ук золымга керә.

(وَلَا تَطْرُدِ الَّذِينَ يَدْعُونَ رَبَّهُمْ بِالْغَدَاةِ وَالْعَشِيِّ يُرِيدُونَ وَجْهَهُ
مَا عَلَيْكَ مِنْ حِسَابِهِمْ مِنْ شَيْءٍ وَمَا مِنْ حِسَابِكَ عَلَيْهِمْ مِنْ
شَيْءٍ فَتَطْرُدَهُمْ فَتَكُونَ مِنَ الظَّالِمِينَ) الأنعام: ٥٢

Мәгънәсе: **«Аллаһ ризалыгын өстәп көндезләрен вә кичләрен Раббыларына гыйбадәт кылган зәгыйфь яки фәкыйрь мөэминнәрне яныңнан кума! Ул кәферләрнең гамәленнән һичнәрсәне хисап итмәк синңа тиеш түгел һәм синең гамәлеңнән һичнәрсәне хисап итмәк аларга тиеш түгел. Дошманнар сүзенә карап, фәкыйрьләрне яныңнан кума! Әгәр кусаң, залимнәрдән булырсың».**

Бу аятьтән күренгәнчә, мөшрикләр пәйгамбәребезгә ﷺ: «Үзенең яныңнан фәкыйрь вә мескен мөселманнарны кусаң, без синең динеңә бәлки керербез, чөнки без ул фәкыйрьләр белән бергә җыела алмыйбыз», — дип, шарт куйдылар. Аллаһ тәгалә ошбуны бәян итеп аять иңдерде.

**5.** Юныс عليه السلام балык эчендә булганда аңа килгән авырлык, кавеме иман китермәгән өчен аларга ачуланып чыгып киткән сәбәпле икәнлеген тойды. Һәм бу гамәлнең, аның тарафыннан кавеменә карата золым икәнлеген аңлап Раббысына ялварды:

وَذَا النُّونِ إِذْ ذَهَبَ مُغَاضِبًا فَظَنَّ أَنْ لَنْ نَقْدِرَ عَلَيْهِ فَنَادَى فِي الظُّلُمَاتِ
أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ ۞ فَاسْتَجَبْنَا لَهُ
وَنَجَّيْنَاهُ مِنَ الْغَمِّ وَكَذَلِكَ نُنْجِي الْمُؤْمِنِينَ الأنبياء: ٨٧ - ٨٨

Мәгънәсе: **«Юнысны да хәтерләгез, ачуланып кавеменнән аерылып китте, ул кавемен ташлап киткән өчен Безнең аңа хөкем булмас дип уйлады. Ул караңгыда яки балык эчендә дога кылып әйтте: «Әй Аллаһ!**

**Синнән башка һич иләһ юк, мәгәр Син генә, Сине һәр кимчелектән пакь дип беләмен, Синең рөхсәтеңнән башка кавемемне ташлап китүем белән үземә золым итүчеләрдән булдым». Аның догасын кабул иттек, вә аны кайгысыннан коткардык, әнә шулай мөэминнәрне коткарабыз».**

6. Аллаһ тәгалә Адәм белән Хәвага билгеле бер агачтан ашарга тыйды, һәм әгәр дә алар тыелган агачтан ашасалар залимнардан булачакларын белгертте:

(وَقُلْنَا يَا آَدَمُ اسْكُنْ أَنْتَ وَزَوْجُكَ الْجَنَّةَ وَكُلَا مِنْهَا رَغَدًا حَيْثُ
شِئْتُمَا وَلَا تَقْرَبَا هَذِهِ الشَّجَرَةَ فَتَكُونَا مِنَ الظَّالِمِينَ) البقرة: ٣٥

Мәгънәсе: **«Вә Адәмгә әйттек: «Үзең һәм хатының Җәннәттә торыгыз һәм җимешләрен киңлек илә теләгәнчә ашагыз, мәгәр бу агачка якын бармагыз, әгәр шуны эшләсәгез, залимнәрдән булырсыз».**

Бу аятьтән күренгәнчә, Аллаһ тәгаләнең тыйганнарыннан тыелмау, золымга керә.

**7.** Хаклыкны яшереп калдыру шулай ук золымга керә. Хаклыкны яшерүдә булган иң зур золым, ул Аллаһның дине вә шәригате белән бәйле хаклыкны яшерү һәм ялган шәһидлек кылу.

(أَمْ تَقُولُونَ إِنَّ إِبْرَاهِيمَ وَإِسْمَاعِيلَ وَإِسْحَاقَ وَيَعْقُوبَ وَالْأَسْبَاطَ
كَانُوا هُودًا أَوْ نَصَارَى قُلْ أَأَنْتُمْ أَعْلَمُ أَمِ اللَّهُ وَمَنْ أَظْلَمُ مِمَّنْ كَتَمَ
شَهَادَةً عِنْدَهُ مِنَ اللَّهِ وَمَا اللَّهُ بِغَافِلٍ عَمَّا تَعْمَلُونَ) البقرة: ١٤٠

Мәгънәсе: **«Әллә сез әйтәсезме: Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб һәм башка пәйгамбәрләр яһүд динендә яки насара динендә иделәр дип? Син аларга әйт: «Пәйгамбәрләрнең кайсы диндә булганлыкларын сезме яки Аллаһмы белүчерәк?». Белгән нәрсәсен Аллаһтан яшереп маташкан кеше хәтле залим кеше**

**булырмы? Бит Аллаһ сезнең кылган эшләрегездән һич гафил түгел».**

**8.** Мәчетләрдә Аллаһның исемен искә алудан һәм Аңа гыйбадәт кылудан тыю, зур золымга керә.

(وَمَنْ أَظْلَمُ مِمَّنْ مَنَعَ مَسَاجِدَ اللَّهِ أَنْ يُذْكَرَ فِيهَا اسْمُهُ وَسَعَى
فِي خَرَابِهَا أُولَئِكَ مَا كَانَ لَهُمْ أَنْ يَدْخُلُوهَا إِلَّا خَائِفِينَ لَهُمْ فِي
الدُّنْيَا خِزْيٌ وَلَهُمْ فِي الْآخِرَةِ عَذَابٌ عَظِيمٌ) البقرة: ١١٤

Мәгънәсе: **«Мәчетләрдә Аллаһны искә алудан тыйган һәм шундый мәчетләрне юк итәргә тырышкан кешеләрдән дә залимрәк кеше булырмы? Аларга Аллаһ мәчетләренә мәгәр куркучы хәлдә генә керү тиеш иде. Аларга дөньяда хурлык, ахирәттә олуг газап».**

Бу залимнарны өч төрле җәза көтә: **1 —** аларның йөрәкләренә курку керә, һәм әгәр дә мәчеткә керә калсалар, курыккан вә кимсетелгән хәлдә генә керә алалар; **2 —** бу дөньяда аларны хурлык вә рисвайлык көтә; **3 —** ахирәттә аларны олуг газап көтә.

**9.** Аллаһның аятьләре искә алынгач, аларны кабул итмичә инкяр итү, шулай ук куркыныч золымнарның берсе.

(وَمَنْ أَظْلَمُ مِمَّنْ ذُكِّرَ بِآيَاتِ رَبِّهِ فَأَعْرَضَ عَنْهَا وَنَسِيَ مَا قَدَّمَتْ
يَدَاهُ إِنَّا جَعَلْنَا عَلَى قُلُوبِهِمْ أَكِنَّةً أَنْ يَفْقَهُوهُ وَفِي آذَانِهِمْ وَقْرًا
وَإِنْ تَدْعُهُمْ إِلَى الْهُدَى فَلَنْ يَهْتَدُوا إِذًا أَبَدًا) الكهف: ٥٧

Мәгънәсе: **«Раббысының аятьләре искә алынып та аннан баш тарткан һәм үзенең куллары эшләгән (гөнаһлы) эшләрне оныткын кешедән дә залимрәк кеше булырмы? Инде аңламасыннар өчен Без аларның йөрәкләренә (вә күңелләренә) пәрдә кылдык, вә хак сүзне ишетмәсеннәр өчен колакларын саңгыраулы**

**кылдык. Әгәр син аларны һидәяткә чакырсаң, мәңге һидәяткә күнелмәсләр».**

Икенче аятьтә Аллаһ тәгалә бу төрле кешеләрне җинаятьчеләр дип сыйфатлады:

(وَمَنْ أَظْلَمُ مِمَّنْ ذُكِّرَ بِآيَاتِ رَبِّهِ ثُمَّ أَعْرَضَ عَنْهَا
إِنَّا مِنَ الْمُجْرِمِينَ مُنْتَقِمُونَ) السجدة: ٢٢

Мәгънәсе: **«Раббысының аятьләре искә алынып та, аннан баш тарткан кешедән дә залимрәк кеше булырмы? Хакыйкатьтә, Без җинаятьчеләрдән үч алучыбыз».**

Барчабызга да билгеле ки, җинаятьче үзенең эше өчен җәзага тартылырга тиеш. Һәрбер залим — ул җинаятьче, ә инде Аллаһның шәригатен кабул итмәүчеләр, алар иң зур җинаятьчеләр һәм бу җинятьләре өчен һичшиксез җәзага тартылачаклар.

**10.** Кешеләрне, белемсез килеш, туры вә хак юлдан адаштырыр өчен Аллаһ тәгаләгә ялганны тагу, шулай ук куркыныч золымнардан санала.

(فَمَنْ أَظْلَمُ مِمَّنِ افْتَرَى عَلَى اللَّهِ كَذِبًا لِيُضِلَّ النَّاسَ بِغَيْرِ
عِلْمٍ إِنَّ اللَّهَ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الظَّالِمِينَ) الأنعام: ١٤٤

Мәгънәсе: **«Наданлык белән дәлилсез, кешеләрне адаштыру өчен Аллаһка ялганны ифтира кылган кеше хәтле залимрәк кеше булырмы? Әлбәттә, Аллаһ тәгалә залимнәрне туры юлга салмас».**

Бу төрле кешеләр үзләренең наданлыклары белән башкаларны туры вә хак юлдан адаштырыр өчен Раббыларына ялганны сөйләп зур золым кылгач, ничек Аллаһ тәгалә аларны һидәяткә вә туры юлга күндерсен?

**11.** Башка кешеләргә һәм аларның мал-мөлкәтләренә карата золым кылу.

(يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَأْكُلُوا أَمْوَالَكُمْ بَيْنَكُمْ بِالْبَاطِلِ إِلَّا أَنْ تَكُونَ تِجَارَةً عَنْ تَرَاضٍ مِنْكُمْ وَلَا تَقْتُلُوا أَنْفُسَكُمْ إِنَّ اللَّهَ كَانَ بِكُمْ رَحِيمًا ۞ وَمَنْ يَفْعَلْ ذَلِكَ عُدْوَانًا وَظُلْمًا فَسَوْفَ نُصْلِيهِ نَارًا وَكَانَ ذَلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرًا) النساء: ٢٩ - ٣٠

Мәгънәсе: **«Әй, мөэминнәр! Үзара малларыгызны хыянәт, золым юллар белән ашамагыз, мәгәр риза булышканыгыз хәлдә сәүдә белән кәсеп итеп ашагыз. Янә үз-үзегезне, яки дин кардәшегезне үтермәгез. Дөреслектә, Аллаһ сезнең өчен рәхимле булды. Кем бу эшләрне дошманлык вә золым юллары белән эшләсә, аны тиздән Җәһәннәм утына салырбыз, Аллаһка бу эш җиңел булды».**

Кешеләргә һәм аларның малларына карата золым кылу — Аллаһ каршында зур гөнаһ, һәм аның нәтиҗәсе дә бик куркыныч. Бу хакта пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдисләрендә кисәтеп узды һәм без кайберләрен искә алып үтәрбез:

٢٥٨٢ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «لَتُؤَدُّنَّ الْحُقُوقَ إِلَى أَهْلِهَا يَوْمَ الْقِيَامَةِ حَتَّى يُقَادَ لِلشَّاةِ الْجَلْحَاءِ مِنْ الشَّاةِ الْقَرْنَاءِ»(مسلم)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ؓ, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кыямәт көнендә барча тиешле булган хаклар үз ияләренә кайтарылачак, хәтта мөгезле тәкә (яки нинди генә булса да хайван) мөгезсезне сөзгәне өчен, аралары хөкем ителәчәк».***

٣١١٨ - عَنْ خَوْلَةَ الأَنْصَارِيَّةِ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهَا قَالَتْ: سَمِعْتُ النَّبِيَّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ يَقُولُ: «إِنَّ رِجَالاً يَتَخَوَّضُونَ فِي مَالِ اللَّهِ بِغَيْرِ حَقٍّ فَلَهُمْ النَّارُ يَوْمَ الْقِيَامَةِ». (البخاري)

Мәгънәсе: Хаулә әл-Әнсария ﵂ әйтте: Мин пәйгамбәребезнең ﷺ әйткәнен ишеттем: ***«Хакыйкатьтә, кайбер кешеләр Аллаһның байлыгын хаксыз вә тиешсез сарыф итәләр, ул кешеләргә Кыямәт көнендә ут булачак».***

٢٤٤٩ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُ قَالَ : قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «مَنْ كَانَتْ لَهُ مَظْلَمَةٌ لأَخِيهِ مِنْ عِرْضِهِ أَوْ شَيْءٍ فَلْيَتَحَلَّلْهُ مِنْهُ الْيَوْمَ قَبْلَ أَنْ لا يَكُونَ دِينَارٌ وَلا دِرْهَمٌ، إِنْ كَانَ لَهُ عَمَلٌ صَالِحٌ أُخِذَ مِنْهُ بِقَدْرِ مَظْلَمَتِهِ وَإِنْ لَمْ تَكُنْ لَهُ حَسَنَاتٌ أُخِذَ مِنْ سَيِّئَاتِ صَاحِبِهِ فَحُمِلَ عَلَيْهِ». (البخاري)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем кардәшенең намусына яки башка бер әйберсенә карата золым иткән булса, динар да дирһам да юкка чыканчыга кадәр (Кыямәт көне җиткәнчегә кадәр) ул золымнан бүген үк котылсын (кемне җәберләгән булса, шуннан гафу үтенеп вә тиешле хакын кайтарып хәер-фатыхасын алсын). (Ул золымыннан бу дөньяда ук котылмаса, Кыямәт көнендә) әгәр дә аның изге гамәлләре булса, шул изгелекләреннән золым микъдары кадәр алынып, җәберләнгән кешегә бирелер. Изгелекләре булмаса, җәберләнгән кешенең начар гамәлләре (гөнаһлары) алынып, золым кылучыга йөкләнер».***

٢٥٨١ - عَنْ أَبِي هُرَيْرَةَ ﵁ أَنَّ رَسُولَ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «أَتَدْرُونَ مَا الْمُفْلِسُ؟». قَالُوا: الْمُفْلِسُ فِينَا مَنْ لا دِرْهَمَ لَهُ وَلا مَتَاعَ. فَقَالَ: «إِنَّ الْمُفْلِسَ مِنْ أُمَّتِي يَأْتِي يَوْمَ الْقِيَامَةِ بِصَلاةٍ وَصِيَامٍ وَزَكَاةٍ، وَيَأْتِي قَدْ شَتَمَ هَذَا، وَقَذَفَ هَذَا، وَأَكَلَ مَالَ هَذَا، وَسَفَكَ دَمَ هَذَا، وَضَرَبَ هَذَا، فَيُعْطَى هَذَا مِنْ حَسَنَاتِهِ، وَهَذَا مِنْ حَسَنَاتِهِ، فَإِنْ فَنِيَتْ حَسَنَاتُهُ قَبْلَ أَنْ يُقْضَى مَا عَلَيْهِ أُخِذَ مِنْ خَطَايَاهُمْ فَطُرِحَتْ عَلَيْهِ، ثُمَّ طُرِحَ فِي النَّارِ». (مسلم)

Мәгънәсе: Әбү Һурайрадән ﵁, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Сез беләсезме, кем ул бөлгенлеккә төшкән кеше (банкрот)?».*** Сахәбәләр әйттеләр: «Бөлгенлеккә

төшкән кеше ул, кемнең дирһамы да, малы да юк». Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Хакыйкатьтә, минем өммәтемнән бөлгенлеккә төшкән кеше шул булыр: Кыямәт көнендә ул кеше намаз, ураза һәм зәкәтләре белән килер, әмма дөньяда вакытта ул берәүне орышкан, икенчегә яла яккан, өченченең малын хаксыз ашаган, дүртенченең тиешсез канын түккән, бишенчегә кул күтәргән. Боларның һәрберсенә ул үзенең изге гамәлләреннән бирер, ә инде аларның хакларын кайтарып түләгәнче аның изгелекләре бетсә, ул вакытта җәберләнгән кешеләрнең гөнаһ-хаталары алынып аңа йөкләнер, һәм шуннан соң утка ташланыр».*** Аллаһ сакласын!

Бу һәм башка золым белән бәйле хәдисләрдән аңлашылганча, Аллаһ тәгаләнең гаделлеге залимнарны хөкем итүдә өскә чыгачак. Ул Үзенең гаделлек канунын Кыямәт көнендә хәтта акылы булмаган һәм шәригать белән йөкләнмәгән хайваннарга да билгеләячәк. Алар хайван булсалар да, ләкин Аллаһ тәгалә аларны начар яки яхшы мөгамәләне, авыртуны вә хаксыз җәберләүне сизә торган итеп халикъ кылды. Без моны үзебезнең көндәлек тормышыбызда күрмибезме әллә? Әгәр дә сыерга яки атка, мәчегә яки башка хайванга яхшы мөгамәлә кылып, аларны сыпырсаң һәм ашатсаң, аларга бу ошый түгелме? Шулай ук аларга начар мөгамәлә кылып суксаң яки ач тотсаң, бу золымнан алар синнән качып китәргә әзер түгелме? Кем кечкенә тузан бөртеге кадәр хәерле эш эшләсә, шуның нәтиҗәсен күрәчәк, ә кем кечкенә тузан бөртеге кадәр начарлык эшләсә, шуның җәзасын татыячак. Бохарида (6979) ибен әл-Лүтбия хакындагы хәдистән күренгәнчә; кем үзенә тиешле булмаган малны алган булса, Кыямәт көнендә шул малы белән

киләчәк. Шулай ук кем нисабка җиткән малыннан зәкәтен чыгармаса, шуның өчен газап кылыначак, чөнки зәкәт чыгарыласы өлеше аның хакы түгел. Гомәр ﵁ әйткәнчә, мөселман кешесе Кыяматтә хисаплану җиткәнчегә кадәр, үзен бу дөньяда хисапларга тиеш. Аллаһу мүстәган!

**12.** Золым иң кабахәт гамәлләрдән икәнлеген бәян кылып, хәдис-кудсидә пәйгамбәребез ﷺ Раббысыннан риваять итеп болай диде (мәгънәсе): Аллаһ тәгалә әйтте: ***«Әй колларым! Мин золымны үземә хәрам кылдым, һәм сезнең арагызда да аны тыйдым, бер-берегезгә золым кылмагыз!».***

Моннан аңлашылганча, Аллаһ тәгалә үзенә дә, бәндәләргә дә золымны бертигез хәрам кылды, һәм Ул кечкенә тузан бөртеге кадәр дә золым итми:

(إِنَّ اللَّهَ لَا يَظْلِمُ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ وَإِنْ تَكُ حَسَنَةً يُضَاعِفْهَا
وَيُؤْتِ مِنْ لَدُنْهُ أَجْرًا عَظِيمًا) النساء: ٤٠

Мәгънәсе: **«Аллаһ бәндәләренә тузан хәтле дә золым итми. Әгәр ул тузан бөртеге хәтле эш — изгелек булса, Аллаһ ул изгелекне арттырыр һәм рәхмәтеннән олы әҗерне бирер».**

(إِنَّ اللَّهَ لَا يَظْلِمُ النَّاسَ شَيْئًا وَلَكِنَّ النَّاسَ أَنْفُسَهُمْ يَظْلِمُونَ) يونس: ٤٤

Мәгънәсе: **«Аллаһ кешеләргә берничек тә золым итми, ләкин кешеләр Аллаһка карышып үзләренә-үзләре золым итәләр».**

**13.** Кыямәт көнендә залим караңгылыклар пәрдәсе белән каплана, һәм аның юлдашы газап булачак. Ә изгелекнең юлдашы нур булачак.

٢٤٤٧ ـ عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عُمَرَ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمَا عَنِ النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ قَالَ: «الظُّلْمُ ظُلُمَاتٌ يَوْمَ الْقِيَامَةِ». (البخاري)

Мәгънәсе: Ибен Гомәрдән ﵁ риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кыямәт көнендә золым кап-кара караңгылыкка әйләнәчәк».***

(يَوْمَ تَرَى الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ يَسْعَى نُورُهُمْ بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَبِأَيْمَانِهِمْ بُشْرَاكُمُ الْيَوْمَ جَنَّاتٌ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا ذَلِكَ هُوَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ (٢١) يَوْمَ يَقُولُ الْمُنَافِقُونَ وَالْمُنَافِقَاتُ لِلَّذِينَ آمَنُوا انْظُرُونَا نَقْتَبِسْ مِنْ نُورِكُمْ قِيلَ ارْجِعُوا وَرَاءَكُمْ فَالْتَمِسُوا نُورًا فَضُرِبَ بَيْنَهُمْ بِسُورٍ لَهُ بَابٌ بَاطِنُهُ فِيهِ الرَّحْمَةُ وَظَاهِرُهُ مِنْ قِبَلِهِ الْعَذَابُ) الحديد: ١٢ - ١٣

Мәгънәсе: **«Кыямәт көнендә мөэминнәрне вә мөэминәләрне күрерсең, һидәят нурлары алларыннан вә уңнарыннан барыр. Фәрештәләр әйтер: «Бүген сөенеч сезләргә, сезгә асларыннан татлы елгалар ага торган бакчалар, ул бакчаларда сез мәңге калырсыз, нурга чорналып бакчаларда мәңге калу зур уңыштыр». Кыямәт көнендә монафикъ ирләр вә монафика хатыннар мөэминнәргә әйтерләр: «Безне көтегез, нурыгыздан файдаланып артыгыздан барыйкчы», — дип. Аларга әйтелер: «Артыгызда калган дөньяга кайтыгыз вә нурны анда эзләгез», — дип. Ул мөэминнәр белән монафикълар арасына бер ишекле дивар корылыр, ул диварның эчендә рәхимлелек ә тышында гаты газабтыр».**

**14.** Аллаһ тәгалә залимны бу дөньяда бәлки беразга кичектерсә дә, әмма ләкин аны җәза кылса, тиешлечә җәзалый. Күпме залимнар мәкерлек кылып, үзләренең мәкерлекләренә дучар булдылар.

(وَكَذَلِكَ أَخْذُ رَبِّكَ إِذَا أَخَذَ الْقُرَى وَهِيَ ظَالِمَةٌ إِنَّ أَخْذَهُ أَلِيمٌ شَدِيدٌ) هود: ١٠٢

Мәгънәсе: **«Әнә шулай, кешеләре азган вә залим шәһәрне, Раббыңның газап белән тотуы бик тиз вә бик каты булды».**

**15.** Золым кылынган вә җәберләнгән кешенең догасы пәрдәсез кабул була. Бу хакта пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисендә болай диелде:

١٤٩٦ - عَنْ ابْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمَا قَالَ : قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ لِمُعَاذِ بْنِ جَبَلٍ حِينَ بَعَثَهُ إِلَى الْيَمَنِ: «إِنَّكَ سَتَأْتِي قَوْمًا أَهْلَ كِتَابٍ فَإِذَا جِئْتَهُمْ فَادْعُهُمْ إِلَى أَنْ يَشْهَدُوا أَنْ لا إِلَهَ إِلا اللَّهُ وَأَنَّ مُحَمَّدًا رَسُولُ اللَّهِ فَإِنْ هُمْ أَطَاعُوا لَكَ بِذَلِكَ فَأَخْبِرْهُمْ أَنَّ اللَّهَ قَدْ فَرَضَ عَلَيْهِمْ خَمْسَ صَلَوَاتٍ فِي كُلِّ يَوْمٍ وَلَيْلَةٍ فَإِنْ هُمْ أَطَاعُوا لَكَ بِذَلِكَ فَأَخْبِرْهُمْ أَنَّ اللَّهَ قَدْ فَرَضَ عَلَيْهِمْ صَدَقَةً تُؤْخَذُ مِنْ أَغْنِيَائِهِمْ فَتُرَدُّ عَلَى فُقَرَائِهِمْ فَإِنْ هُمْ أَطَاعُوا لَكَ بِذَلِكَ فَإِيَّاكَ وَكَرَائِمَ أَمْوَالِهِمْ وَاتَّقِ دَعْوَةَ الْمَظْلُومِ فَإِنَّهُ لَيْسَ بَيْنَهُ وَبَيْنَ اللَّهِ حِجَابٌ». (البخاري)

Мәгънәсе: Ибен Габбастан ﵁ риваять ителә, пәйгамбәребез ﷺ Мугаз бин Җәбәлне Йәмәнгә җибәргәндә, аңа нәсыйхәт итеп әйтте: ***«Хакыйкатьтә, син китап әһелләреннән булган кешеләргә барачаксың, анда җиткәч аларны «Лә иләһә иллә Аллаһ вә ән-нә Мүхәммәдәр-расүл Аллаһ», — дип таныклык бирүләренә чакыр. Әгәр дә моны кабул итеп сиңа итагать итсәләр, аларга Аллаһ тәгалә көненә биш вакыт намаз укуны фарыз кылганлыгын хәбәр ит. Алар намазны кабул итеп сиңа итагать итсәләр, Аллаһ аларга байлардан алынып фәкыйрьләргә бирелә торган зәкәт белән фарыз иткәнлеген хәбәр ит. Алар моны да кабул итеп сиңа зәкәт чыгаруда да итагать итсәләр, аларның бик кадерле булган мал-мөлкәтләрен алудан саклан, һәм дә җәберләнгән кешенең догасыннан (сиңа ләгънәт кылып дога кылуыннан) курык! Хакыйкатьтә, ул кешенең догасы белән Аллаһ арасында пәрдә юк!».***

Кешеләрне золым итүчеләр уйлансын!

**16.** Кыямәт көнендә иң беренче булып хаксызга кеше үтерүче хөкем ителәчәк. Бу хакта пәйгамбәребезнең ﷺ Бохарида килгән хәдисендә болай бәян ителде:

٦٨٦٤ - عَنْ عَبْدِ اللَّهِ قَالَ: قَالَ النَّبِيُّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: «أَوَّلُ مَا يُقْضَى بَيْنَ النَّاسِ فِي الدِّمَاءِ». (البخاري)

Мәгънәсе: Габдуллаһ бин Мәсгудтән ﵁ риваять кылына, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кыямәт көнендә иң беренче, кешеләр арасында булган кан хакы хәл ителәчәк».***

**17.** Кем үзенең көнен Аллаһка гыйбадәт белән башласа, ул кеше Аллаһ тәгаләнең сагында булыр. Золымнан саклану өчен, бу иң хәерле гамәл. Чөнки Мөслимдә (657)нче сан белән килгән хәдистә пәйгамбәребез ﷺ бу хакта бәян итеп болай диде (кыскача мәгънәсе): ***«Кем иртәнге намазны укыса, ул Аллаһ тәгаләнең иминлегендә (сагында) була...».***

Раббысының кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәгән мөселманның дәрәҗәсе вә хакы зур, чөнки ул Аллаһның иминлеге вә сагы белән тәэмин ителгән. Бу Раббуль-гыйззәһ тарафыннан мөэминнәргә бүләк һәм рәхимлек. Акылы булган кеше Аллаһка көферлек кылып, Аның биргән нигъмәтен инкяр итеп, үзенә һәм башкаларга золым ясап үз-үзен Җәһәннәм утына салмас.

## Эчтәлек

Догаң кабул булсын дисәң..............................1
Пәйгамбәребезгә мәхәббәт...........................9
Сабырларны шатландыр...............................33
Яланбаш намаз уку хакында.........................65
Оекбашка (носкига) мәсех кылырга ярыймы?.............................................................69
Тәвәссүл...................................................73
Мәүлид кичәсен бәйрәм итү..........................81
Гает намазы җомгага туры килсә.................85
Хәнәфиләрдә җыр һәм музыка ярыймы?.....91
Дәваланырга ярыймы?................................97
Ялган сөйләп кешеләр көлдерү хакында....103
Золым хакында........................................105